ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN
ISSN 0130-2418
1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
№ 4 (351)
АПРЕЛЬ 2021
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ГАЛӘМНЕ ЯКТЫРТКАН ЕЛМАЮ: БӘҺАСЕЗ КАДР ТАРИХЫ

6+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Зәһидуллин, Михаил Рябинин,
Ксения Сёмина, Ландыш Фаезова
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: кинооператор Мәхмүт Рафыйковның
документаль фильмыннан кадр

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-980
Басарга кул куелды: 09.04.2021
Басмадан чыкты: 15.04.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79
Коммерция директоры:
Юлия Фасахова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

БУЛАЧАК КОСМОНАВТЛАРНЫҢ ДӨРЕС ХЫЯЛЛАРЫ

Теләсә кайсы олы кешедән аның нәрсә турында хыяллануын сорагыз – кайчагында социаль челтәрләрдә блогерлар шундый сорау бирә. Комментарийларда «яңа машина алырга телим», «бай иргә кияүгә чыгасым килә», «акчага тиенеп, эшләмичә генә яшисе килә» дигәнрәк җаваплар тезелеп китә, «ипотеканы түләп бетереп, бурычларсыз гына тынычлап яшәр идем» дигәне дә бар. Шушы ук сорауны балаларга бирсәң, космик хыялларга якынраклары турында ишетерсез. Әлбәттә, Яңа ел бәйрәме җитәрәк «iPhone12 Pro» турындагы хыял алгарак чыгар, әмма аның бусы хыял түгел, ә Кыш бабайга бирем дисәк, дөрес булыр. Балаларның киләчәк турындагы хыяллары төптән уйланылган: «иң көчлесе булыр идем дә бөтен кешегә ярдәм итәр идем», «президент булыр идем дә, бер генә хәерче дә калмас иде» дигәннән алып, «әни авырмасын өчен, табиб булыр идем» дигәнгә кадәр.

Кайчандыр без бәләкәй чакта космонавт булырга, яңа планеталар ачып, чит планета кешеләре белән дуслашырга хыяллана идек. Исегездәме? Балалар матур итеп, зурдан кубып, һәрнәрсәдән азат булып, өлкәннәргә ихлас һәм дөрес хыялның нинди булырга тиеш икәнен күрсәтеп хыяллана белә. Чөнки хыял ихлас булса, «президентлар», президент булмыйча да, ярлыларга ярдәм итә, «космонавтлар», Галәм киңлекләренә күтәрелмичә дә, теләсә кайсы биеклекне буйсындыра ала, ә инде табибларның әниләре барысы да сәламәт һәм үзләрен яхшы хис итә.

Хыялларыгыз турында уйланыгыз, чөнки дөрес хыялларның чынга аша торган гадәте бар.

Сезнең космик редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «Татарстан» журналына

Татарстанның 100 җәүһәре
Бары тик Татарстанда

Илнең космик калканы

Мәскәүнең чит ракеталарга каршы (ПРО) стратегик системасының хәрби кизүе башлануы турында илебезнең массакүләм мәгълүмат чаралары әдәп саклап дәшми кала. ПРО составына Казанның «Союз» тәҗрибә-конструкторлык бюросында уйлап табылган двигательләр урнаштырылган ракеталар керүе турында да... 1990 ел була ул, «Катгый сер» грифы формаль түгел әле, һәм «Союз»-ның баш конструкторы Ирек Фәхретдиновны тар даирә кешеләре генә белә. Ирек Фәхретдинов һәм аның конструкторлык бюросы катнашкан уңышлы проектлар арасында – «С-300« һәм «Бук» зенит комплекслары ракеталары, илнең ракета-космик оборонасы ракеталары, үтә югарытавышлы ракета йөртүчеләр өчен двигательләр ясау.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Бары тик «эш өчен» генә төшерелгән кадрлар
Яшерен космик кинооператор кинематография «Ника»сын нәрсә өчен алган

10. Чөгә балыгы, бал суы һәм су чаңгысы
Беренче космонавт Татарстанда ничек ял иткән

12. Кузгалдыкмы? Алга!
Корабльләрне космоста тоташтыру җайланмасын кайсы шәһәрдә ясаганнар

14. Айга кадәр – кул сузымы гына
Якташыбыз Җир иярчененә очарга ничек әзерләнгән

16. Җәлил, Сөембикә, Казан...
Кече планеталар нинди исемнәр йөртә

18. Космонавтлар проспекты өстеннән очышлар
Ни өчен галәмгә очулар Минзәләдә башлана

24. Авыл музееның космик киңлекләре
Базарлы Матак космос белән ничек туганлашкан

27. Мәңгелек билгесе кергән тигезләмә
Урал Закиров – йолдызара сәяхәтләр турында

30. Тәмле булсын!
Юрий Гагаринны Татарстанда нәрсә белән сыйлаганнар

игелекле эшләр

52. Чишмә суына – Чувашстанга
«Татарстан»ның татарлар күпләп яшәгән урыннарга сәяхәте

56. Без яшәгән дөнья
Азәрбайҗаннар Татарстанда ничек яши

57. Мәгариф
Үзенчәлекле үсешле балалар ничек белем ала

58. Булачак фильмнар
Татарстан киносы алтын кинофондның бер өлеше була аламы?

64. Һөнәрле хур булмас
Галиҗәнап мич кодрәте

мәңгелек кыйммәтләр

70. Онытылмас исемнәр
«Мин яратам сине, тормыш!»

76. Тарих сәхифәләре
Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов

79. Китап киштәсе
Татар ТЮЗы директоры нәрсәләр укый

82. Татар авыллары
Тау Иленә сәяхәт

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **protatarstan.ru**

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6.03

Алексей ПЕСОШИН, Татарстанның Премьер-министры, – Казанда Хөкүмәт йортындагы киңәшмәдә:

– Ковидка каршы чикләүләр әкренләп бетереләчәк. Ә хәзергә Роспотребнадзорның контроль рейдларын дәвам иттерергә кирәк. Коллектив иммунитет формалашмый, массакүләм вакциналаштыру үткәрми торып, чикләүләрне бетерү мөмкин түгел. Республикада 153 пунктта вакцина ясыйлар, шуның өчтән бере – мобиль пунктлар.

22.03

Людмила ПУЧКОВА, Кырымның Бакчасарай районы хакимияте башлыгы:

– Татарстанның ярдәмен төрле яклап тоябыз. Сезнең республика безгә мәгариф системасы объектларының тиешле рәвештә эшләвен тәэмин итүдә, су челтәрләрен реконструкцияләүдә, мәдәният йортлары төзелешендә матди һәм методик ярдәм күрсәтә. Тулаем алганда, районга 150 миллион сумнан артык акча килде.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

5.03

Владимир ЧАГИН, «КАМАЗ-мастер» командасы җитәкчесе, «Дакар» раллиеның күп тапкырлар җиңүчесе, – хатын-кызларны яз бәйрәме белән котлаганда:

– Төрле илләрдән ир-егетләр җыелганда, һәркайсы үзләренең хатын-кызларын мактый: немецлар – үзләренекен, америкалылар – үзләренекен, чехлар – үзләренекен. Әмма без иң матур хатын-кызлар Россиядә, диюгә, барысы да тынып кала, чөнки каршы әйтер сүзләре юк.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

акыллы гамәлләр /

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Кинооператор Мәхмүт Рафыйковны **НИНДИ** кадр атаклы иткән

КАЙСЫ космонавт галәмгә бер мәртәбә дә очмаган

Галәмгә юл **НИ ӨЧЕН** Минзәләдә башлана

Урал Закиров **НИЧЕК** йолдызара сәяхәтчегә әверелә

Юрий Гагаринны Татарстанда **НӘРСӘ** белән сыйлаганнар

PRESSA

АЧКЫЧНЫ

«Ачкычны стартка!» командасы, Гагаринның «Кузгалдык!» дигән сүзләре һәм бәхет-шатлыктан акылын җуйган дөнья – «Галәмдә – кеше!». Космик вакыт күзлегеннән караганда, бу вакыйга әле кичә генә – 1961 елның 12 апрелендә була. Аннан соң бик күп очышлар оештырыла. Кеше Айга аяк баса, Марска очарга әзерләнә, ләкин космоска кешелек дөньясы өчен сукмак салган Гагарин һәм совет иле мәңгегә беренче булып калачак. Һәм беренче космик очышлар вакытында ук туган традиция – Җиргә әйләнеп кайткан экипажга теләсә кайсы очышка старт бирә торган ачкычны бүләк итү дә юкка чыкмаячак.

Фото: Сергей Головкин

СТАРТКА!

«Татарстан» да традицияне бозмаска булды – Юрий Гагаринның галәмгә очуының 60 еллыгына без үз укучыларыбызга символик ачкыч тапшырабыз: беренче космонавтларыбызга кагылышлы сирәк очрый торган фактлар, космик экспедицияләр, аларны әзерләүдә катнашкан кешеләр, шулай ук безнең космик программаларның бүгенгесе һәм киләчәге турындагы мәкаләләребезне укыгыз. Космос кайда да, Татарстан кайда диярсез. Ашыкмагыз! Җир шарының тирә-ягын һәм йолдызлар дөньясын өйрәнүдә республика һәм аның кешеләре – беренче рольләрдә. Ышанмыйсызмы? Алайса – ачкычны стартка!

МӘХМҮТ РАФЫЙКОВ ТОРМЫШЫННАН 24 КАДР*

Автор: Әскәр Сабиров

Беренче космонавтның Җиргә әйләнеп кайтканнан соң төшерелгән тәүге фотосы... Бер шул кадр гына да аны атаклы ясый алыр иде. Ләкин космоска беренче стартлар һәм атом-төш коралын сынаулар турында кыйммәтле документаль кадрларның авторын ил халкы белгәнче берничә дистә ел узачак. Һәм кинематографиядә үзенең «Ника»сын Мәхмүт Рафыйков Гагаринның галәмгә күтәрелүенең 50 еллыгын билгеләп үткәндә генә алачак...

БЕРЕНЧЕ КАДР, ШУЛ МИЗГЕЛ. 1961 ЕЛНЫҢ 12 АПРЕЛЕ

Һава көчләренә каршы оборона хәрби часте Саратов янындагы Энгельс шәһәрендә урнашкан. Бирегә әле кичә генә өлкән лейтенант, бүген инде майор булган Гагарин фамилияле берәүне алып киләләр. Герой уйчан, дулкынлануы да сизелә. Чәчләре тузгыган – күрәсең, скафандрдагы тынчу-эсседәндер. Кинооператор Мәхмүт Рафыйков Сергей Королёвның күрсәтмәсен үтәргә тиеш: «Космонавтны Җиргә төшүгә үк төшерергә, озын-озын кисәкләр белән – кинотасма буенча аның психологик һәм физик халәтенә бәя бирерлек булсын». Төшереп бетерүгә, Рафыйков камерасын читкәрәк алып куя. Профессионал буларак үзендә канәгатьсезлек сизә – нәрсәдер җитеп бетми. Һәм шулчак телефон шалтырый – чыбыкның икенче очында Брежнев – СССР Югары Советы Рәисе: беренче космонавт белән сөйләшергә тели. Рафыйков тагын камерасына ябыша: уңышлы төгәлләнгән очыш турында ил җитәкчесенә җиткергәндә космонавтның йөзе яктырып китә, кояштай елмаюны соңрак Гагарин елмаюы дип атаячаклар...

Әлбәттә, төшерелгән материалларны халыкка чыгармыйлар, дәүләт сере, бары тик «эш өчен» генә кулланачаклар. Шулай да кинотасмадан бер кадрны бастыралар – Гагаринның нәкъ шул елмаюы чагылыш тапканын. Фотоны Советлар Союзының барлык үзәк газеталарында бастырып чыгаралар. Фото авторының фамилиясен атамыйча. Әлеге фамилия шулай ук – дәүләт сере.

ИКЕНЧЕ КАДР. ХӘЛИТКЕЧ. ГАГАРИН СТАРТЫНА КАДӘР 16 ЕЛ ЭЛЕК

Сугыштан соңгы беренче җәй. Мәскәүдәге Орлик тыкрыгында Григорий Александров «Весна» музыкаль комедиясен төшерә. Мәхмүт массовкада катнаша – чакырудан баш тарта алмый, чөнки чакыручылары «бигрәк матур туташлар» була. Кино төшерү мәйданчыгында күргәннәреннән Рафыйковның исе-акылы китә: «Бик матур эпизод иде. Бөтен җирдә музыка яңгырый, матур актёрлар, янәшәдә генә сөйкемле балериналар бии...»

Ул чакта МАИда укыган Рафыйков, бөтен ихтыяр көчен туплап, документларын ВГИКка илтә. Ул фотография, музыка, рәсем белән шөгыльләнә һәм хәзер инде шуны тәгаен аңлый: аның язмышы – күңелле музыкаль фильмнар төшерү. Әмма ВГИКта аның хыялын уртаклашмыйлар. Тик Мәхмүт тә үҗәт: икенче елга да килә. Конкурс комиссиясенә үзенең эти-әнисенең фотосын тәкъдим итә, үзе әйткәнчә, «Рембрандт стилендә». Һәм тагын – тугани абыйсының чалма киеп төшкән фотосын. «Ул вакыт өчен тугани абыем дингә чын күңелдән ышанган мөселман иде», – ди ул...

Комиссиянең карары: кабул итәргә.

ӨЧЕНЧЕ КАДР. ЭКСКЛЮЗИВ. 1961 ЕЛНЫҢ 12 АПРЕЛЕ

Юрий Гагарин утырган «Ил-18» очкычы Куйбышевка (хәзер – Самара – ред. иск.) юл ала. Куйбышевта беренче космонавтны каршы алу тантанасына әзерләнәләр. Гагарин самолёттан беренче булып чыгарга тиеш: әлеге тарихи мизгелне төшерү өчен атаклы һәм исемнәре сер саналмаган фотографлар һәм операторлар төркеме җыела. Энгельстан Гагарин белән бер очкычта очып килгән Рафыйковка язмыш үзе елмая кебек... Әмма – ярамый!

Кызганыч. Аның каравы Рафыйков космонавтны юлда, очыш вакытында төшерә ала. «Эш

* Секундына 24 кадр – кинематографиядә кино төшерү стандарты.

өчен» кулланылырга тиешле фильмнан кадр: Гагарин самолет кәнәфиендә. Арыган, эмма, мөгаен, очыштан соң беренче мәртәбә аз гына ял итеп алган халәттә...

Плёнкага төшергәннән соң, Мәхмүт космонавтка үзенең күпне күргән блокнотын суза: «Юрий Алексеевич, автографыгызны бирегез әле, зинһар».

Космонавт каршы килми. Гади генә итеп: «Оператору» дип язып куя. Иркенләп имзасын төшерә һәм, «12.04. 61 год» дип, датасын да өсти.

Тарихи очыштан соң Гагарин тарафыннан бирелгән беренче автографтыр бу, мөгаен. Рафыйков аны гомере буе саклый.

ДҮРТЕНЧЕ КАДР, ЯШЕРЕН. ГАГАРИН СТАРТЫНА КАДӘР 10 ЕЛ ЭЛЕК

Рафыйковның күңелле музыкаль фильмнар төшерү турындагы хыялына бер генә адым кебек. Дөрес, укуын тәмамлаган белгечне эшкә фәнни-популяр фильмнар киностудиясенә билгелиләр. Чын хыял өчен билгеләнгән урында өч ел мәҗбүри эшләү нәрсә инде ул? Хәзерге реклама паузасы кебек.

Бик тиздән Мәхмүтне кадрлар бүлегенә чакырталар. Төз гәүдәле иптәш табышмаклар белән сөйли:

– Егет, сез безнең эшкә туры киләсез. Без нәрсә әйтәбез, шуны төшерергә кирәк булачак...

Иптәшнең каян килгәнлегенә төшенү авыр түгел, әлбәттә. Мәхмүт тәкъдимнән матур гына итеп баш тартып карый. Әңгәмәдәш тә серле генә елмаеп, Советлар Союзы картасына күз салырга тәкъдим итә:

– Күрәсеңме, әнә тегендә Магадан? Бик ерак дип уйлыйсыңмы? Чынлыкта бик якын ул...

Сталин әле исән, Рафыйковның планнарына Магадан бөтенләй керми. Ризалык бирергә туры килә.

БИШЕНЧЕ КАДР, ХӘЛИТКЕЧ. «ВОСТОК» СТАРТЫ АЛДЫННАН

Кеше утырткан беренче космик корабль иртәгә галәмгә күтәрелә дигән көнне «Моснаучфильм» киностудиясе директоры Михаил Тихоновка Сергей Королёв шалтырата. Беренче космонавтның җиргә төшеп утыруын беренче булып каршы алырга тиешле эзләү төркеме белән операторлардан кемне җибәрәселәре белән кызыксына.

– Мәхмүт Рафыйков булачак, – дип җиткерә Тихонов.

– Юк, башка кеше кирәк – дип аптырашта калдыра әңгәмәдәшен Королёв. Һәм беркавым торганнан соң, өстәп куя. – Сезнең Мах исемле операторыгыз бар, шуны җибәрегез.

Генераль конструкторның тоны каршы әйтерлек түгел.

– Соң Рафыйков шул Мах бит инде! – дип, сөенеченнән нишләргә белми Тихонов. Чөнки баш конструкторга каршы килү үзенә кыйммәткәрәк төшәргә мөмкин.

Иптәшләре арасында Мах булып йөргән Мәхмүт шулай итеп командировкага әзерләнә, иң җитди күрсәтмәләрне («озынозын кисәкләр белән төшерергә») турыдан-туры Сергей Павловичның үзеннән ала. Һәм Королёвның феноменаль хәтеренә гаҗәпләнеп туя алмый. Соңгы тапкыр алар ун еллап элек – ракета полигонында очрашкан була.

«Эш өчен» төшерелгән фильмнан кадр: Гагаринның очыштан соң беренче мәртәбә бераз гына ял итеп алган мизгеле.

АЛТЫНЧЫ КАДР, СТРАТЕГИК. ГАГАРИН СТАРТЫНА КАДӘР 10 ЕЛ ЭЛЕК

Эштә куллану өчен «номерлы» (яшерен дип укы) фильмнар төшерүче төркем Ярославль вокзалыннан билгесез юнәлештә чыгып китә. Товар поездына тагылган вагонда. Биш профессиональ оператор һәм тагын берәү – әлегә ассистент – Мәхмүт Рафыйков. Бер көннән инде билгеләнгән урынга барып та җитәләр – Капустин Яр дип аталган ракета полигоны икән, бирердә Р-2 баллистик ракетасын сыныйлар.

Операторлар ракетаны ничек итеп очышка әзерләүләре, аның ничек очып китүен төшерәләр. Барысы да җирдән эшләнә, еш кына – бункердан. Көтмәгәндә яңа боерык куела: ракетаның стартын самолёттан төшерергә. Операторлар бердәм рәвештә баш тарталар: һавада бункер юк бит... Аның каравы яшь ассистент бар, җитмәсә МАИда да укыган – менә ул очсын!

Ассистент каршы килми: аның өчен бу форсат! «Аймо» – КС-50б кинокамерасын (аның белән фронт операторлары төшергән) элэктерә дә самолётка кереп утыра.

«Шаккатырасым килгәндер, – дип сөйли күп еллар узганнан соң бу турыда Мәхмүт Рафыйков. – Мин әле генә ВГИК тәмамлаган егет, берсеннән-берсе кыю идеяләр белән янган чак. Башта бернинди ди калыплар юк. Секундына 48 кадр режимында төшерергә карар кылдым, гадәттәге 24 кадр урынына. Бу ракетаның стартын һәм очышын акрынайтылган темпта күрсәтергә мөмкинлек бирә...»

Королёв Рафыйковның эшен югары бәяли: «Алга таба да бу егет төшерсен».

Хәзер самолёттан төшерү – гел Мәхмүтнеке. Әлеге кадрлар ракеталарны очыру турындагы фильмнарны бизи, аларны исә Югары Совет Рәисе үзе карый, дип сөйлиләр. Ләкин яшерен фильмнарда операторның фамилиясе күрсәтелми – кирәге дә юк.

Аның каравы һәрвакыт операторны чыннан да коточкыч куркыныч булган урыннарга җибәрергә була. Яңа яшерен фильмнар төшерү фонында баллистик ракеталар старты – бер уен, мавыгу кебек.

ҖИДЕНЧЕ КАДР, ТӘМУГ. ГАГАРИН СТАРТЫНА КАДӘР 7 ЕЛ ЭЛЕК

Семипалатинскидагы атом-төш полигоны – «Сакал» (Игорь Курчатовны үзара шулай дип йөртәләр) хуҗалыгына Рафыйковны 1954 елда командировкага җибәрәләр. Ту-16 самолётына атом бомбасын китергәнне төшергәндә Мәхмүт иң нәтиҗәле ракурсларны сайлый. Төшерүнең иң яхшы ноктасын табу өчен, хәтта аның өстенә дә менеп утыра. Әмма Рафыйковны барыбер башка нәрсә өчен чакыралар – самолёттан төшерү белгече буларак. Һәм яңа күрсәтмә – атом-төш шартлавын иң югары ноктадан төшерергә.

Бөтен тирә-юньне ниндидер гайре табигый ак төскә күмгән күзне чагылдыргыч көчле шартлау – Рафыйков кинокамера объективы аша бу тәмуг утын әнә шундый итеп күрә, аларның самолёты шартлау ноктасыннан биш кенә чакрым ераклыкта була. Мизгел эчендә гөмбә барлыкка килә, аның эшләпәсе бик тиз зурая бара... Һәм шартлау дулкыны самолётны читкә атып бәрә. Шулай да очучылар машинаны һавада тотып кала, ә Рафыйков беренче хәрби чыныгуын ала: объективның окуляры аздан гына аның күзен чыгармый кала... Ләкин ул эшен дәвам итә, гражданский кием кигән иптәш, аның иңбашына кулын салып: «Сез үз эшегезне башкардыгыз, ял итегез» дигәнче, төшерүен дәвам итә.

Әлеге шартлауны, шулай ук башка атом һәм термик атом-төш шартлауларын (ә алар аның биографиясендә кырыктан артык) камерага төшергәндә Рафыйков күпме күләмдә нурланыш алгандыр – беркем белми. Соңрак аларга бирелә башлаган «карандашлар» бер үзенчәлеккә ия була. Приборның угы максималь билгегә килеп җитүгә, күрсәткечләр нульгә әйләнә. Менә шундый «нуль»ләр белән гадәттә очыштан кайталар да.

Ул үз эшен башкара. Мөгаен, бер нәрсәгә генә үкенгәндер. Чираттагы «фәләненче номерлы» үлем «эшләнмәсен» төшергән вакытта бик еш кына аның боларның барысын да тудырган кешеләрне төшерергә хокукы булмый.

СИГЕЗЕНЧЕ КАДР, БУЛМЫЙ КАЛГАН. «ВОСТОК»НЫҢ ОЧЫШЫНА КАДӘР 10 ЕЛ ЭЛЕК

Ракеталарның очып китүен төшерүче кинотөркем режиссёры, күрәсең, яхшы психолог та булган. Сергей Павловичның Рафыйковка карата хәерхаһлы мөнәсәбәтен күреп, сорап куя: «Карале, иртәгә без Королёвны ракета янында төшерәбез, ә ул һаман ниндидер иске кепкадан йөри. Берәз рәтлерәк нәрсә кияргә киңәш биреп кара әле!»

Рафыйков ризалаша һәм икенче көнне, Королёв цехта пәйда булуга, аның янына килеп сүз башлый: «Сергей Павлович, зинһар өчен, башка кепкагызны киегез әле, монысы кинога төшерү өчен бармый. Башыгызга бөтенләй кимәсәгез дә була...»

Операторның сүзләреннән аптырап калса да, Королёв ачуланмый. Матур гына итеп еракка – «дядя Васяга» җибәрә. Чын «дядя Васяга». Янәсе, менә аны төшерегез, ул эшен бетерү өчен ике тәүлек буена ракета яныннан китмәде дә. Ә Василий гап-гади эшче була, әмма алтын куллы.

Икенче яктан карaганда, бәлки, менә нәкъ шушы очрак аркасында Королёв оператор Махны әллә ничә еллар үткәч тә искә төшерерлек итеп хәтерендә калдыргандыр да?

ТУГЫЗЫНЧЫ КАДР. КӨЧЛЕ РУХЛЫЛАР ӨЧЕН. ГАГАРИН СТАРТЫНА КАДӘР 7 ЕЛ КАЛА

1954 елның октябре. Атом-төш заряды – 15 метр биеклектәге корылмада. Берничә километрлы радиус тирәсендә – хәрби техника һәм баганаларга бәйләнгән хайваннар. Операторларның бурычы – тирә-юньдәге бөтен нәрсәнең ничек тузанга әйләнүен төшереп өлгерергә. Ләкин нәрсәдер була: атом-төш шартлавы һәм күзләрне чагылдыргыч яктылык урынына – җиңелчә генә шартлау һәм нәзек кенә төтен томаны.

«Сакал», Игорь Курчатов, кәефсез. Ни өчен барып чыкмаганын белү өчен шартлау буласы урынга галимнәрне җибәрү аларны үлем куркынычы астына куюга тиң... Бер вариант тәкъдим ителә: барып чыкмаган шартлау урынына вертолётта операторны җибәрергә – анда нәрсә барганын төшереп кайтсын. Үзе теләүчеләр кирәк – бомба шартламас дип кем гарантия бирә? Барысы да Рафыйковка карый. Ничек баш тартасың инде?

Төтен чыгып торган объект өстеннән вертолёт ун минут әйләнеп йөри, аннан һавада эленеп тора, тагын әйләнә. Рафыйков ун минут дәвамында төшереп булган бар нәрсәне күз уңыннан ычкындырмаска тырыша. Китәр алдыннан очучыдан вертолётны тагын да түбәнгәрәк төшерүен сорый, тегесенең сабырлыгы бетә – әйтәсе сүзләрен кызганып тормый. Игътибар итеш юк, иң мөһиме – барысы да төшерелә!

Берничә айдан соң Рафыйков әлеге вертолёт командиры белән ашханәдә очраша. Очучы сорау бирә:

– Сине нәрсә белән бүләкләделәр?
– Бүләкләмәделәр.
– Ничек? Ә миңа Герой исеме бирделәр...

УНЫНЧЫ КАДР, РАДИОАКТИВ. ГАГАРИН СТАРТЫНА КАДӘР 3 ЕЛ КАЛА

1958 елның җәе. Оператор да, режиссёр да Мәхмүт Рафыйков дөньяда беренче мәртәбә атом су асты көймәсен сынау турында фильм ясарга тиеш. Панораманы төшерә. Кинәт шуны күреп ала: кешеләр көймәдән кирегә йөгерә. Эш көне тәмамлана, дип уйлап куя Рафыйков һәм төшерүен дәвам итә. Особист килеп, бөтен нәрсәне ташлап, территориядән чыгып китүен таләп итеп кычкыра башлаганчы эшли ул. Кинотасма белән киноаппаратны оператор ташламый, штативтан гына баш тарта. Ә проходнойда аны инде ак халат кигән кешеләр каршы ала. Киемнәрен яндыралар, үзен кайнар душ астына кертәләр...

Су асты көймәсендә радиация чыгуы аның өчен эзсез үтми: нурланыш авыруы ала. Шуның аркасында берничә елын хастаханә палаталарында үткәрә, һәм аннан чыкканда медикларның киңәше мондый була:

– Бәлки, сезгә инвалидлык алу яхшырактыр?

– Юк-юк! Минем хатыным бик чибәр, ә мин инвалид булыйммы?

Идарә ителешле очышлар башланыр алдыннан Рафыйков янә сафта була инде.

УНБЕРЕНЧЕ КАДР. КОСМИК, ӘММА ҖИРДӘ ТӨШЕРЕЛГӘН

1961 елның 12 апреле. Рафыйков вертолётта Гагарин төшеп утырасы урынга оча, күзләрен талдыра-талдыра көтелгән парашютны эзли. Барысы да шуны аңлый: Юраны төшеп утырганнан соң беренче булып табу форсаты миллионга бер. Эзләү районы (анысын да соңгы моментта гына ачыклыйлар) – Куйбышевтан Саратовка кадәр...

Форсат килеп чыкмый: Гагаринның галәмдә 108 минут булганнан соң, җирдә атлаган беренче адымнарын беркем дә төшерә алмый. Рафыйков гомере буе шуңа үкенәчәк. Әмма беренче космонавт турында, ул җиргә әйләнеп кайтканнан соң ярты сәгать үткәч оператор тарафыннан төшерелгән документаль кадрлар тарихка кереп кала. Шулай ук Рафыйков тарафыннан соңрак, башка уңайдан төшерелгән йөзәрләгән метрлы кадрлар кебек үк: анда Андриян Николаев, Павел Попович, Валентина Терешкова, башка совет космонавтларының әзерлек, старт, җиргә төшү мизгелләре чагылыш тапкан.

УНИКЕНЧЕ КАДР. ҖИҢҮЛЕ. ГАГАРИН СТАРТЫННАН СОҢ 50 ЕЛ ҮТКӘЧ

2011 ел. Мәхмүт Рафыйковка кинәт кенә «Ника» милли кинопремиясен тапшыралар – Гагаринның галәмгә очуына 50 ел тулу хөрмәтенә «Россия кинематографына гаять зур өлеш керткәне өчен». Халыкка озак еллар дәвамында бары тик «эш өчен» генә дип билгеләнгән кадрларны тәкъдим итәләр, аларны Рафыйков үзе дә беренче тапкыр күрә. Дөрес, барысын да күрсәтеп бетермиләр – хәтта 180 метрлы «гагаринлы» тасмадан да, оператор сүзләренә караганда, бары тик 35е генә «ачыла». Әлеге кыйммәтле кадрлар Сергей Павлович Королёв исән вакытта ук күрсәтелгән «Йолдызларга беренче рейс» документаль фильмына кертелә.

Генераль конструктор кызы Наталья Королёва болай ди:

– Минем буын кешеләре үзләрен бәхетле дип саный ала. Чөнки без яңа космик эраның шаһитлары булып торабыз. Ә Мәхмүт Мөхәммәтҗанович – бигрәк тә бәхетле. Ул шаһит кенә түгел, ул бу бөек эшләрдә катнашучы да. Ул әлеге зур һәм мөһим эшләрне башкарган беренче космонавтларны, конструкторлар – минем әтием һәм аның хезмәттәшләрен, фикердәшләрен төшергән кеше.

«Ника» милли кинопремиясен Мәхмүт Рафыйковка Россия кинематографына гаять зур өлеш керткән өчен тапшыралар.

13-24 НЧЕ КАДРЛАР. АЕРУЧА ЯШЕРЕН. ЧИТ КҮЗЛӘРДӘН ЕРАК

Әлеге кадрларда нәрсә – безгә әле моны беләсе бар. Әгәр безгә язмаган булса, димәк, балаларыбызга, оныкларыбызга. Мәхмүт Рафыйков космодромнарда, атом-төш полигоннарында һәм космонавтларның Җиргә төшеп утыру урыннарында төшергән кадрларның күбесе бүгенге көнгә кадәр Оборона министрлыгы архивлары киштәләрендә «Катгый сер» дигән язу белән саклана.

Мәхмүт Мөхәммәтҗанович Рафыйков (1924-2018). Кинооператор-документалист. Әти-әнисе чыгышлары белән Татарстанның Арча районыннан. Беренче совет ракеталарын кинотасмада мәңгеләштерә. Беренче мәртәбә атом бомбасы шартлавын, беренче водород авиабомбасын сынауны, беренче су асты атом бомбасы шартлавын, очыштагы самолет юнәлешендә беренче тапкыр атом-төш ракетасын җибәрүне һ.б.ларны самолётта очкан килеш төшерә. Илдә беренче атом су асты көймәсен төзү һәм сынау турында фильм ясый. 1961 елның 12 апрелендә Җиргә әйләнеп кайтканан соң Юрий Гагаринны беренче булып кинотасмага төшерә. Рафыйков – космонавтлар һәм космик очышлар турында документаль фильмнар ясаучыларның берсе. СССРның дәүләт бүләкләре белән бүләкләнмәгән.

ЮРИЙ ГАГАРИН
ТАТАРСТАНДА НИЧЕК ЯЛ ИТКӘН

Автор: Михаил Рябинин



Боровое Матюшино бистәсендәге «Идел» лагерена килгән һәркемгә җирле «изге урынны» – кайчандыр Юрий Гагарин тукталган тыйнак кына бунгалоны күрсәтми калмаганнар.

Планетаның беренче космонавты Казанга 1967 елның августында совет һәм япон яшьләре дуслыгы фестиваленә җибәрелә. Шундый абруйлы чарага Гагаринны китертүгә, кайберәүләр әйтүенчә, бары тик ул чакта ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре булган Рәис Беляевның энергиясе һәм үҗәтлеге нәтиҗәсендә генә ирешелә. Кинохроника кадрларында һәм газеталардагы фотоларда Юрий Алексеевичның Татарстанга сәфәренең рәсми мизгелләрен күрергә мөмкин: менә ул, форма кигән, күкрәгендә – Герой Йолдызы, спорт сараена җыелган фестиваль кунакларын трибунадан сәламли. Икенче кадрда – шулай ук формада, алдынгы совет һәм япон яшьләре белән аралаша... Әлбәттә, сәфәрнең рәсми булмаган өлеше дә югары дәрәҗәдә оештырыла: Татарстанда һәрвакыттагыча кунак итә беләләр. Ә инде ил күләмендә халык мәхәббәтен яулаган Юраны тиешенчә кунак итү дигәндә, нинди шик булуы мөмкин?! Дөресен әйтик, Гагаринның фестивальдән тыш ялы ничек оештырылуы турында дистә еллар беркем дә берни дә белми диярлек: СССРда мондый эксклюзив мәгълүмат җиде йозак астында саклана.

«ҺӘМ МИНЕМ ИСӘПКӘ БИШ ШЕШӘ ШАМПАН ШӘРАБЫ...»

Җиде йозак астында булса да, бер фотосурәт дөньяга чыгып өлгергән: анда Юрий Гагарин Боровое Матюшинодагы бунгалосының ишек төбендә утырып тора. Фотоның авторы, «Комсомолец Татарии» басмасының фотохәбәрчесе, соңрак әйтәчәк – кирәкле вакытта кирәкле урынга ул очраклы рәвештә генә килеп чыга: Идел яры буйлап барганда, коймадагы тишектән, кысыла-кысыла, бер-бер артлы Рәис Беляев белән Юрий Гагаринның чыгып баруын «эләктерә»... Шундый мизгелдә журналист белән очрашуга гаҗәпләнә алар, әмма куып җибәрмиләр. Фотохәбәрче сөйләвенчә, ул үз күзләре белән күргән – буфетта ике шешә шампан шәрабы сорап мөрәҗәгать итүченең Гагарин ҮЗЕ икәнлеген аңлаган сатучы хатын гаҗәпләнүдән сүзен әйтә алмый тораташтай ката. Ул арада Беляев, инициативаны үз кулына алып, биш шешә шампан шәрабын үз исәбенә язып куярга куша...

Ул көнне очраклы гына төшерелгән сурәтнең газета битләренә шулай ук очраклы рәвештә килеп эләгүе бик шикле, әлбәттә. Мондый фотоны халыкка чыгарырга рөхсәт биргән җаваплы иптәшләр акыллы фикер йөртә: тыйнак бунгало янында утыручы Гагаринга карата халыкның яратуы тагын да артачак. Янәсе, менә бит, Җирнең беренче космонавты, ә үзе яшьләр форумының гади катнашучылары сыман гади шартларда яши, өлкә комитет апартаментларында түгел...

ТУЛЫ БӘХЕТ ӨЧЕН БЕР СТАКАН БАЛ

Шулай да, әйдәгез әле, космонавтның Татарстандагы сәфәренең ят күзләрдән яшерелгән мизгелләренә әйләнеп кайтыйк. Фикрәт Табиев, ул заманда республикада беренче кеше (КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре. – Ред. иск.), берничә ел элек, вафатына берникадәр вакыт кала биргән интервьюларыннан берсендә, Гагарин сәфәренең рәсми булмаган өлеше турында да сөйли.

Фото: Владимир Зотов

Боровое Матюшинодагы обком резиденциясендә Гагаринны зурлап кабул итәләр. Идел буйлап берничә сәгать катерда йөреп кайталар (юлның күбрәк өлешен космонавт катер артыннан су чаңгысында җилдерә). Тәмтедә ял иткәндә, Табиев сөйләвенчә, Юра балыкчылар бригадасының чөгә балыгын тотуларын күзәтә, ухадан авыз итә, җирле колхозчылар белән аралаша һәм хәтта җирле үзешчән артистлар концертын да карый... Ветеран хатирәләренә ышансак, кыскача гына әйткәндә, хуҗалар әнә шундый ял программасы әзерли Гагаринга.

Тарихта калган 1967 елның август вакыйгалары хроникасын Фикрәт Табиев озак еллар узгач күңелендә яңарта һәм, бәлки, кайбер мизгелләр аның хәтереннән инде сызып та ташлангандыр. Ничек кенә булмасын, ул бары тик ике генә конкрет эпизодны исенә төшерә. Беренчесе – Гагаринны өлкә комитет резиденциясендә бал белән сыйлаулары турында.

«Мин бер бидон бал китертергә куштым. Юра моны күрде дә: «Миңа бер стакан бал ярыймы?» – ди. «Әлбәттә, ярый, әмма бу бик көчле эчемлек, аннан соң салкын су эчәргә һич ярамый!» Әмма ул барыбер авыз итте...», – дип сөйли Табиев.

Фикрәт Әхмәтҗан улы искә алган «бал» чынлыкта «медовуха» дип йөртелгән эче бал булгандыр. Бер стакан гади балны Гагарин бер утыруда эчеп бетерә алмас иде, мөгаен, аннан Табиевның «бик көчле эчемлек» дип сыйфатлавы да сүзнең нәкъ менә эчә торган бал турында баруына ишарәли.

Ә менә элеккеге партия секретаре искә алган икенче бер эпизод, йомшак итеп әйткәндә, шик тудыра. Аның раславынча, Гагарин, шук кеше буларак, Татарстанда да мөгез чыгармый калмый: елга буйлап сәяхәт иткәндә ул яхшы ук тизлек белән барган суднодан Иделгә сикерә – арттан баручы сак катерлары чак кына читкә китеп өлгерә... Бу «геройлык» турындагы хатирә, мөгаен, дистә еллар узгач кына барлыкка килгән һәм тулысынча авторның фантазиясе җимешедер. Өстәвенә, сөйләнгән вакыйгада тагын төгәлсезлекләр бар. Мәсәлән, катер штурвалында, янәсе, ул үзе – өлкә комитетының беренче секретаре булган...

СУ ЧАҢГЫСЫ ҺӘМ ЯТЬМӘДӘГЕ ЧӨГӘ БАЛЫГЫ

Табиевның әлеге әңгәмәсен электрон мәгълүмат чараларыннан укыгач, Кама Тамагы район газетасы хезмәткәрләре уйга калган: әгәр Гагарин дөрестән дә ерак 1967 елда Тәмтедә кунак булса, бу вакыйганың тере шаһитләре булырга тиеш бит. Әмма Тәмтедә беренче космонавтның кайтуы турында хәтерләүче-белүче табылмый. Бәлки, Гагарин Тәмтедә бөтенләй булмагандыр да?

Ә менә Красновидово авылында шаһит табыла. Газетада Александр Камонин хатирәләре басыла: «1967 елда Горький исемендәге колхозның рәисе Тимофей Сомов иде. Ул иртәдән үк кисәтте: безгә Гагарин үзе киләчәк, балык әзерләп куярга кирәк, кунакларга утрауда уха пешерәчәкләр. Иртәнге 9да утрауга чөгә балыгы илттек. Хатыннар казанны ялтыраганчы юып чистартты, балыкны ухага әзерләде. Тимофеей Александрович белән без кире кайтып киттек, соңрак яңадан килдек. Безнең белән милиционерлар да барды. Бераздан утрауга якынлашкан катер да күренде. Аның артыннан су чаңгысында Юрий Гагарин һәм ВЛКСМ ҮК беренче секретаре Сергей Павлов җилдерә иде. Алар безгә «Идел» лагереннан шул рәвешле килеп җиткән. Сай сулы урынга җиткәч, тросларын ташладылар да, чаңгыларын салып, утрауга җәяү килеп керделәр.

Бу вакыйгага кадәр мине колхозның парторгы итеп куйганнар иде. Утрауга минем белән тагын берничә кеше килде. Әмма безне кунаклар янына бик якын китермәделәр. Милиционерлар саклап кына торды. Без берникадәр читтәрәк үз күзләребез белән Юрий Гагаринны күрә алуыбызга сөенеп утырдык. Кунаклар уха ашап алгач, Юрий Алексеевич балыкчылардан эш тәртибен күрсәтүләрен сорады. Аны Геннадий Кокуев көймәсенә утырттылар, һәм алар ятьмәләрне карарга китте».

Александр Левин, Красновидово мәктәбенең элеккеге директоры, Гагарин турында әнә шул балыкчы Геннадий Кокуев сөйләгәннәрне искә төшергән: «Без көймәдә йөзеп килдек тә ятьмәләрне барлый башладык. Балыкны көймәгә алып салабыз, алар төптә сикерешә. Кинәт бер корбан балыгы сикерде дә суга чумды. Ә Гагарин аның артыннан ук елгага сикерде һәм тотты да бит. Бик җитез булып чыкты...»

Аннан Гагарин һәм башка кунаклар Антоновка ягына юл тоткан. Анда, Антоновка авылының гүзәл табигатендә, аларны инде Кама Тамагы район кулланучылар җәмгыяте пешекчеләре көтеп торган. Юрий Алексеевичка төшке аш әзерләүчеләр арасында яшь кыз Рита Мөхәммәдиева да булган (аның Гагарин белән очрашуы турындагы хатирәләре, космонавтка төшке ашка әзерләнгән ризыкның рецепты безнең «Аш-су» рубрикасында, 30 нчы биттә).

Ә Тәмте? Табиев ялгышканмы, Гагарин Тәмтегә барып җитмәгәнме? Фикрәт Әхмәтҗанович белән аның йолдызлы кунагы анда да булгандыр, мөгаен. Әмма Тәмтенең үзендә түгел, алмагач бакчасы белән уратып алынган аучылар йортында. Бу урын Идел ярында, авылдан ике чакрымлап ераклыкта урнашкан, биредә Табиев еш кына ял итәргә яраткан. Аучылар йорты янынннан аккан чишмәдә шампан шәрабы бик шәп суынган...

P.S. БЕРЕНЧЕ КОСМОНАВТ ТУКТАЛГАН БУНГАЛОНЫ 1990 НЧЫ ЕЛЛАР АЗАГЫНДА СҮТӘЛӘР. БЕРНИЧӘ ЕЛДАН ЛАГЕРЬ ҮЗЕ ДӘ ЮККА ЧЫГА. ЯНӘШӘДӘ БАШКА «ИДЕЛ» – ЯҢА, ЗАМАНЧАСЫ ТӨЗЕЛӘ. ӘММА БУ ИНДЕ – ТАРИХСЫЗ «ИДЕЛ».

1


2

КУЗГАЛДЫКМЫ? АЛГА!

Автор: Алсу Троицкая

Җирнең ясалма иярченеңнең беренче очышы. Кешенең беренче тапкыр галәмгә күтәрелүе. Беренче орбиталь станция. Корабльләрнең беренче мәртәбә галәмдә тоташуы... Космик киңлекләрне яулауда катнашкан предприятиеләр арасында Татарстанныкыларның аерым урын алып торуын, мөгаен, күпләр белмидер дә.

ТОТАШТЫК!

1960 нчы еллар башында Казан «Электроприбор» заводы каршына шундый бурыч куела: космик корабльләрнең автомат рәвештә тоташуын тәэмин итә торган система уйлап табарга һәм ясарга. Бу җаваплы эшне заводның иң яхшы инженер-техникларына һәм эшчеләренә ышанып тапшыралар.

«Эшне тизләтер өчен, кайтартылган тимер табаклары буенча турыдан-туры эшләдек, ялгышырга һич ярамый иде. Чөнки махсус металлургия заводларында коелган эшләнмәләр еш кына бер данәдә кайта иде, һәр хата билгеләнгән җитештерү срокларын бозуга китерергә мөмкин, – дип искә ала ул чакта инженер-конструктор, соңрак заводның баш конструкторы булып эшләгән Юрий Большаков. – Сызымнар бик катлаулы, ә үрнәкләр булмаганга, кайбер детальләрне эшләүне без эшчеләр белән бергә сызымнар буенча билгели идек – кайсы операция артыннан кайсысын һәм ничек итеп башкарырга. Аннан соң мин аның үтәлешен карыйм, һәм алга таба башкарыласы операцияне билгелибез. Ике, ә кайчак өчәр смена эшли идек...

Нәтиҗәдә – җиңү! 1967 елның 30 октябрендә дөньяда беренче мәртәбә «Космос-186» һәм «Космос-188» космик корабльләрен автомат рәвештә тоташтыру бездә ясалган гиростабилизатор ярдәмендә башкарыла!

Космик гиростабилизаторны эшләүдә һәм җитештерүдә катнашкан бик күпләр соңрак орден-медальләр белән бүләкләнә. Завод белгечләре Байконурга бер генә мәртәбә бармый. Алар анда үз хезмәт җимешләре – гиростабилизаторны беренче тапкыр галәмгә җибәргәндә дә булалар. Юрий Васильевич бу турыда болай дип искә ала: «Бөтен нәрсә гаять зур, колачлы: иксез-чиксез тигезлек, еракта утрау кебек старт мәйданчыклары, старт алдыннан Сергей Королёв һәм Юрий Гагарин яшәгән коттеджлар, космик корабльне йөртүче ракетаны җыю өчен каралган зур ангар һәм башка объектлар шәйләнә. Ул вакытта без очучы-космонавтлар Виктор Горбатко һәм Юрий Глазковны очышка озаттык. Без ракета стартын 1,5–2 км ераклыкта карап тордык. Караңгы төн иде. Ләкин ракета двигательләрен эшләп җибәреп, ул өскә күтәрелә башлагач, тирә-як көндезге кебек яп-якты булды. Көчле гөрселдәү безнең шатлыклы авазларыбызны күмеп китте. Төн уртасында барыбызны да уяттылар. Космонавт Глазков бик төпченүчән кеше иде, ул локатор экранында тоташу объекты – «Салют» станциясенең күренмәвенә борчылган. Шул сәбәпле Мәскәүдә дә барлык хезмәтләрне аякка бастырдылар. Тиздән борчылуның юкка гына булуы ачыкланды – корабль әле станциягә локатор экраннарында күренерлек якынлыкка килеп җитмәгән...

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Казан «Электроприбор» заводында җитештерелгән гиростабилизаторларның ышанычлылыгы шулкадәр зур була ки, әле 80 нче еллар ахырына кадәр космик корабльләрнең үзара һәм космик станцияләр белән тоташуы алар ярдәмендә башкарыла. Бу предприятие тарихында иң матур сәхифәләрнең берсе була.

Фотолар «Казан «Электроприбор» заводы» ААҖ һәм «КОМЗ» АҖ тарафыннан тәкъдим ителде


3

4

«ПИОН» ОЧЫШКА ӘЗЕР

1975–1977 елларда Үзәк конструкторлык бюросында һәм Казан оптика-механика заводында беренче стратосфера, орбиталь һәм планетаара оптик-электрон комплекслар һәм космик киңлекләрне өйрәнү приборлары җитештерелә. «Сатурн» автоматик кояш стратосфера обсерваториясе генә дә галәмгә дүрт мәртәбә очыш ясый.

БСТ-1 субмиллиметрлы телескобын ясау да Казан оптикларының җитди эше нәтиҗәсе була. Аны күзәтү объектына җайлауны космонавт оптик төзәү җайланмасы аша башкара. Телескопны «Салют-6» станциясендә урнаштыралар. Аның ярдәмендә космонавтлар Юрий Романенко, Георгий Гречко, Владимир Ковалёнок һәм Александр Иванченков тарафыннан йолдызларның, планеталарның, Айның һәм Җир атмосферасының спектраль һәм энергетик характеристикалары алына, Айның люминисцентлы ультрашәмәхә яктыртуы теркәлә.

Космоста озак вакыт эшләү өчен ясалган идарә ителешле «Пион-К» оптик приборлар комплексы 1985–1986 елларда «Салют-7» орбиталь комплексы составында эшли. Ул ҮКБ тарафыннан уйлап табыла һәм «КОМЗ»да җитештерелә.

Һәм «Пион-К» оптик приборлар комплексы бүген дә төзек, ул җыю цехында тора һәм орбиталь станцияләрдә кулланыла ала.

СҮЗ УҢАЕННАН

● Казан «Элекон» заводында җитештерелгән электр тоташтыргычларыннан башка «Союз»лар да, космик корабльне йөртүче ракеталар да оча алмый. Әлеге тоташтыргычлар «Луна», «Марс», «Венера» планетара станцияләрендә, Җирнең ясалма иярченнәрендә, «Салют», «Мир» орбиталь станцияләре һәм МКС конструкцияләрендә кулланыла...

● Яшел Үзәндәге «Серго исемендәге завод» (POZIS) пиропатроннары төшә торган аппараттан космонавтларга катапульта ясау өчен уйлап табылган системаның бер өлеше булып тора...

● «Бу сәгать 1975 елның 11 гыйнварыннан 8 февраленә кадәр космоста – «Союз-17» корабленда һәм «Салют-4» станциясендә булды» – совет тикшерүче-космонавты, Советлар Союзы Герое Георгий Гречконың уникаль шәхси имзасы һәм шәхси автографы Чистайдагы «Восток» сәгать заводы эшчеләренә «Амфибия» сәгате өчен рәхмәтенә дәлил...

● Татарстан предприятиеләре хәтта космонавтларны азык-төлек белән тәэмин итүдә дә катнаша – 2011 елдан Алабугадагы «Эссен Продакшн» компаниясе космонавтлар өчен әче соуслар һәм җиләк-җимеш джемнары җитештерә...

1 2011 елдан «Эссен Продакшн» компаниясе космонавтларны әче соуслар һәм җиләк-җимеш джемнары белән тәэмин итә.

2 Антеннаның гиростабилизаторлы платформасы.

3 Дүртенче космонавт Павел Попович «Пион-К» комплексы янында. 1985 ел.

4 Александр Иванченков, Георгий Гречко, Владимир Ковалёнок, Юрий Романенко «КОМЗ»да. 1978 ел.

5 Орбиталь станция.


5

Редакция Казан «Электроприбор» заводы» ААҖ тарихы музее директоры Ангелина Корбановага һәм «КОМЗ» АҖ генераль директоры киңәшчесе Сергей Черновка хезмәттәшлек өчен рәхмәтен белдерә.

Ә АЙГА КАДӘР – КУЛ СУЗЫМЫ АРА

Автор: Әскәр Сабиров

Космонавт Анатолий Воронов Айга очарга тиешле беренче кешеләр арасында була. Мөһим миссия өчен сайлап алынган бәхетлеләр командасында ул УР500К-Л1 (Ай тирәли очу) программасы буенча Л-1 корабленда әзерлек башлый. Максат аңлашыла – Айга менү узышында СССРның өстенлеген күрсәтергә кирәк. Календарьда – 1967 ел...

Генерал Николай Каманин боерыгы буенча оештырылган төркемгә иң-иңнәр генә җыелган. Алексей Леонов, Павел Попович, Валерий Быковский, Виталий Севастьянов, Алексей Рукавишников... Күбесенең галәмдә булганы бар инде. Анатолий Вороновның әле космоска очканы юк, тик аны бу өлкәдә яңа кеше дип әйтеп булмый. Космонавтлар отрядында ул 1963 елдан бирле, квалификациясе – «Хәрби-һава көчләре космонавты»: хәрби-космос программалары буенча әзерлек узган кеше. Аның орбитага 1965 елда ук, бер елга якын махсус өйрәнүләрдән соң, күп урынлы «Восход»та очу ихтималы булган (Анатолий Воронов ачык космоска чыгу күнекмәләрен Петр Колодин белән бергә үзләштергән. – Ред.иск.). Әмма көтелгәнчә булмый шул: «Восход» программасын ябалар – аңа алмашка «Союз»лар төзелә башлый...

БЕЗ БЕРЕНЧЕ БУЛЫРГА ТИЕШ!

Ай программасы, моңа кадәр булганы белән чагыштырганда, гади космос кына түгел – могҗизага тиң! Яңа ракета йөрткеч, әлегә макет рәвешендә генә булса да, яңа корабль. Ә алда бурыч-башваткычлар чылбыры, аларны хәл итмичә торып, Айга менеп җитеп булмый, Җиргә исән-имин әйләнеп кайту турында исә әйтәсе дә юк.

Төгәлрәк әйтсәң, программалар икәү. Беренчесендә пилот белән Айга очу фаразлана, икенчесе Җир иярчененә кеше төшерүне күздә тота. Америкалылар бу өлкәдә безнең аякка басып килә (кем белә – бәлки без аларны куалыйбыздыр), шуңа күрә барысы да бик зур тизлектә эшләнә: без, һичшиксез, беренче булырга тиеш!

Шул сәбәпле тренировкалар да киеренке графикта бара. Анатолий Воронов һәм аның коллегалары тәүлегенә унсигезәр сәгать эшли. Үҗәтлекләре белән тренажерларны туздыралар, орбитага кулдан төзәтмәләр кертергә, Айга төшкәндә кораб белән идарә итәргә өйрәнәләр. Мөгаен, иң еш тренировкалар – «Волчок» исемле тренажердадыр. Аның ярдәмендә космонавтлар реаль шартларда кораб белән идарә итү күнекмәләрен үзләштерә, аппарат атмосферага икенче космик тизлек белән кергәндә аларны нәкъ шундый йөкләнеш көтә. Һәр экипаж бу центрифугада 10g йөкләнеш белән, ким дигәндә, 40 әйләнеш ясый.

КУРКЫНЫЧ ҮЗӘГЕНДӘ НЫКЛЫКНЫ ТИКШЕРҮ

Космонавтлар отрядына Воронов хәрби авиациядән соң килә, шуңа күрә аны авырлыклар белән шаккатырып булмый. Психологик тотрыклылык ягыннан да барысы да тәртиптә. Нервларын 1957 елда Семипалатинск атом-төш полигонында сынаган була. Биредә өлкән лейтенант Воронов, ерак авиациянең 13 нче гвардия авыр бомбардировка авиаполкы штурманы, җиде атом-төш бомбасын сынауда катнаша. Зарядны ташлап, кичекмәстән тиешле арага ераклашу турында сүз дә бармый, ә киресенчә. Күктә куркыныч атом-төш гөмбәсе үсә башлауга, «Ту» экипажы кирәкле нокталар аша очып үтә. Штурман Вороновка бик төгәл бурыч куелган: шартлау үзәгеннән төрле биеклектәге һәм төрле ераклыктагы радиация дәрәҗәсен үлчәргә кирәк...

Шулай да Айга очу экспедицияләрен әзерләү программасында талчыктыргыч күнегүләр генә түгел, ә күңелле мизгелләр дә була. Космонавтлар йолдызлы күкне яхшы өйрәнсен өчен, әзерлек үзәгендә махсус планетарий төзегәннәр, диләр. Ә Ай экспедициясендә катнашучы кандидатлар көньяк ярымшар өстендәге йолдызлы күкне безнең төньяктагы күктәй яхшы белсен өчен, космонавтларны Африкага, Сомалига командировкага җибәрәләр...

Хезмәттәшләре арасында бердәнбер штурман булган Вороновка ориентация биремнәре, әлбәттә, җиңел бирелә – маршрут салу һәм курсны үтү осталыгы сайланган һөнәре белән бергә сеңгән. Аны гомумән гаҗәпләндерү бик авыр. Парашют белән сикерү? Бу яктан Вороновка тиңнәр юк: аның исәбендә йөздән артык сикерү, беренче разряд һәм парашют-десант спорты инструкторы исеме. Авырлык югалту шартларына әзерлек ничекме? Камил дип әйтеп була. Космонавтлар отрядына кабул ителгәнче үк, Воронов аны үзендә бик күп тапкыр сынап карый. Модификацияләнгән Ту-104А сынауларында катнашканда, авырлык югалту режимында ул 240 параболик очыш («горка») башкара! Башка кандидатлар мондый күрсәткечләр турында хыяллана да алмый.

Әзерлек белән барысы да тәртиптә, иң мөһиме – техника сынатмасын.

РАКЕТА СТАРТ ВАКЫТЫНДА УК ШАРТЛЫЙ...

Айга беренче булып аяк басарга әзерләнүчеләрне техника белән алдан ук таныштыралар. 1969 елның июле. Байконур. Космонавтлар «Н-1» югары куәтле ракетасын сынау буенча әзерлек эшләрендә катнаша. Алар 105 метрлы ракетаның иң өске ноктасына күтәрелә, ракета комплексын карый, тикшерә һәм өйрәнә. Старт 3 июль төненә билгеләнгән була.

3 июль. 23.18. Ракета акрын гына старт өстәленнән аерыла, бераз күтәрелә, һәм шулвакыт – шартлау...

«Кинәт шартлау булды, без аска йөгереп төшәргә өлгердек, һәм бу вакытта бәрмә дулкын пыялаларны койды. Ракета кире төшеп, старт мәйданчыгында шартлады», – дип искә ала ракета җибәрүне башка космонавтлар белән бергә кунакханә тәрәзәсеннән күзәтеп торган Анатолий Воронов.

Уңышсыз сынау күңелсез нәтиҗәләргә китерә. Һавада 18 секунд булганнан соң, ракета старт өстәленә егылып төшеп, старт комплексын һәм старт корылмасының җир астындагы алты катын да җимереп шартлый... Әмма очышка әзерләнүче экипажлар бу вакытта иң мөһимен белми әле. Асылда, бу вакыйга аларның өметләрен өзә. Безнең космодромдагы уңышсыз старттан соң унҗиде көн дә үтми, Айның Тынычлык диңгезе тирәсендә Американың «Аполлон-11» модуле төшеп утыра...

СССР җитәкчелеге Җир иярчененә пилотлы очыш әзерләүнең алга таба мәгънәсен күрми: Айга меңү узышында америкалыларга оттырган булабыз инде. Программа ябыла, «Л-1» төркеме таратыла...

ХУШЛАШУ «САЛЮТ»Ы

Күп тә үтми, Вороновка галәмгә очарга тагын бер мөмкинлек ачыла. 1970 елның сентябре. Анатолий Воронов, инженер-сынаучы сыйфатында, Георгий Добровольский һәм Виталий Севастьянов белән бергә дөньяда беренче «Салют» орбиталь станциясенә озак вакытлы очышка әзерләнә башлый. Бу инде дүртенче экипаж була, әмма очышлар программасы киләсе 1971 ел ахырына кадәр барлык космонавтларны да орбитага чыгарырлык итеп төзелгән. Бу юлы йолдызлар аңа хәерхаһлы кебек: 1971 елның апрелендә Воронов инде өченче экипаж составында, бу юлы ул Алексей Губарев һәм Виталий Севастьянов белән бергә. Ә аннары...

Алга таба барысы да начарлана. Воронов белән бергә әзерлек башлаган Добровольский «Салют»ка беренче экипаж составында «Союз-11»дә китә. Бу экипаж (Георгий Добровольский, Владислав Волков, Виктор Пацаев) корабны утырткан вакытта һәлак була, проблемалы «Салют»ны, 1971 елның октябрендә орбитадан чыгарып, Тын океанда батыралар, программаны ябалар...

Ә Анатолий Воронов чираттагы тапкыр яңа очышка әзерләнә башлый – бу юлы Владимир Ляхов белән. «Союз» модификацияләренең берсен сынап карау бурычы тора, Воронов – бортинженер...

Ляхов, нәтиҗәдә, өч тапкыр галәмгә оча, беренче тапкыр – 1979 елда. Шул ук елны Анатолий Вороновны сәламәтлеге начар булу сәбәпле отрядтан чыгаралар – онкология ачыклана. Шулай итеп, ул бер генә тапкыр да космоска оча алмый кала.

Звёздный шәһәрчегеннән ерак түгел, Леониха авылы зиратында, гади һәйкәл тора. Анда гади генә язу: Анатолий Федорович Воронов, космонавт.

Анатолий Федорович Воронов, космонавт-сынаучы (Хәрби-һава көчләренең икенче җыены). Гагарин шәһәренең Мактаулы гражданины. 1945 елда ТАССРның Зеленая Роща урта мәктәбен, 1948 елда Бөгелмә педагогика училищесын тәмамлый. Аргуновка башлангыч мәктәбе мөдире, ТАССРның Кече Бөгелмә җидееллык мәктәбендә математика укытучысы булып эшли. Штурманнар училищесын тәмамлаганнан соң – Хәрби-һава көчләре сафында. Атом-төш коралын сынауда катнашкан өчен Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. 60 нчы еллар башында – штурман-сынаучы. 1965 елдан 1979 елга кадәр – космонавтлар отрядында. Космос программаларын эшләүдә һәм үтәүдә актив катнашканы өчен СССР Космонавтика федерациясенең СССРның космонавт-очучысы Ю.А. Гагарин исемендәге дипломы белән бүләкләнгән.

ГАЛӘМДӘ ТАТАРСТАН ҮЗЕ

Hasantufan (Хәсән Туфан) – 48631 нче номерлы кече планета, ул Җирдән 250 млн км ераклыкта урнашкан, диаметры – өч км. 1995 елның сентябрендә Казан дәүләт университетының Зеленчук астрономия станциясендә (Төньяк Кавказ) астроном Тимур Крячко тарафыннан ачылган.

Dzhalil (Җәлил) – кече планета (№3082), 1972 елда Кырым астрофизика обсерваториясендә астроном Т. Смирнов тарафыннан ачылган. Кояштан ераклыгы 2,4 астрономик берамлектән 2,8 а.б.кә кадәр исәпләнә. Кояш тирәли әйләнү периоды – 4,1 ел.

Kazan university (Казан университеты) – кече планета (№ 46650), 1995 елның 17 октябрендә Казан дәүләт университетының Зеленчук астрономия станциясендә галим Владимир Соловьев тарафыннан ачылган. Диаметры 5 км булган планета Марс белән Юпитер арасында, Кояштан 340 млн км ераклыкта урнашкан.

Rizvanov (Ризванов) – 451138 нче номерлы планета, Казан университетын тәмамлап, шунда эшләгән профессор, астрометрия һәм күк механикасы өлкәсендәге белгеч Нәүфәл Ризванов (1930–2012 еллар) хөрмәтенә аталган.

Suyumbika (Сөембикә) – астероид (кече планета), Марс белән Юпитер арасында урнашкан. Җирдән «Сөембикә»гә кадәрге ара якынча 300 млн км ны тәшкил итә. Астероид 1994 елда Тимур Крячко тарафыннан ачылган.



Kasan (Казан) – астероид (№1316), диаметры якынча – 7 км, ул Марс орбитасын кисеп үтүче астероидлар төркеменә керә һәм S якты спектраль классына карый. Ул 1933 елның 17 ноябрендә Симеиз обсерваториясендә совет астрономы Григорий Неуймин тарафыннан ачылган.

Lobachevskij (Лобачевский) – астероидлар поясының үзәк өлкәсенә караган 1858 нче типтагы астероид, диаметры якынча – 13 км. Ул 1972 елның 18 августында Кырым астрофизика обсерваториясендә совет астрономы Людмила Журавлева тарафыннан ачылган.

Dubiago (Дубяго) – астероидлар поясының тышкы өлкәсенә караган астероид, диаметры якынча – 63 км. Ул 1930 елның 3 августында Кырым ярымутравындагы Симеиз обсерваториясендә совет астрономы Евгений Скворцов тарафыннан ачылган һәм астроном Александр Дубяго хөрмәтенә аталган.

Martynov (Мартынов) – астероид (№2376), диаметры якынча – 38 км, күренекле астроном һәм педагог, Казан университеты профессоры, ректоры (1951–1954 еллар) Дмитрий Мартынов хөрмәтенә аталган.

Belkovich (Белькович) – астероид (№179595), 2002 елда ачылган, астроном, Казан университеты профессоры Олег Белькович хөрмәтенә аталган.

Dibay (Дибай) – астероид (№2389), Казан университетын тәмамлаган күренекле совет астрономы Эрнст Дибай хөрмәтенә аталган. Астероид 1977 елның 19 августында астроном Николай Черных тарафыннан ачылган.

Ай кратерлары – унысы Казан галимнәре хөрмәтенә аталган (Banahevich, Belkovich, Dubjago, Engelhardt, Kovalsky, Krasnov, Littrov, Lobachevsky, Yakovkin, Nefed'ev).

Martynov – Марстагы кратер, диаметры – 61 км. Дмитрий Мартынов хөрмәтенә аталган.

КОСМОНАВТЛАР ПРОСПЕКТЫ ӨСТЕННӘН ОЧЫШ

Фото: Александр Ефремов; Минзәлә аэроклубының ВКонтактедагы рәсми төркеме; А.Мисуркинның шәхси архивыннан

Автор: Ксения Сёмина

Космоска юл Татарстан аша үтә. Ышанмыйсызмы? Ышанмасагыз, Россия космонавтларыннан сорагыз. Аларның күбесе нәкъ менә биредә махсус парашюттан сикерү әзерлеген үтә.

Россия ДОСААФына кергән Татарстан Үзәк аэроклубының Минзәлә филиалы Россия Федерациясе космонавтлары өчен махсус парашют әзерлеген оештыру һәм үткәрү буенча база тәкъдим итү хокукына конкурсны 10 елдан артык отып бара.

Кирәк чакта очышлардан гел буш аяз күк йөзе, күнекмәләр залыннан алып уңайлы кемпингка кадәр – бөтен кирәк-ярагы булган база, ә иң мөһиме – кунаклары кебек үк зәңгәр күккә гашыйк, якты чырайлы хуҗалар бу аэроклубка гел тартып тора.

Биредәге космоска бәйле тарихлар белән оешма директоры Равил Нурмөхәммәтов кабинетында фотосурәтләрне караганда танышып була. Менә Геннадий Падалка, Сергей Корниенко, Марк Серов экипажы фотосурәте – космонавтлар үзләренең рәхмәт сүзен язып калдырган. Бусы – Халыкара космик станциядә булып кайткан, клубның логотибы төшерелгән парашют тасмасы. Ә менә бу – легендар парашютчы, Космонавтлар әзерләү үзәге инструкторы, беренче һава кинооператоры Сергей Киселев фотосурәте. Сәламләү сүзләре язылган бусы да аныкы – ярты гасырдан соң очышта төшкәне. Сергей Александровичка тиздән 88 яшь тула, тик ул әле һаман парашют белән сикерүен дәвам итә. Минзәләдә дә парашют белән байтак сикергән ул.

Клубка авторлар үзләре бүләк иткән космонавтлар портретлары галереясын, йолдызлы пейзажлар фотосурәтләрен яхшылап карап чыгар өчен берничә сәгать вакыт кирәк. Без әлеге хроникага күз йөртеп кенә чыктык, әмма Татарстанның Минзәлә районы һәм космос арасында турыдан-туры бәйләнеш барлыгын аңлар өчен шул да җитте.

ӨЙДӘГЕ КЕБЕК ДИЯРЛЕК

Когда студёный ключ играет по оврагу
И, погружая мысль в какой-то смутный сон,
Лепечет мне таинственную сагу
Про мирный край, откуда мчится он, –

Тогда смиряется души моей тревога,
Тогда расходятся морщины на челе, –
И счастье я могу постигнуть на земле,
И в небесах я вижу бога

– Михаил Лермонтовның әлеге шигъри юлларын аэроклубка сәлам рәвешендә космик станциядән экипаж командиры Сергей Рыжиков укый. Минзәләлеләрне космонавтлар үзләренең тугры дуслары дип саный. Кагыйдә буларак, 22–24 кешелек отряд аэроклубка елына ике тапкыр килә. Ике атна буе космонавтлар һәм инструкторлар база территориясендә яши. Бу вакыт эчендә һәркайсы берничә дистә тапкыр парашют белән сикерә.

Равил Мирзанур улы безнең өчен экскурсия үткәрә. Бирегә парашют белән сикерергә килгән һәркем, шул исәптән космонавтлар да, төп бинадагы ашханәдә туклана. Менюдагы ризыклар бик гади: бәрәңге боламыгы, карабодай боткасы, кәтлит, җәйге салат һ.б. Ашханә диварларына Минзәлә күгендә парашют белән

Россия ДОСААФына кергән Татарстан Үзәк аэроклубының Минзәлә филиалы директоры Равил Нурмөхәммәтов аэроклубка килгән легендар кунаклар турында сөйли.

сикерүче бәхетле кешеләрнең күпсанлы фотосурәтләре эленгән.

Төп бина янында конференц-зал урнашкан. Космонавтлар отрядына керүчеләр Минзәләдә күнекмәләр ясап кына калмый, бәлки мәктәп укучылары белән очраша, социаль акцияләрдә катнаша, Татарстанның истәлекле урыннарына экскурсиягә бара, клуб кунаклары белән аралаша. Былтыр космонавтлар республикада ДОСААФ эшчәнлеген актив хуплаучы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашкан.

Төп бина чатында – Космонавтлар проспекты. Андагы йортларда гадәттә йолдызлы кунаклар яши. Дөрес, йорт эчендә җиһазлар бик гади – тыйнак кына уңайлы бүлмәдә ике карават, өстәл, тумбочка тора, юыну бүлмәсе бар.

Космонавтлар урамы перронга барып чыга, аның артында исә – ярты чакрымлы аэродром юлы һәм 1,3 километр озынлыктагы очып китү-төшү полосасы. Күз ачып йомганчы, җитез Л-410 сине бер-ике мең метр югарыга күтәрәчәк һәм дустанә инструктор сине җайлап кына һава упкынына төртеп төшерәчәк...

ҖИРГӘ ТАБА

– Мин монда күп тапкыр сикердем инде. Югарыдан бу урын бөтен яктан су белән уратылган аерым утрауга охшаган. Искиткеч манзара! – дип сурәтли җирле аэроклубны һәм аның тирә-юнендәге табигатьне Ю.А.Гагарин исемендәге Космонавтлар әзерләү үзәгенең сынаучы инструкторы, Россия Герое Виктор Рень. Ул Татарстанга космонавтлар белән бергә килә һәм Минзәлә клубын махсус парашют әзерлеген оештыру һәм үткәрү буенча иң яхшы базаларның берсе дип саный.

Минзәләдә аның шәкертләре үтәгән программа мәҗбүри гомумкосмик әзерлекнең 13 этабыннан берсе булып тора. Аны үтмичә, космоска эләгә алмыйсың. Чынлыкта исә әлеге биремнәрне үтәү парашютта сикерү буенча спорт мастерлары өчен дә бик катлаулы. Һәм эш башкару техникасында гына да түгел (аны җиргә төшү өчен бары тик беренче алты космонавт кына кулланган). Махсус парашют

әзерлегенең максаты – космоска очарга җыенучы кандидатны чикләнгән вакыт һәм югары психоэмоциональ киеренкелек шартларында дөрес гамәлләр кылырга өйрәтү.

Техника гади принципка нигезләнә: кеше организмы өчен тоткарлыксыз-ирекле түбән очу гайре табигый һәм иң куркыныч нәрсә булып тора. Уйлап табучылары – ирле-хатынлы инструкторлар Сергей Киселев һәм Ирина Соловьева аны модельләштерелгән стресс системасы дип атый: әлеге техниканы кат-кат башкарган саен, космонавт үзенең баш миен санаулы секундлар эчендә кирәкле мәгълүматны эзләп табарга, аңларга һәм эшкәртергә, дөрес карар кабул итәргә һәм шуны эшләргә өйрәтә.

Практикада бу шуннан гыйбарәт: инструктор һәм үзеннән-үзе ачыла торган парашют кигән сыналучы сикерәләр (кайвакыт космонавт өчен көтелмәгән мизгелдә). Сыналучы беләзегенә беркетелгән карточкага язылган биремне үти.

– Парашют белән сикерү буенча биремнәр бик күп. Алар барысы да мәгънәләре, эчтәлекләре, катлаулылыклары белән бер-берсеннән аерыла. Бу математик яки логик мәсьәләләр чишү, мәгълүмат эзләү, аска таба очканда ирекле яисә билгеле бер темага репортаж алып бару, акробатик элементлар башкару, хәрәкәттәге яки бер урындагы мишень белән актив эшләү булырга мөмкин. Әзерлек барышында биремнәр катлаулана бара. Космонавт кайчак биремне алдан белә, кайчак – сикергәндә генә, – ди Виктор Рень.

Сикерү вакытында биремне үтәгәндә космонавт җир өслеген каплаган һава катламы торышы, үзенең карарлары һәм гамәлләре, янәшәдәге инструкторларның һәм башка парашютчыларның гамәлләре турындагы күзәтүләрен шәрехли. Үзенең фикерләре турында ул магнитофонга беркетелгән микрофонга сөйли (исегезгә төшерик, болар барысы да – секундына 50-60 метр тизлектә җиргә таба очу вакытында). Җиргә төшеп җиткәч, бу язмаларны инструкторлар һәм психологлар анализлый.

1 Космонавтлар проспектындагы йортлар. Анда йолдызлы кунаклар яши.

2 Йорт эчендәге бүлмәләр бик гади, әмма уңайлы.

3 Аэроклубның һава паркында берничә Л-110 һәм Ан-28 самолётлары исәпләнә.



Космонавтлар аэроклубта. 2019 ел.

– Шул рәвешле без шәкертләребезне очыш вакытында штаттан тыш хәл килеп чыккан очракта зур күләмле мәгълүмат арасыннан иң дөресен сайлап алырга өйрәтәбез. Бу штаттан тыш хәлнең сәбәбен аңларга, аны юкка чыгару өчен тиз һәм дөрес гамәлләр кылырга булыша.

Виктор Алексеевич 1994 елда «Мир» станциясендә килеп туган штаттан тыш хәл вакытында космонавт Валерий Поляковның нәтиҗәле эшен, 1997 елда орбитада янгын чыккач, Василий Циблиев һәм Валерий Корзунның дөрес һәм тиз арада башкарган гамәлләрен мисалга китерә.

КҮК ТӘ СЕЗНЕ ЯРАТЫР

– Минем тәүге сикерүем – катып калган кадрлар җыелмасы ул. Менә мин самолеттан беренче адымымны атлыйм, менә мине һава агымы бөтереп ала. Гөмбәз тасмасын, китеп барган самолетны күрәм... Тагын берничә тартылу, ыргылыш, бөтерелеш, һәм мин инде зур ак гөмбәз астында тирбәләм. Тирә-юнь – тып-тын. Шлемда үземнең сулышымны гына ишетәм, кипкән тамагым белән һава йотмакчы булам... Әмма алда – билгеләнгән урынга төшү. Һаман якыная барган җир куркыта. Өйрәткәнчә эшләргә маташасың... Каты итеп килеп бәреләсең, мәтәлчек атасың, һәм син инде әле генә уңышы җыеп алынган Минзәлә кыры буйлап тәгәрисең... Әлбәттә, мин билгеләнгән урынга төшмәдем, әмма шулай да башта – сөенеч һәм канәгатьлек хисе генә! Аннары көн саен үз күнекмәләреңне чарлыйсың, хисләр арткы планга күчә, һәм сикерү инде нинди дер глобаль нәрсә башкару инструментына әйләнә... – дип, үзенең хисләре белән уртаклаша быел сентябрьдә космоска очарга тиешле «Союз МС-19» төп экипажының икенче бортинженеры Дмитрий Петелин. Дмитрий космоска әле беренче тапкыр гына очачак.

Виктор Рень әйтүенчә, парашют белән сикерү яки авиациядә эшләү тәҗрибәсе булмаганнарны өйрәтү җиңелрәк.

– Парашютта сикерү тәҗрибәсе булмаган космонавтлыкка кандидат – менә дигән эш материалы, ул безгә тулысынча ышана, аңардан кирәкле продукт ясау бик җиңел. Сикерү тәҗрибәсе булмау өйрәтүнең тизләтелгән һәм нәтиҗәлелеген арттыра. 30–40 нчы тапкыр сикергәндә алар инде парашют спорты мастерлары 200–500 нче тапкырда гына башкарган биремнәрне үти, – дип аңлата инструктор. – Очучылар – космонавтлыкка кандидатлар белән эшләгәндә бер неч-

кәлек бар. Без аны махсус парашют әзерлеге курсы кысаларына кергән индивидуаль әзерлек программасын һәм методикасын эшләгәндә һичшиксез исәпкә алабыз. Эш шунда ки, космонавтларның парашютта сикерү буенча тәҗрибәләре төрле, шулай ук алар һава судносыннан аерылу, иреклe төшү, мәйданга якынаю һәм төшеп утыруның билгеле бер күнекмәләренә ия. Яхшы (дөрес) күнекмәләрне без үстерәбез, ә начарларын (зарарлыларын) бетерәбез. Моңа кыйммәтле вакытыбызны сарыф итәбез. Тагын бер мөһим, безнең тарафтан исәпкә алына торган фактор – очучыларга төзек горизонталь оча торган самолетны ташлап, билгесезлеккә сикерү психологик яктан бик кыен. Очыш вакытында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрдә дә алар очкычны саклап калу өчен тырыша, соңгы мизгелдә генә самолетны ташлап чыга. Әмма иртәме-соңмы махсус парашют әзерлеге программасын бөтенесе дә уңышлы тәгәлли.

Хәзер теләгән һәркем космонавт булу сайлавын үтеп карый ала. Виктор Рень әйтүенчә, әлеге омтылышта дүрт фактор хәлиткеч роль уйный. Беренчесе һәм иң мөһиме: кеше сау-сәламәт булырга тиеш. Икенчесе – тирән белем, эрудиция, компьютерны белү, белем алуга сәләтле булу, чит телләрне, беренче чиратта инглиз телен белү, зур күләмдәге катлаулы мәгълүмат белән эшли алу таләп ителә. Өченчесе – яхшы физик әзерлектә булу. Бу спорт мастеры, Россия, Европа яисә дөнья чемпионы булу кирәк дигән сүз түгел. Яхшы физик әзерлек – космонавтлар отрядына эләгергә омтылган, соңрак космонавт булган кешенең озак елларга сузылган һөнәри эшчәнлеге дәвамында авыр физик йөкләнешкә һәм югары психоэмоциональ киеренкелеккә чыдамлылыгы. Дүртенчесе – космик очышларга әзерләнү, катнашу һәм бурычларны үтәү өчен бик зур теләкнең булуы.

Гомумкосмик әзерлек якынча ике ел дәвам итә, аннары, экипажга билгеләнгәнче, әзерлек махсуслашу һәм камилләшү төркемнәрендә бара, бу өч-биш елга сузыла. Экипажга билгеләнгәч, әзерлекнең чираттагы этабы тагын ярты елдан алып ике елга кадәр бара. Булачак космонавт шуны белергә тиеш: беренче космик очышка илткән юл озын һәм сикәлтәле – космонавтлар отрядына кертелгәннән алып, очышка кадәр 7–10 һәм аннан да күбрәк ел үтәргә мөмкин. Берничә очышта катнашу өчен, 25–30 елга сузылган катлаулы марафонга әзер булу сорала. Сәламәтлек, белем, күнекмәләр һәм теләк шул дистанциягә җитәргә тиеш. Боларның барысы да нәрсә өчен соң?

– Хәзер без яңа космик кораб төзибез. Киләчәктә яңа станция, аннары – космик платформа, Айга, Марска һәм башка планеталарга очачак аппаратлар төзү турында карарлар кабул ителергә мөмкин, – ди Виктор Алексеевич. – Мин, космонавтикада без узган гасырның 60–70 нче елларында ирешкән казанышларыбызны кире кайтарырбыз һәм башка инде югалтмабыз, дип уйлыйм.

Ә космонавт Дмитрий Петелин очышларның мәгънәсе турында сорауга болай җавап бирә:

– Әгәр сине зәңгәр күк йөзе яки төнге йолдызлар яктысы кызыктыра икән, беренче адымны ясарга – аэроклубка килергә, парашют, планер, самолетны үзләштерергә, авиация эшенә өйрәтә торган институт, колледжга укырга керергә, хыялыңа якынаю, максатыңа ирешү өчен барысын да эшләргә кирәк. Шул вакытта гына күк йөзе үзе дә сиңа хәерхаһлыгын күрсәтер. Бу исә бик югары бәһа, мин моны яхшы беләм.

Парашютта төшерелә торган аппарат.



ИҢ КОСМИК

Фото: Олеся Бондаревская, Александр Ефремов

Космоста ничегрәк икәнне белү өчен, скафандр киеп орбитага чыгу мәҗбүри түгел хәзер... Базарлы Матакка барсагыз, шул җитә. Андагы космик музейга, төгәлрәге – сәүдәгәрлек-космик музейга гына керәсе кала.

Биредә сезгә элекке сәүдәгәрлек һәм хәзерге космос чоры арасында турыдан-туры бәйләнеш булуын күрсәтәчәкләр, чөнки әлеге музейның Татарстанның нәкъ менә бу районында пәйда булу тарихы бик мавыктыргыч.

СӘҮДӘГӘР НӘСЕЛЕ

Космосны буйсындыру түгел, әле аның нәрсә икәнен дә белмәгән борын-борын заманда Базарлы Матакта сәүдәгәр Сергей Михайлович Лисенков яшәгән. Бик бай булган. Әмма революциядән соң аңа, туган йортын ташлап, Америкага качарга туры килгән. Анда оныклары һәм аларның да балалары туган. Оныгының ире Яков Михеев бөтен гомерен космонавтикага багышлаган. Ул Сергей Королев белән бергә эшләгән, Юрий Гагаринны күреп белгән, 1957 елның 4 октябрендә Түрәтам (соңрак Байконур) полигоныннан орбитага җибәрелгән Җирнең дөньяда беренче ясалма иярчене антеннасын конструкцияләүдә катнашкан. Аның улы (сәүдәгәр оныгының улы була инде) – АКШ һәм Россия гражданины, «Аэроджет» компаниясенең Россиядәге вәкиллеге башлыгы Анатолий Михеев, ватанына кунакка кайткач, үз нәселенең күчемсез мөлкәтен – сәүдәгәр Лисенков йортын – тарих-төбәкне өйрәнү музее итеп файдалануга тапшыра. Аннары бирегә үзенең дусларын – очучы-космонавтлар Александр Баландин белән Муса Манаровны алып кайта. Кунаклар буш кул белән килми – музейга үзләренең махсус космик костюмнарын һәм башка «галәм» экспонатларын бүләк итә...

БАЗАРЛЫ МАТАК: КОСМОСТАН КҮРЕНЕШ

Шул вакыттан космос Базарлы Матакның төбәкне өйрәнү музеенда ныклап «тамыр җәя», яңа экспозиция формалаша: Җирнең космостан төшерелгән фотолары, космик корабль элементлары, «космик» ризыклар – эремчек, соклар, консервалар... Музейда космоста төшерелгән фотосурәтләр тулы диск та саклана: Везувий вулканы, мөселманнарның изге Мәккә шәһәре, «Казан» халыкара аэропорты... Архивта 25 яшендә «Восток-2» корабында очкан иң яшь очучы-космонавт Герман Титов,

1 Александр Баландинның тренировка костюмнары.

2 Александр Баландин ложементы һәм сыеклыклы ракета двигателе.

3 Музейга нигез салган Йосыф Зарипов коллекциясендәге сәгатьләр.

4 «Космик» ризыклар – эремчек, соклар, консервалар...

ике тапкыр Советлар Союзы Геройлары Георгий Гречко, Павел Попович төшергән сурәтләр дә бар.

Әлкилеләрнең үзләренә исә Базарлы Матакның космостан төшерелгән фотолары һәм космоста булып кайткан (аңа моны дәлилли торган махсус космик мөһер сугылган!) Әлки районы герблы флагы аеруча кадерле.

КОСМИК ЯКТАШЛАР

Музей оештырылуга ук, Әлки районының космос белгечләренә бай булуы ачыкланган. Мәсәлән, Базарлы Матакта туган Урал Закиров – космик техника төзүче һәм атказанган сынаучы, физика-математика фәннәре докторы – Королёв белән бергә эшләгән.

БЕРЕНЧЕ КОСМИК МУЗЕЙ

Музей Россия космонавтика музейлары ассоциациясенә керә. Шунлыктан әлеге һөнәргә бәйле кешеләр бирегә еш килә һәм бүләкләр дә китерә. Әйтик, музейда «100 рассказов о стыковке» китабы шул рәвешле пәйда булган – аны космик аппаратлар өчен инженерлык системалары конструкторы, атаклы Владимир Сыромятниковның улы бүләк иткән. Владимир Сергеевич Сергей Королёвның конструкторлык бюросында Җирнең беренче ясалма иярчене җибәрелүдән ел ярым элек эшли башлаган. Бүләк китапка Антон Владимирович Сыромятников: «Космическому музею номер один в Татарстане. С уважением, от сына отца мировой стыковки», – дип язып куйган.

5

Космонавт Николай Бударин костюмы.



6

Галим-физик Урал Закиров китаплары.

7

Әлки муниципаль районы башлыгы урынбасары Рәшит Билалов һәм ел саен үткәрелә торган «Космос глазами детей» район конкурсында катнашкан самолет «прототибы».

8

Базарлы Матакның космостан күренеше.

ЙОЛДЫЗАРА СӘЯХӘТЧЕ ЯЗМАЛАРЫ

Автор: Ксения Сёмина

«Дәһшәтле сугыш тәмамланган 9 май төнендә мин, Татарстандагы Базарлы Матак авылында яшәүче 12 яшьлек малай, урамга чыктым. Күк йөзен йолдызлар каплаган. Мин йолдызлар тупланган урынга игътибар иттем. Төшемдә мин беренче мәртәбә аларга якынайдым, астрономик ераклыкны һәм ниндидер бер эчке сиземләвем белән анда цивилизация барлыгын тойдым. Миңа калса, Илаһыбыз, Җирдә барган канлы бәрелешләрне күреп, исән калганнарга йолдызларга юлны күрсәтергә тырышкандыр».

Бу – «Записки межзвёздного путешественника» дип аталган фәнни-фантастик повестьтан алынган өзек. Аны китап авторы, якташыбыз, физика-математика фәннәре докторы Урал Закиров 87 яшендә дә ни өчен һәм ни рәвешле галәмне тикшерүен һәм аны «йөгәнләргә» тырышуын дәвам итә дигән сорауга төгәл җавап дияргә була.

МӘҢГЕЛЕК БИЛГЕЛӘРЕ

– Мин һәрвакыт үзебезнең проектларыбыз турында нинди дә булса истәлек сакларга тырыштым. Вакыт бик тиз уза, бернәрсә дә калмый, – ди Урал Нуриевич. Калын альбом – галәмне өйрәнүгә багышланган алты дистә ел дәвамындагы хезмәткә шаһит. Анда фотографияләр, язулар, чакыру билетлары, автографлар, хәтта космик аппарат тышлыгы кисәкчекләре дә саклана.

Журналистларны, кагыйдә буларак, альбомдагы ике раритет кызыксындыра: Юрий Гагаринның автографы һәм ул очкан «Восток-1» корабы тышлыгы фрагменты. Урал Закировка беренче космонавт белән берничә мәртәбә аралашырга насыйп була. Тәүге тапкыр Закиров Гагарин белән 1961 елның мартында очраша. Урал Нуриевич Сергей Королёв җитәкләгән 1 нче сынау-конструкторлык бюросында (1 нче ОКБ) инженер булып эшли.

Беренче мәртәбә космоска очарга тиешле кандидатлар Сергей Павлович белән очрашуга җыела. Урал Закиров өстәле янына яшь кенә офицер – Гагарин килеп утыра.

Фото: Александр Ефремов

– Мин инде аны нәрсә көткәнен белә идем, шуңа сүз катарга булдым. Күптән түгел сурдобарокамерада чыккан янгында һәлак булган кандидат Бондаренко фаҗигасе турында. Мин Юрадан, табиблар гаепле түгелме, дип сорадым. Ул, юк, диде. Мин аңа очышка шәхси әзерлеге турында да сорау бирдем. «Ил кушкан эшне үтәргә әзер!» – дип горурланып җаваплады Гагарин.

Космоска очканнан соң беренче космонавтны тагын әлеге бюрога алып киләләр. Бөтенесе автограф алырга ашыга, Урал Нуриевичка да Гагаринның имзасын алырга насыйп була. Соңрак әңгәмәдәшемнең тупланмасы «Восток-1» изоляциясенең бер кисәгенә дә байый.

Гагарин белән тагын бер очрашу атаклы хирург Александр Вишневский янына килгәч була. Космонавт әнисе Анна Тимофеевнаны табибка күрсәтергә алып килә. Аннан соң 1967 елда Байконурда очрашалар. Анда Урал Закиров Ай юнәлешендә җибәрелергә тиешле аппаратны әзерләүдә катнаша. Хәрби-һава көчләре Башкомандующиеның космик очышларны әзерләү һәм тәэмин итү буенча ярдәмчесе Николай Каманин Закировтан космонавтларга лекция укуын сорый. Анда Юрий Гагарин да була, ул кайбер нәрсәләрне блокнотына теркәп бара. Соңрак космонавт белән инженер Евпаториядәге Идарә үзәгендә эш буенча очраша. Соңгы мәртәбә – шунда ук. Космонавтның дуслары Юрий Гагаринның туган көнен бәйрәм итә.

– Ул бик дисциплиналы иде, бәйрәмнән соң да эшкә килде. Мин аңа Байконурда Королёв йорты янында үзем тапкан ташка әйләнгән агач кисәкләрен бүләк иттем. Юра аларны кесәсенә салып куйды һәм мине кочаклап алды. Мин аңа Марска да беренче булып очуын теләдем. Аннан соң коточкыч фаҗига – Гагарин һәлак булган көн җитте, – дип искә ала галим. – Минем авариянең сәбәбе турындагы соравыма авиакатастрофаны тикшерү буенча дәүләт комиссиясе әгъзасы, очучы Сергей Анохин кыска гына җавап бирде: «Пространствода юнәлешен югалту». Мин гаять зур бушлык тойдым... Һәлак булган Владимир Комаров һәм Юрий Гагаринның якты истәлегенә багышлагандай, без 1968 елда аппаратыбызны космоска озаттык, ул беренче тапкыр Айны очып әйләнде һәм Җиргә кире кайтты.

«БАРЫГЫЗГА ДА КОРАБ ҖИТМӘС...»

«Желаю побывать там!» – Урал Закировка биргән Ай фотосурәтенә космонавт Валерий Кубасов шулай дип язган. Очасы килү теләге героебызны гомере буе әзәрлекләгән. Барысы да Базарлы Матакта, әле бала чагында ук башлана. Уралның этисе, очучы белән сөйләшеп, улын «кукурузник»ка утырта. Очу хыялы булачак галимнең күңелендә әнә шул вакытта оялый. Ул Казандагы 19 нчы мәктәпне, Рига Югары инженерлык-авиация училищесын тәмамлый. Мәктәптә укыганда ук, СССРның космосны техник яктан үзләштерү пионеры Михаил Тихонравов мәкаләсе белән танышып, аңа хат яза. Аралаша башлыйлар. Училище тәмамлап, авиациядә хезмәт иткәннән соң, Закировны СССР Оборона министрлыгының Тихонравов эшләгән 4 нче фәнни-тикшеренү институтына эшкә алалар. Урал Нуриевич Мәскәү университетына читтән торып укырга керә, аннан соң читтән торып аспирантура тәмамлый. 1 нче ОКБга эшкә килә.

Ул вакытка илне ихтимал булган һөҗүмнән сакларга сәләтле континентара ракета Сергей Королёв тарафыннан инде проектлаштырылган була. Бу ракета космик эраны ача: ул беренче иярченне галәмгә күтәрә. Аннан соң космоска Лайканы очыралар, кешене җибәрү өчен аппарат әзерләнә. Королёв белән ул Гагарин галәмдә булып кайтканнан соң гына таныша. Проект бүлеге инженерлары да космоска тартыла. Алар белән Королёв шәхсән үзе сөйләшә.

– Минем дә космоска очасым килә иде. Чират җиткәч, Сергей Павлович миңа моның ни өчен кирәк булуы белән кызыксынды, – дип искә төшерә Урал Нуриевич. – Мин, яңа техниканы сыныйсым һәм космик киңлекләрне өйрәнәсем килә, дип җавап бирдем. «Молодец, үҗәт!» – дип мактады Королёв.

Королёв гадел һәм белемле инженерларны һәм сынаучыларны үз итә, аннан-моннан эшләүчеләрне һәм ялкауларны яратмый. Аның кырыслыгы һәрвакыт гадел була. Бераз вакыт үткәч, Урал Закиров һәм аның коллегасы җитәкче янына тагын бер мәртәбә космонавтлар отрядына кертүен сорап киләләр. Очрашуда Королёв нигәдер үзен һәм космонавт Николаевны Чувашиядә ничек матур каршылаулары турында искә төшерә. Мөгаен, ТАССР белән Чувашия күршеләр булгангадыр. Чыгып киткәндә исә: «Барыгызга да кораб җитмәс... Очарга насыйп булмаса, кайгырмагыз! Тормышны яратыгыз! Хатын-кызларны яратыгыз!» – ди.

– Инде аның вафатыннан соң без Айга ракета җибәрү эшенә әзерләнә башладык. Ракета җибәреләсе көнне Сергей Павловичның урынбасары Евгений Васильевич Шабаров миңа Королёвның кабинетына керергә, аның кәнәфиенә утырып, аның шәхси телефоны аша стартны тыңларга боерды. Мин шулай эшләдем дә, соңрак нәтиҗәләр турында ҮК һәм Шабаровка җиткердем, – дип сөйли Урал Закиров.

Космонавтлар отрядына ул барыбер эләгә алмый, чөнки күрү сәләте начаррак булып чыга. Ул вакытта инде Закиров совет Ай программасы проектларында катнаша – моның өчен, «Восток» белән чагыштырганда, бөтенләй өр-яңа корабль төзү таләп ителә. Марска экспедиция җибәрү максатында авыр планетаара корабль төзү буенча Королёв һәм Тихонравов проекты киләчәккә башлап куелган эшкә әйләнә. Очыш турындагы хыялдан өмете өзелү

космосны үзләштерүнең алгы сафларында калу теләгеннән көчсезрәк булып чыга.

ОРИЕНТИРНЫ ЮГАЛТУ

– Космосны өйрәнү корбаннар таләп итә, кыюлык, каршылыкларны җиңүне сорый. Аның асылы шундый, – ди Урал Нуриевич. Аңа космик аппаратларны җибәргәндә килеп чыккан берничә фаҗиганең шаһиты булырга туры килә, шул исәптән – космоста беренче мәртәбә кеше үлеменең дә.

Космонавт Владимир Комаров белән Урал Закиров 1960 елда Белка белән Стрелканың очышы вакытыннан бирле таныш була. 1967 елда Закиров Комаров идарә итәргә тиешле «Союз-1» не очышка әзерләүдә катнаша. 1967 елның 23 апреле төнендә Урал Нуриевичны Королёвның урынбасары уята һәм кабинетына килергә куша. Закировка шуны хәбәр итәләр: Комаров корабленең бер батареясы ачылмаган, Кояшта ориентирын югалткан. Электрның күпмегә җитәсен, двигательне кайчан төшерү уңаена эшләтеп җибәрергә кирәклеген санап чыгару таләп ителә.

– Мин исәпләдем, иртәнге 4–5 тирәсе чыкты. Аңлавымча, минем саннарны башка ФТИда да тикшергәннәр һәм раслаганнар. Мин кайтып киттем. Иртән эшкә килдем һәм миңа, Комаров үлгән, төп парашют ачылмаган, дип хәбәр иттеләр, – дип искә ала әңгәмәдәшем...

Урал Закиров катнашкан проектлар арасында тормышка ашырылмаганнары да бар.

Мәсәлән, 60 нчы елларда 1 нче ОКБда ул «Восход» кораблендә ясалма гравитация булдыру системасы буенча эшли. Әлеге система күпбаскычлы корабльнең соңгы баскычына бәйләнгән махсус аркан ярдәмендә космик аппаратның «сүтелүенә» нигезләнә. Алга таба система озакка сузылган космик очышларда кирәк булачак Җирнекенә якын тарту көчен тәэмин итүдә төп рольне уйный алыр иде. Әмма 1966 елда проектны туктаталар. Шул ук елның мартында американлылар үзләренең «Джемини» программасында безнекенә охшаш ясалма гравитация системасын сынап карый.

– Авырлык югалту халәтендә кеше организмында үзгәрешләр башлана, кайвакыт кире кайтарып булмастайлар. Шуңа күрә космосны өйрәнү иртәме-соңмы ясалма гравитацияне таләп итәчәк, – ди галим. – Мин, безнең системаны эшләп бетерергә кирәк, дип саныйм. Моннан тыш, ресурсы беткәннән соң Халыкара космик станциягә алмашка нинди аппарат киләчәге, шулай ук күп мәртәбә кулланыла торган космик системалар эшләү турында да уйларга кирәк.

Урал Закировның соңгы хезмәтләре Кояш системасындагы җисемнәргә тагын да кыскарак вакыт эчендә (мәсәлән, Марска – 200 тәүлек эчендә түгел, бер атнада) барып җитә алырлык тиз оча торган ракеталар физикасына багышланган. Аның тагын, Кояш системасы буйлап сәяхәт итү өчен термик атом-төш двигателен уйлап тапканнар, дигән яңалыкны да бик ишетәсе килә.

Урал Закиров журналга үзенең «Записки межзвёздного путешественника» китабын бүләк итте.

ГАЛӘМ ИСКИТКЕЧ ГҮЗӘЛ!

Минем әңгәмәдәшем бу язмада үзенең сүзләрен максималь дәрәҗәдә төгәл бирүне үтенә – кайбер темаларга аның әле һаман да ачыктан-ачык сөйләргә хакы юк. Мин аңардан, Җирдән башка да цивилизацияләр булуына ышанасызмы-юкмы, дип сорыйм.

– НЛОлар пәйда булу турындагы хәбәрләрне җентекләп тикшерергә кирәк. Кызык тоела билгеле, ләкин мондый нәрсәләрне еш кына төрледән-төрле космик чүп-чар тудыра. Шулай да, без, әлбәттә, тирә-як дөнья турында шактый нәрсәне белмибез, – дип сөйли Урал Нуриевич.

Менә инде 6 ел дәвамында ул теоретик физика өлкәсендәге тикшеренүләр белән шөгыльләнә. Барыннан да ныграк кызыксындырган темасы – караңгы энергия. Ул Галәмнең дүрттән өч өлешен тәшкил итә, шул ук вакытта әлегә аның барлыкка килү табигатен теоретик яктан гына тикшереп була. Ул антигравитация тудыра һәм Галәмне киңәйтә. Быел Урал Закиров әлеге проблемага бәйле чираттагы хезмәтен бастырган. Караңгы энергияне өйрәнү белән бүгенге көндә күп кенә чит ил һәм үзебезнең галимнәр шөгыльләнә.

Галимнең альбомында Алексей Леонов рәсеме саклана – кояш чыгышы фонында космоска Җирдән ракета күтәрелә. «Желаю приложить руку к этой фантастике!» – дип язган рәсемгә автор. Аның теләге туры һәм күчерелмә мәгънәләрдә тормышка ашуын дәвам итә. Урал Нуриевичның алдарак телгә алынган китабының сюжеты кешеләрнең космоста үзләренекенә охшаган гакылны барыбер табуы һәм әлеге очрашуның яхшы үтүе турында сөйли.

– Галәм искиткеч гүзәл һәм үзгәрүчән, ул миллионлаган йолдыз, тузан, бушлык, яктылык һәм дулкыннардан гыйбарәт. Миңа ул бик ошый, – ди галим.

Редакция кухнясы

«ГАГАРИНГА УХА ПЕШЕРДЕМ!»

Автор: Руфия Фазылова

Рита Мөхәммәдиева турында очраклы ишеттек. Һәм тиз генә үзе белән элемтәгә кердек. 1967 елда Юрий Гагаринга уха пешереп ашаткан пешекче икән ул!
– Әйе, булды андый хәл, – диде ул, бер дә исе китмичә.
– Безгә дә шундый уха пешереп күрсәтмәссезме икән? – дибез.
– Ярар, килегез. Аның бер авырлыгы да юк, – дип ризалашты Рита апа.

«УТ ИДЕМ...»

Рита Мөхәммәдиева Кама Тамагы бистәсендә үз йорты белән яши. Бирета туган, гомер иткән. Җәйгә 80 яшен тутыра икән. Безне ул кайнар кыстыбыйлар белән каршы алды.

– Тиз генә пешереп куйдым, - диде.

Башта аның бу сүзенә әллә ни игътибар итмәгән идек. Рита апа чынлап та бөтен әйберне тиз эшли. «Әһ» дигәнче ул өстәлгә уха өчен кирәкле әйберләрне тезеп тә куйды. Шул арада кәстрүлгә су салды, газын кабызды...

– Рита апа, 80 яшь димәссең, кулларыңа күз иярми, - дибез, уенын-чынын кушып.

– Хәзер аякларым авырта инде. Ә менә элек чынлап та ут идем...

Рита Мөхәммәдиева район ашханәсендә 33 ел буе пешекче булып эшләгән. Тик 50 яшендә, яраткан эшен ташлап, идән юарга урнашкан.

– Пешекчеләрнең хезмәт хакы аз бит. Идән юучы ярты көн эшләп, шулкадәр хезмәт хакы ала. Ә пешекченең эш сәгате иртәнге биштә башланып төнге уникегә кадәр дәвам итә.

Шулай сөйләшкән арада тәҗрибәле пешекче балыкны чистартып, зур кисәкләргә бүлде. Бәрәңге әрчеп, шакмаклап турады.

– Ухага мин бөтен әйберне берьюлы салам, – диде Рита апа. – Кайнап чыккан тозлы суга балык, бәрәңге, суган өстисең дә, эш бетә. Егерме минуттан аш пешә!

Хуҗабикә үзе сөйли, үзе эшли... Бу вакытта фотографны кызганып куйдым: Рита апа артыннан сурәткә төшерергә өлгерми!

«КИЕНЕГЕЗ, ЗИНҺАР...»

Кай арада эшне башладык, кай арада төгәлләдек – аңламый да калдык. Инде бирегә килүебезнең төп сәбәбенә – Юрий Гагаринга бәйле хатирәләрне барлау, искә төшерүгә күчәсе иде. Шул хакта сүз башладык...

1967 елның июль аен бик яхшы хәтерли Рита апа. Кама Тамагына КПССның Татарстан өлкә

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК

- судак (сыла) балыгы (уртача зурлыкта)
- бәрәңге – ике данә
- суган – ике данә
- дәфнә яфрагы
- кыяклы суган
- яшел укроп
- тоз – тәменчә
- борыч – тәменчә

Фото: Александр Ефремов

РИТА МӨХӘММӘДИЕВАДАН КИҢӘШ:
- Балыкны һәм яшелчәләрне кайнап торган суга бер үк вакытта салырга кирәк! Һәм барысын бергә 15–20 минут кайнатырга.

комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев җитәкчелегендә зур делегация киләчәк, дигән хәбәр тарала. Кунакларны Идел ярында каршы алып, тәмле итеп ашатып, озатып җибәрергә кирәк. Һәм әлеге җаваплы миссияне район ашханәсенең уңган пешекчесе Рита Мөхәммәдиевага йөклиләр.

– Юрий Гагаринны сыйлыйсын белгәч сөендем, – дип сөйли тәҗрибәле пешекче. – Дөньякүләм танылган кешене кайчан күрер идең әле! Уха пешерергә куштылар. Кама Тамагына төрле даирә кешеләре еш килә иде. Һәркайсына төрле ризык әзерләдек. Күрәсең, Гагаринны Иделдә тотылган балык ашы белән шаккатырырга теләгәннәрдер.

– Шаккаттымы соң? – дим.

– Белмим инде. Бик тәмле, дип ашады. Кат-кат рәхмәтләрен әйтте. Ул Идел ярына су чаңгысында килде. Ә өч кеше катер белән иде. Аларын танымадым, Мәскәү кешеләре булдымы икән. Фикрәт Табиев исә машина белән аз гына соңрак килде. Су чаңгысындагы космонавт ялан тән, плавкидан гына иде. Яр буенда өч хатын-кызны күргәч, каушап калды ул. Тиз генә катерның каютасына төшеп китте. Без исә артыннан, зинһар космонавт костюмыгызны киегез, дип кычкырып калдык.

Гагарин озак көттерми: формасын киеп, пешекче кызлар янына чыга. Ялан тән килгәне өчен тагын бер кат гафу үтенә.

– Без әле аның костюмын тотып та карадык,- ди Рита апа. – Ул безгә елмаеп карап торды. Бик итагатьле кеше. Зифа буйлы, чибәр. Хәтерлим, сул як кашында яра эзе бар иде. Үзара шаярышып, көлешеп ашадылар. Ашап кына түгел, эчеп тә алдылар.

– Нәрсә эчтеләр?

– Яхшы коньяк, аракы инде. Беренче тапкыр гына зур кунакларны сыйламадык. Табында һәрвакыт спиртлы эчемлекләр дә булды. Кунак эчәме-юкмы – анысы икенче мәсьәлә.

– Ухаsuccessfully

– Уханы ул вакытта сигез литрлы чиләктә пешердек. Яртысын ашап бетерделәр, калганын үзләре белән алдылар.

Сигез литрлы чиләктә пешкән ашны соңыннан кызлар катерның каютасына төшереп куя. Саубуллашканда кунаклар аларны, катерга утырып, Иделдә әйләнеп килергә чакыралар. Тик кызлар «юк» дип кырт кисә.

– Без бит татар хатын-кызлары! – ди Рита апа. – Аллаһ сакласын! Бөтен районга яманатың чыгар!

«АЛТЫ БАЛА ҮСТЕК»

Рита апа – сугыш башланып бер ай узгач туган бала. Биш яшенә кадәр әтисез үсә. Ә 1946 елны могҗиза була – әтисе сугыштан кайта!

– Әтидән куркып, аны танымыйча, өстәл астында утырганымны хәтерлим, – ди Рита апа. – Аның сул кулы яралы иде. Тик сәламәтлегеннән зарланмады. Әти фронттан кайткач, әни тагын биш бала тапты әле.

Гаиләдә олы бала буларак, Рита әнисенең төп ярдәмчесе булып үсә.

– Ундүрт яшемнән тире җыеп тозладым, – дип искә ала хуҗабикә. – Әти, мәрхүм, сугыштан бик бозылып кайтты. Эчүгә сабышты. Рәхәт күрмәдек без... Аллаһка шөкер, барыбыз да сау-сәламәт булып үстек.

Рита апа ире Раил белән бер ул тәрбияләп үстерә. Тик ир белән хатынга картлык көннәренә кадәр бергә яшәү насыйп булмый – гаилә башлыгы 48 яшендә вафат була.

– 43 яшемдә тол калдым, – дип сүзен дәвам итте әңгәмәдәшем. – Раилгә ике тапкыр инсульт булды. Бердәнбер улыбыз Рамилне Әфганстанга алганнарын белгәч, хәле тагын да начарланды аның. Аллаһка шөкер, Рамилебез сугыштан исән-сау кайтты. Шуннан соң Раил озак тормады, бакыйлыкка күчте. «Синең кайтуыңны көткән икән», – дидем улыма.

Рита апа ике оныгы турында бик озаклап, яратып сөйләде. Олы оныгы инде кияүдә, Азнакайда яши икән. Кечкенәсе Кама Тамагы урта мәктәбенең унберенче сыйныфында белем ала.

– Оныгым монда яши дисәм дә була, – диде хуҗабикә. – Олысы да шулай үсте. Улым Рамил шофер минем, ерак сәфәрләргә йөри. Хатыны да эшли. Мин исә көне буе өйдә. Оныгым кайткан төшкә әнә шулай тәмле ризыклар пешереп куям. Аннары миңа да иптәш кирәк бит.

Рита апаның йорты үзе кебек көлеп тора, якты, чиста. Өе тулы гөл. Җәен ишегалды, капка яннары, бакчасы да шулай чәчәккә күмелә икән.

– Улым әрли, – ди Рита апа. – Су сибәргә күп бит. «Шулкадәр күп чәчәк утыртма, аякларың авырта бит», – ди. Ел саен азрак утыртырмын дим дә, барыбер булмый. Миңа калса, шул чәчәкләр, гөлләр үстергәнгә яшәрәм, яшим мин, кызым.

«УХА ЯШЕЛ ТӘМЛӘТКЕЧЛӘР ЯРАТА»

Рита апа урыныннан кылт сикереп торды:

– Егерме минут узды, балык тарала күрмәсен!

Кәстрүлнең капкачын ачып карады. Балык кисәкләре ап-ак булып йөзеп йөри.

– Булган бу, булган. Артыгын тотарга ярамый, - дип, хуҗабикә газны сүндереп куйды. Шуннан ашка яшел суган белән укроп турый башлады.

– Уха яшел тәмләткечләр ярата. Элек пешергәндә дә шулай сала идек, - ди.

– Рита апа, Гагаринга пешергән уха бүгенгесеннән аерыламы? - дим.

– Аерыла, әлбәттә. Беренчедән, табигатьтә, учакта пешкән уха тәмлерәк була. Икенчедән, ул вакытта ухада өч төрле балык иде: чөгә, судак, алабуга. Безнең балык кибеттән сатып алынган. Ә ул чакта яңа гына Идел елгасыннан тотылган иде. Ухадан башка да, табынга ризыкны күп ясадык: тутырган тавык, каклаган каз, бәлеш, өчпочмак. Һәм, әлбәттә, берничә төрле балык. Ысланганы, киптерелгәне. Ул чакта Иделдә нинди генә төр балык юк иде бит!

Хуҗабикә уханы тәлинкәләргә бүлде. Тәмле балык исе чыкты. Рита апа ашка күп итеп яшел тәмләткечләр салды.

Авыз итәбез... Чын уха. Бер артык тәм дә юк.

– Аллаһның рәхмәте, балыгы әйбәт туры килгән, – дип сөенә Рита апа. – Кайбер кеше ухага йомырка, сыр, тагын әллә нәрсәләр сала, мин алай яратмыйм. Башка әйберләр балыкның тәмен ала. Үз гомеремдә нинди генә уха пешермәдем. Тавык шулпасында да ясадык. Ә менә монысы иң җиңеле, ашарга да, пешерергә дә.

«ӨЙДӘ ӘЗЕРЛӘП КАРЫЙ ИДЕМ»

Рита апа бөтен төр ризыкны да пешерә белә. Ашханәдә эшләгән вакытта беренче, икенче ашлар, камыр ризыклары – барысын да әзерләргә туры килгән аңа.

– Барысы да тәҗрибәдән килә, - ди хуҗабикә. – Гадәттә, яңа ризыкларны өйдә әзерләп карый идем. Нәрсә җитми, нәрсәсе артык, үзең өчен нәтиҗә чыгарасың.

Берсендә шулай Рита апага камырга төреп каз пешерергә кушалар. Әлеге дә баягы, районга зур кунаклар киләчәк икән.

– Башта каты камыр җәйдем. Аны куна тактасында егерме минутлап киптердем. Шуннан каз түшкәсенә тоз, аджика, башка тәмләткечләр сыладым да, камырга төрдем. Аны газ мичендә озак итеп пешердем. Ул төнне күзгә йокы кермәде инде...

Кунаклар Рита апаның казын мактап туя алмыйлар. Шулай итеп пешкченең тагын бер «фирменный» рецепты пәйда була.

– Ул заманнарда кыяр, помидордан, кәбестәдән салат ясый идек, - ди хуҗабикә. – Тагын винегрет бар иде. Күбрәк камыр ризыклары пешердек. Һәм, әлбәттә, балык...

Авыр чакларда эшләсәләр дә, тәҗрибәле пешекче үткәнен сагына. (Ә бәлки, яшьлегендер...) Күз алдына китерергә дә авыр: иртәнге биштә торып, ашханәгә килгәннәр дә мичкә якканнар. Утынын кичтән ярып калдырганнар. Аннан көянтә-чиләк алып суга киткәннәр. Ул арада плитәгә аш утыртырга кирәк. Рита апа хәтта түшкә-түшкә итне дә үзе чапкан...

– Әйе, авыр заманнарда эшләдек, дип искә ала тәҗрибәле пешекче. - Хәзер җиңелрәк инде, мичкә ягасы, су ташыйсы юк. Кайнар суы да килеп тора. Тик менә ул чакта да, хәзер дә пешекчеләрнең хезмәт хаклары аз. Бик авыр эш бит, көне буе аяк өстендә...

...Рита апаның «борчуы» бар – җәйгә 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтәсе килә икән. Табынга менюны инде әзерләп куйган. Исәнлек кенә булсын, ди. Без дә шуны телибез, Рита апа! Әле тагын күп еллар буе йөгереп йөрергә насыйп булсын! Тәмле ризык, акыллы сүзләрегез белән якыннарыгызны гел шулай сөендереп яшәгез!

ЮРИЙ ГАГАРИН КАМА ТАМАГЫНА СУ ЧАҢГЫСЫНДА КИЛӘ – БУ АНЫҢ ЯРАТКАН МАВЫГУЫ БУЛА. БЕРЕНЧЕ КОСМОНАВТНЫҢ ҮРНӘГЕ СССРДА ӘЛЕГЕ СПОРТ ТӨРЕНЕҢ ПОПУЛЯРЛАШУЫНА ЭТӘРГЕЧ БИРӘ. 1964 ЕЛДА СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА СУ ЧАҢГЫСЫ СПОРТЫ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ТӨЗЕЛӘ. 1965 ЕЛДА ИЛДӘ ӘЛЕГЕ СПОРТ ТӨРЕ БУЕНЧА ИЛ ЧЕМПИОНАТЫ ОЕШТЫРЫЛА. 1970 НЧЕ ЕЛЛАР АХЫРЫННАН СОВЕТ СУ ЧАҢГЫЧЫЛАРЫ ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘ ДӘ УҢЫШЛАРГА ИРЕШӘ БАШЛЫЙ. МӘСӘЛӘН, 1977 ЕЛДА МАРИНА ЧЕРЕСОВА СУ ЧАҢГЫСЫНДА ФИГУРАЛЫ ШУУ БУЕНЧА ЕВРОПА РЕКОРДЫ КУЯ. Ә 1979 ЕЛДА НАТАЛЬЯ РУМЯНЦЕВА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНКАСЫ ИСЕМЕН ЯУЛЫЙ.

1 Кисәбез!

2 Салабыз!

3 Турыйбыз!

4 Пешерәбез!

5 Болгатабыз!

6 Бүләбез!

7 Тәмләткечләр өстибез!

АВЫРЛЫК ЮГАЛУ ХАЛӘТЕНӘ ҺӨҖҮМ

Автор: Ольга Туманская

Дөнья фәне авырлык югалу халәтенең кеше организмына тискәре йогынтысына каршы берәр әмәл уйлап тапмыйча торып, галәмгә озак вакытлы очышлар ясау мөмкин булмаячак. Әлеге эшкә дөньяның алдынгы институтлары да кушылган. Адәм баласы галәмдә озак булганда, аның мускуллары зәгыйфьләнә. КФУның экстремаль биология лабораториясе галимнәре шушы проблеманы хәл итәргә алынган.

Фото: Александр Ефремов



ГЕННАР ДӘРӘҖӘСЕНДӘ АЛМАШ

1970 елның июнь ае. Андриан Николаев белән Виталий Севастьянов составындагы «Союз-9» корабы экипажы автоном очыш буенча әле бүген дә беркем уза алмаган дөнья рекорды куя – 18 тәүлеккә якын орбитадагы станциягә тоташмыйча эшли! Әмма геройларны Җирдә каршы алганда көтелмәгән хәл туа. Севастьянов кулында шлемын да тотып тора алмый, Николаев кәнәфиендә селкенмичә дә ята – коткаручылар аларны корабтан күтәреп алып чыга. Виталий Севастьяновның шул 18 тәүлек эчендә бот әйләнәсе – 7, балтырыныкы 3 сантиметрга кечерәя. Андриан Николаев шул очышка бәйле ике инфаркт кичерә, йөрәк – безнең организмдагы иң мөһим мускул бит ул.

Бүгенге көн технологияләре мөмкинлекләре буенча безгә иң якын планетага очу өчен ярты елдан артыграк вакыт кирәк. Һәм хәзергә кадәр мәсьәләнең биологик аспекты Марс миссияләрен гамәлгә ашыру өчен иң зур киртә булып кала. Әмма Казан лабораториясе мөдире, RIKEN Физика-химия тикшеренүләре институтының (Япония) әйдәп баручы хезмәткәре Олег Гусев моңа тыныч оптимизм белән карый:

– Идарә ителешле космонавтика үсеше дәверендәге кебек үк, әлеге проблеманы хәл итүгә бүген дә күп көч түгелә. Халыкара космик станциядәге космонавтлар өчен шул исәптән махсус тренажерлар ярдәмендә дә физик күнегүләр программалары эшләнә, алар мускуллар кулланылмаганда югала торган массаны компенсацияләүгә булыша. Әмма безне – генетикларны һәм молекуляр биологларны – икенче мәсьәлә кызыксындыра: әлеге котылгысыз рәвештә зәгыйфьләнү процессына генетик контроль позициясеннән йогынты ясап буламы? Хәзерге вакытта нәкъ шуның белән шөгыльләнәбез дә.

Казан галимнәре әлеге бурычка ике яклап якын килеп карарга була, диләр. Тикшеренүләрнең беренче юнәлеше киләчәктә космонавтларның күнекмәләрен оптимальләштерү мөмкинлеген бирәчәк. Һәм биредә безнең галимнәргә скелет мускулларындагы геннарның күнекмәләргә карата җавабын анализлау, шулай ук дистә еллар узгач яңадан үткәрелә башлаган коры иммерсия тәҗрибәләре ярдәм итә. Бүген тегесе дә, бусы да Мәскәүдә Россия Фәннәр академиясенең Медицина-биология проблемалары институты базасында уздырыла.

Коры иммерсия уникаль ысулы Җирдә авырлык югалу халәтен булдырырга ярдәм итә. Волонтерны гравитациясез пространство имитациясенә – тән тиресе суга тиеп тормасын өчен махсус әлпә белән капланган сулы ваннага урнаштыралар. Казан лабораториясе хезмәткәрләре бу вакытта кеше организмында нинди үзгәрешләр булуы турындагы генетик мәгълүматларны анализлый: организмга нинди сигналлар килә, аларның кайсылары мускулларның зәгыйфьләнү процессын башлап җибәрә? Шулай ук галимнәрне физиологик дәрәҗәдә башланган реабилитация вакытында алынган кире сигналлар да кызыксындыра. Мондый генетик экспертиза алга таба нәтиҗәлерәк күнегүләр схемаларын эшләргә мөмкинлек бирә.

Икенче юнәлешне Олег Гусев «күпмедер дәрәҗәдә футуристик» дип бәяли, әмма

Гүзәл Газизова экстремаль биология лабораториясендә йоклач тиен тукымасыннан РНК бүлеп чыгара. Бу тикшеренүләрнең нәтиҗәләре космоста да, Җирдә дә мускуллар атрофиясе проблемасын хәл итәргә булышырга тиеш.

ул фантастика булып тоелса да, проблеманы тамырдан хәл итәргә тиеш. Әгәр дә генетик аппаратны, чынлыкта бернинди авырлыксызлык юк, бар да тәртиптә, дип ышандырсаң? Чыннан да, әйбәт ялган!

– Якын киләчәктә кайбер рецепторларның чын сигналларын молекуляр фантомнарга алыштырырга һәм шул рәвешле күзәнәкне элеккеге кебек аксым бүлеп чыгаруга мәҗбүр итәргә өметләнәбез, – дип ачыклык кертә Олег Гусев.

Моны ничек эшләргә? Бу сорауга җавапны Казан галимнәре үткәргән тәҗрибә нәтиҗәләре бирергә тиеш. Өлге организм сыйфатында кимерүчеләр – күселәр һәм йоклач тиеннәр (русчасы – соня-полчок – ред. иск.) кулланыла.

КАБЫЗУ-СҮНДЕРҮ

«Авалон» галактикаара корабы колонистларны Җирдән яңа планетага алып бара. Очыш вакыты – 120 ел. Корабта – анабиоз халәтендәге кешеләрнең меңнәрчә гибернация капсуласы. Ялгышлык аркасында аларның берсе сафтан чыга. Капсула эченә кислород тула, автомат анда яткан ир кешегә яшәүнең төп функцияләрен активлаштыргыч препарат кадый. Бер секундтан кеше сулый башлый. Бер минуттан йөреп тә китә...

Фантастлар – «Пассажирлар» фильмы авторлары – озак вакытлы очышларның мөмкинлекләрен шулай күрә. Сүз уңаеннан, алар ашыгыч ярдәм күрсәтү һәм хәтта реанимация функциясе дә булган медицина капсуласын да уйлап тапкан. Әйе, экранда ерак киләчәк, әмма ул киләчәктән күп нәрсә бүген тормышка ашырыла инде.

– Кешене ясалма комага кертү, фармацевтика ысулы белән аның метаболизм процессларын акрынайту... Бүгенге тенденцияләргә карап фикер йөртсәк, медицинадагы андый технологияләрнең үсеше хәтта космик технологияләргә караганда да тизрәк бара, – ди Олег Гусев. – Кешелек техник яктан башка галактикаларга очарга әзер булганда (ягъни двигательләр, ягулык, радиациядән саклану мәсьәләләре хәл ителгәндә), гомумән алганда, фән боларак биология һәм медицина да сынатмаячак.

Бүген Казан галимнәре күселәрдә үткәрелгән тәҗрибә барышында алынган мәгълүматларны эшкәртә. Сынау моннан берничә ел элек экстремаль биология лабораториясендә башланган. Кимерүчеләрне авырлык югалту халәтенә якын микрогравитация шартларына урнаштырганнар: тәпиләрен авырлыктан азат итәрлек итеп, махсус рәвештә асып куйганнар. Аннары алар мөстәкыйль хәрәкәтләнерлек булганчы, реабилитация үткәрелгән. Лаборатория хезмәткәрләре сынауның барлык стадияләрендә күсе организмында барган бөтен генетик үзгәрешләрне җентекләп күзәтеп торган. Мускуллар атрофиясен тикшерү буенча дөньяда беренче комплекслы эш була бу. Атрофиянең барлык этапларында һәм аннан соңгы торгызылу чорында мускулларда барган процессларны чагылдырган беренче генетик цифрлы база шулай барлыкка килә.

– Авырлык югалу халәтендә геномда нинди үзгәрешләр бара, нинди геннар мутацияләнә һәм «дөрес булмаган» продукт чыгара башлый – ниһаять, бездә боларның тулы бер картинасы формалаша башлады, – ди Олег Гусев. – Генетик структураны бозмыйча гына зәгыйфьләнү процессларын булдырмый калырга өметләнәбез. Моның өчен геннар белән түгел, ә аларны кабыза һәм сүндерә торган механизмнар белән эшләргә кирәк. Геннар эшчәнлеге аларның активлыгына бәйле. Киләчәктә әлеге юнәлеш өстенлек итәчәк, дип саныйм.

ЙОКЛА, ЙОКЫ ЧҮЛМӘГЕ!

Әлеге йомшак җәнлекне күрүгә үк кулга алып сөясе килә башлый. Колаклары түгәрәк, төймә күзләре кабарынкы, зур танавы алсу... Тиен дә түгел, тычкан да түгел – йоклач тиен. Бу житез җәнлекләр ботактан ботакка сикерә ала, ауга төннәрен генә чыга, агач кәүсәләрендәге куышта, чит ояларда яшәргә һәм... сыерчык ояларында ятак корырга ярата! Әмма, мөгаен, алар турындагы иң гаҗәеп факт шушыдыр: алар елына 11 айга сузылган йокыга тала һәм, уянгач, тиз арада элекке хәленә кайта. Бу инде безнең генетиклар өчен табигать бүләгедер.

Әлеге бәләкәй җәнлекләргә нинди механизмнар күнегүләрсез генә мускулларының массасын саклап калу мөмкинлеген бирә соң? Казан галимнәре өчен чын мәгънәсендәге ребус бу. Алар аны иң яңа генетик ысуллар һәм шундый ук яңа аппаратура ярдәмендә чишәргә ниятли.

– Бәхеткә, кеше һәм йоклач тиен – икесе дә имезүчеләр классына керә. Һәм бу безнең өчен бик тә кулай! – дип сөйли Олег Гусев. – Чөнки безнең бер үк төрле геннарыбызның бер үк урыннарда урнашу ихтималы зур. Димәк, йоклач тиеннәр табышмагын чишеп, конкрет геннардагы кабыза һәм сүндерә торган механизмнардан файдаланып, без үзебезнең төп бурычыбызны хәл итүгә якынлашабыз.

Кышкы йокыга талган йоклач тиеннәрнең молекуляр механизмнарын өйрәнү проектының башкаручысы Гүзәл Газизова безгә лаборатория буйлап экскурсия үткәрә.

– Татарстанда әлеге йоклач тиеннәр Кызыл китапка кертелгән, шуңа да безнең лабораториягә аларны Волгоградтан кайтарттык, – дип ачыклык кертә ул. – Әмма хәзер биредә җәнлекләр юк инде, кирәкле генетик мәгълүмат алынды, тәҗрибә аларны анализлау стадиясенә күчте.

Йоклач тиеннәр түбән температурада гына түгел, әйләнә-тирә шартлары уңайсыз булса, җәй көннәрен дә йоклап үткәрә ала, дип сөйли Гүзәл. Җәнлекләр метаболизмнарын акрынайта, ә тәннәренең температурасы 4 градуска кадәр төшә! Шул ук вакытта алар катып кала, тышкы ярсыткычларга игътибар итми. Гадәттә, алар октябрьдә йокыга тала, апрель аенда гына уяна.

– Әгәр кешене, тычканны яки башка бер имезүчене ике атнага булса да йокыга талу шартларына урнаштырсаң, аның организмында кайбер аксымнар таркала башлый, – ди Гүзәл. – Нәтиҗәдә мускуллар хәлсезләнә, күләмнәре кими. Хәер, йоклач тиеннәрдә дә мондый процесслар бара, әмма алар зыян китерерлек булмый.

Йоклач тиеннәр ни барәбәренә мускулларын саклап кала соң? Галимнәрнең бер фаразы – йокы вакытында аларның кыска вакытка гына уянып алулары. Андый вакытта аксым синтезы яңара һәм мускуллар кабат үз массасын җыярга өлгерә.

– Уяну программасы кабыну белән, йоклач тиеннәрнең генетик транскрипция аппараты актив эшли башлый һәм аксым синтезына сигналлар бирә – хәрәкәтсез яткан вакыттагы югалтулар шул рәвешле торгызыла, – дип аңлата Гүзәл. – Без аларның йоклаганда бераз гына калтырауларын да күрдек, димәк, азмыкүпме хәрәкәт бар. Менә шул микрохәрәкәтләр мускулларга бик тә кирәкле булган аксымны сакларга ярдәм итә дә инде.

– Без йоклач тиен организмында теге яки бу программаны уятып җибәрә торган төп молекулаларны билгели алабыз. Атрофия турында сөйләгәндә исә, безне таркалу программалары кызыксындыра. Кешедә яки күседә әлеге программа эшли башлаганда, таркалган аксымны утильләштерә торган молекулалар активлаша. Әлеге молекулалар җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән, әмма без аларны атрофиягә каршы тора алучы йоклач тиеннәрдә күзәтергә телибез.

– Һәм бу кешегә биохимик йогынты ясау ысулларын уйлап табарга ярдәм итәчәк, – дип төгәллек кертәм мин. – Мәсәлән, космонавт дару төймәсе каба да үзенең мускулларын торгызу процессын кабыза...

– Яки, киресенчә, дару каба да атрофия процессын туктата, – дип елмая Гүзәл.

– Беләсезме, космик биология галәм өчен генә яшәми, аның Җирдә тагын да амбициялерәк планнары бар, – ди Олег Гусев. – Безнең тикшеренүләр нәтиҗәләре имгәнгән кешеләрнең реабилитация чорын шактый кыскартырга ярдәм итәчәк. Яки, мәсәлән, озак вакытлар комада яткан пациентларның мускулларын торгызырга... Шуны истә тотарга кирәк: бүген кешелек куллана торган бик күп технологияләр кайчандыр космосны буйсындыру максатыннан уйлап табылган булган.

Лабораториянең иң мөһим урыны – югары җитештерүчәнлекле ДНК секвенаторы. Җиһаз мускуллар атрофиясе процессларына каршы тора алучы уникаль кимерүчеләрнең геном үзенчәлекләрен «җыеп» анализларга мөмкинлек бирә.



ПЛАНЕТАЛАРНЫ ДА АЛЫРБЫЗ ЙӨГӘНЛӘП...

Автор: Ольга Туманская

Венера, Ай, Марс, Сатурн... Аннары исә – башка галактикаларга! Космос безнең Казан галимнәрен дә бик кызыксындыра, ә алар, сүз уңаеннан, бу өлкәдә дөньякүләм абруйга ия. Кыскасы, бүген космик киңлекләрне безнең галимнәрдән башка үзләштерү мөмкин түгел диярлек.

Ә УЛ ЕЛГА БУЛГАНМЫ СОҢ?

Perseverance аппараты 2021 елның 19 февраленә каршы төндә Кызыл планета атмосферасына «бәреп керә». Езеро кратеры янәшәсендәге төшеп утыру урыны очраклы гына сайланмаган. Монда ниндидер тереклек эзләре сакланып калган булырга мөмкин, чөнки ул НАСА белгечләре тарафыннан кайчандыр зур күл булган дип фаразлана, аның тирәсендәге Марс ландшафтында елга дельтасы да шәйләнә...

Ә Казан галимнәренең монда ни катнашы бар, дисезме? Эш шунда ки, Татарстанның яшь белгечләре бүген Марс өслеген өйрәнү белән шөгыльләнә. Һәм, бәлки, бу эш барышында алар ирешкән нәтиҗәләр ExoMars Россия-Европа миссиясе белгечләрен дә кызыксындыра алыр.

– Perseverance аппаратын корыган елга юлы тирәсенә махсус төшерделәр, тик аның нәкъ менә елга булуын кем белә соң? – дип сорау куя КФУ профессоры, «Астровызов» стратегик академик берәмлегенең «Космик навигация һәм планеталарны өйрәнү» фәннитикшеренү лабораториясе җитәкчесе, Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясе директоры Юрий Нефедьев.

Казан университетында аның җитәкчелегендә үткәрелә торган тикшеренүләр бу сорауга дөреслеккә бик якын дәрәҗәдә җавап табарга мөмкинлек бирәчәк. Сүз фракталь геометрия методлары ярдәмендә Марста берберсенә охшаш участокларны билгеләү белән шөгыльләнүче студент Карлос де ла Морена Коко эше турында бара. Ягъни бер үк төрле эволюция шартларында барлыкка килгән урыннар күздә тотыла, шул исәптән су белән бәйле процесслар барган булырга мөмкин, димәк, тере материяләр яши алган участоклар да тикшерелә. Perseverance әнә шундый урыннарны эзләргә дип юл тоткан да инде.

Мәсәлән, КФУның яшь галимнәр төркеме дә, НАСАның «Маринер» программасы кебек төрле космик сәфәрләр мәгълүматларын анализлап, Кызыл планета өслеге структурасының өч төсле цифрлы картасын булдыра, анда нәкъ менә искә алынган бер-берсенә охшаш өлкәләрне аерып күрсәтә. Сүз уңаеннан, беренче карашка, мондый участоклар төрле булып күренергә, ә асылда бер үк эволюция юлыннан узган булырга мөмкин. Шунысы да бар: казанлылар рельефның вакыт аралыкларындагы үзгәрешен дә терки. Аларның хезмәте Марска оештырылачак киләсе сәфәрләрдә су, сирәк очрый торган файдалы ресурслар һәм тереклек калдыкларын эзләүдә булышыр, дип өметләнә галимнәр.

– Марста тереклек эзләре табылу ихтималы югары, – ди Юрий Нефедьев. – Анда шартлар бик кырыс – көндез экваторда 35 градуска кадәр

эсселек, төнлә исә температура 100 градуска хәтле төшә. Асылда, хәтта Җирдә дә температураның шулай үзгәреп торуы белән Кызыл планетага охшаш урыннар бар, тик мондый кырыс шартлар анда тере организмнарга яшәргә комачауламый. Әгәр дә без кайчан да булса Марсның өслегенә тирәнрәк үтеп керә алсак, анда ниндидер микроорганизмнар табылу ихтималы тагын да югарырак. Бәлки, хәтта «микро» гына да түгелдер…

«Марста шәфәкъ», НАСА фотосурәте.

АЙДА ЛАЕКЛЫ УРЫН…

Бүгенге технологияләр Марска пилот тарафыннан идарә ителешле очышларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирми, ә менә Ай исә, бу яктан караганда, чынбарлыкка бик якын проект. «Луна-25» яки «Луна-Глоб» космик аппараты – Россиянең яңа меңьеллыкта Айга беренче сәфәре. Нигездә, СССРда 1976 елда ук туктатылган Ай программасының дәвамы ул. Аны кабат эшләтеп җибәрү 2021 елның октябрь-ноябрь айларына планлаштырылган. Россия проектының төп максаты – Айны тикшерүнең бөтенләй башка баскычына күтәрелү. Бу, асылда, Җирнең табигый иярчененә пилотлы кораб җибәрер алдыннан үзенә күрә разведка булып тора. «Луна-25» аппаратының бурычы – йомшак төшеп утыруны сынап карау һәм ландшафтны өйрәнү. Казан галимнәре уйлап тапкан нәрсәләр бу сәфәрдә, бәлки, шактый мөһим роль уйнар.

Сүз уңаеннан, Казан фәнни мәктәбе Айны өйрәнү өчен күп еллар тырышлык куя. Бу өлкәдә без дөньяда әйдәп баручылардан булдык һәм әлегә кадәр «айлы» тикшеренүләрдә алдынгылыкны бирмибез. Роскосмос үзенең якындагы сәфәрендә иң әүвәл Айда навигация системасының картага төшерелгән имитация моделен кулланырга мөмкин. Әлеге модельне исә дәүләт оборона заказы кысаларында Юрий Нефедьев җитәкчелегендә Казан галимнәре эшли.

– Җирдәге кебек кеше хезмәт куя торган кабул итү станцияләре Айда юк, бу исә навигациягә бәйле җитди проблемалар тудыра, – дип сөйли Юрий Анатольевич. – Без координата-вакыт бәйләнешенә караган мәсьәләләр белән шөгыльләнәбез һәм югары төгәллектәге координаталар системасын төзү методын эшләдек. Әлеге система Ай тирәсендәге орбитада ГЛОНАСС навигация системасын җәелдереп җибәрү өчен нигез булып хезмәт итәчәк.

Эш шунда ки, космосны үзләштерү дәверендә кешелек тарафыннан Ай өслегенең күпсанлы орбиталь фотосурәтләре һәм карталары алынган, тик әлегә кадәр аларны нинди системага бәйләп карау мөмкинлеге ачыкланмаган, чөнки ясалма иярченнәрнең орбиталары тотрыксыз – алар үзгәреп тора. Казанлылар исә, алынган барлык мәгълүматларны бердәм хисап системасына кертеп, аның нигезендә Айның оптик күзәтү мәгълүматлары базасын эшләү һәм шул система ярдәмендә табигый иярчендә терәк навигация челтәрен төзүгә бәйле төп проблеманы хәл итү мөмкинлеген тапкан.

Казан галимнәренең тагын бер хезмәт җимеше алда көтелгән сәфәрнең хәвеф-хәтәрләрен шактый киметергә сәләтле, чөнки ул аппаратның Айга тагын да төгәлрәк, димәк, йомшаграк рәвештә төшеп утыруын тәэмин итә ала. Эш шунда ки, бүгенге көндә Айга төшеп утыру эллипсы 15 кә 8 чакрымны тәшкил итә. Самолетны шундый «төгәллек» белән төшереп утыртуны күз алдына китерәсезме? Казанның яшь галиме Алексей Андреев тарафыннан эшләнгән ысул төшеп утыру мөмкин урынны берничә дистә метрга кадәр кысарга, кечерәйтергә юл ача. Дөрес, әлегә Ай өслегендә лазерлы яктылык маягы урнаштырылачак билгеле бер нокта гына күз уңында тотыла. Тик эшне дөрес юлдан башлау аның яртысын уздың, дигән сүз.

Әлеге тикшеренүләр шулай ук физик либрацияне (тирбәлешләрне) һәм Айның эчке төзелешен өйрәнү нәтиҗәләренә нигезләнә. Ә бу эш белән Казанда инде йөз елдан артык шөгыльләнәләр.

– Бүген дөньяда бу юнәлештә эш алып барган ике генә алдынгы фәнни мәктәп бар. Аларның берсе НАСА, икенчесе – Казан университеты, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Әлбәттә, тикшеренү нәтиҗәләре алдагы Ай сәфәрләрендә файдаланылачак, чөнки Айның физик либрациясе турындагы белемнәрсез гомумән нәрсә дә булса модельләштерү мөмкин түгел.

ЗИЛАНТ ТҮГЕЛ – АПОФИС

Караңгыда очучы зур явыз елан Кояшны юк итәргә омтыла. 2005 елда исә Апофис Мисыр мифологиясеннән йолдызлы күккә «күчә». Әнә шундый исем алган астероид, секундына 30 мең километрдан артык тизлек белән әйләнә-әйләнә, Җир белән һәр 10 ел саен диярлек якынаеп ала. «Кунак»ның чираттагы якынаюы вакыты 2029 елга билгеләнгән. Ул имин генә үтеп китәрме? Бәхеткә, куркыныч тудырмый очып китү ихтималы зуррак. Шулай да астероидлар – даими, җентекле күзәтүне таләп итә торган

Өч йөз метрлы Апофисның Казан Кремле манарасы белән чагыштырып күрсәтелгән фотосы.

куркыныч «кунаклар». Галимнәр шуның белән шөгыльләнә дә инде, шул исәптән Казанда да.

Юрий Нефедьев Казан Кремле манаралары белән чагыштырмада сурәтләнгән өч йөз метрлы Апофис фотосын күрсәтә. Мондый «елан» республиканы санаулы секундлар эчендә Җир йөзеннән юк итәргә мөмкин. Сүз уңаеннан, астероид әле үз траекториясен үзгәртәчәк, шул исәптән үзе «куралмаган» Кояш тәэсирендә дә – ул Апофисның якларын җылыта, шул рәвешле аның хәрәкәтенә яңа реактив этәргеч ясый...

– Без астероидларның һәм башка кече күк җисемнәренең хәрәкәтен, структурасын, үзара бәйләнешен, аларда файдалы ресурслар булу-булмавын өйрәнәбез, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Россиядә бу юнәлештә эшли торган фәнни төркемнәр хәзер әллә ни күп түгел. Бәхеткә, Казан университетында көчле белгечләр калды. Һәм иң мөһиме – бу тема фән өлкәсенә килгән яшьләрне кызыксындыра.

Күк җисемнәре һәм метеорит матдәләр хәрәкәте схемасын төзеп, Казан галимнәре Җир тирәсендәге метеорлар мохитен башка планеталарга кадәр интерполяцияләргә өйрәнде. Мәсәлән, Марска кадәр. Мондый эшләрнең гамәли файдасы анык күренеп тора, чөнки аппарат белән бәрелешкәндә хәтта кечкенә космик җисемнәр дә теләсә нинди сәфәргә куркыныч тудыра ала.

Сүз уңаеннан, Казан галимнәре галәмдәге табигый җисемнәрне генә тикшерү белән чикләнми, кеше кулы ясаганнарын да өйрәнә. Монда сүз космик чүп-чар турында бара. Юрий Нефедьев моңсу гына шаяртып әйтеп куя: тиздән шул чүп-чар аркасында Җир кешеләре үз планеталарыннан чыга да алмый ятачак.

– Ни кызганыч, бу проблема бик кирәкле тикшеренүләр темасына әверелеп бара, – ди ул. – Җир тирәсендә элекке космик корабларның дистәләрчә мең калдыгы, ватыгы очып йөри. Космик аппаратларның бу кисәкләр белән бәрелешү куркынычы бар...

КҮК ҖИСЕМЕ КҮПМЕ ТОРА?

Ә астероидларны куркыныч түгел, ә... файдалы нәрсә дип карасак? «Була ул!» – дип саный Казан галимнәре. Астероидларга гына түгел, алар Айга да практик файда күзлегеннән карарга тәкъдим итә. Табигый байлыкларның бетеп бару проблемасы каршында торган Җир шары икътисадының әлеге мәсьәләне гамәли хәл итәрлек бер берәмлеге итеп күзаллана Ай.

– 2015 елда Goldman Sachs Group финанс конгломераты бастырып чыгарган фаразларга караганда, Җирдә алтын, алмаз, агалтын кебек кайбер ресурслар якынча 40 елга җитәрлек кенә калган, – дип сөйли КФУның Физика институты һәм Энгельгардт исемендәге астрономия обсерваториясенең Космик тикшеренүләр һәм технологияләр үзәге кече фәнни хезмәткәре Алексей Андреев. Әлбәттә, биредә кешелекнең проблемасы зәркәнчелек бизнесы өлкәсенә алтын-көмеш җитмәүдә түгел, ә әлеге файдалы казылмалар кытлыгының оборона-сәнәгать комплексына һәм көнкүреш электроникасы тармагына зыян салуында, дип аныклый галим, ә андый электроникадан башка, аңлавыбызча, цифрлы киләчәк турында уйлыйсы да юк.

Бүген дөньяның күп кенә галимнәре бу мәсьәләне хәл итүдә көчләрен берләштерә. Казанлылар да читтә калмаган. 2019 елда Алексей Андреев, Ай һәм астероидлар ресурсларын тикшерүләрдә катнашу өчен, Россиядә бу мәсьәлә буенча баш белгеч – МДУ профессоры Владислав Шевченко командасына чакырылган булган. Яшь галим Ай өслегендә файдалы байлыклар эзләү һәм әлеге ресурсларга бай районнарда төшереп утыру урыннары күрсәтелгән карталар булдыру ысулларын эшләү белән шөгыльләнгән.

– Нәкъ менә ресурслар турында сүз бара, казылмалар түгел, – дип төгәллек кертә Алексей, чөнки якын киләчәктә Айдан нинди дә казылма байлыклар чыгару мөмкинлеге күзалланмый. Моның белән шөгыльләнә алырлык роботлар әлегә уйлап табылмаган, ә кеше моны югары радиоактив фон аркасында эшли алмый – Җирнең табигый иярченендә озак тору сәламәтлек өчен куркыныч.

Шуңа да карамастан, Айның хәтта өслегендә дә ресурслар буа буарлык, дип санала. Алар анда метеорит яңгыры нәтиҗәсендә әлегә, ә атмосферасыз Ай өчен андый яңгырлар – гадәти хәл. 2009 елда НАСА Айның Lunar Reconnaissance Orbiter (LRO) дип исемләнгән ясалма иярченен җибәргән. Ул соңгы елларда иң нәтиҗәле Ай сәфәрләренең берсе булган. Планетаара автомат станция Ай өслеген бик яхшы сыйфатта фотога төшергән. Нәтиҗәдә, галимнәр Айда яңа кратерларның нинди тизлек белән арта баруын ачыклый алган: 7 ел эш дәверендә аппарат ике йөздән артык яңа кратер тапкан! Ай рельефын акчага әйләндереп була икән ләбаса.

– Астероидның төшү тизлеге секундына 12 км дан артмаса, аның 50 проценты тирәсе Ай өс-

Фото Юрий Нефедьев архивыннан

легенә әллә ни тирән кермичә калырга мөмкин икәнен беләбез. Әлбәттә, бу очракта астероидның төшү почмагы да әһәмиятле роль уйный, – дип аңлата Алексей Андреев.

1994 елда Америка галимнәре 1986 da астероидына спектраль анализ ясый. Әлеге күк җисеменең озынлыгы якынча 2 километр тәшкил итә. Астероидтан алынган нурланыш буенча аның якынча составы һәм авырлыгы билгеләнә – чама белән 30 триллион килограмм. 1994 елдагы хаклар белән санаганда, аның бәясе якынча 25 триллион доллар тәшкил иткән. Ә 2012 ел бәяләренә күчереп исәпләгәндә – инде 82,7 триллион доллар. Кыскасы, икътисад өчен шактый өметле өлкә турында сүз бара.

Мондый гигантка кул сузарга маташу – фантастик рухтагы максат. Тик ник әле игътибарны кечерәк күк җисемнәренә юнәлтмәскә, ди? Озынлыгы берничә метр гына тәшкил иткән астероид белән нәрсә эшләп булуы турында вариантлар теориядә бар инде, дип сөйли Алексей. Мәсәлән, двигатель куеп, орбитасын көйләү һәм аны туп-туры Җир тирәли орбитага җибәрү. Яки Ай тирәли орбитага кертеп, уңайлырак ысул белән үзләштерү җаен шунда карау. Мондый проектларны 2030–2040 елларга таба тормышка ашыру планлаштырыла. Казан галимнәренең кече күк җисемнәре һәм Ай төзелеше турындагы белемнәреннән башка, мөгаен, монда эш алга бармас.

КЕШЕЛЕК БИШЕГЕ

– Сезнеңчә, Марсны колонизацияләү мөмкинлегеннән без ни дәрәҗәдә ерак? – журналистлар НАСА Марс фәнни лабораториясенең әйдәп баручы инженеры Адам Штельцнерга әнә шундый сорау бирә.

– Мин бик ерак дип өметләнәм, – дип җавап бирә ул.

Марс – без яшәргә тиеш урын түгел, дип саный Адам. Анда кешелекнең үзе өчен яраклы шартлар тудыра алачагы да бик икеле. Тәүлеклек температураларның бик зур аермасы, атмосфераның сыеклыгы һәм радиоактив фонның югарылыгы, Марс чагыштырмача якын планета булса да, аны колонизацияләү проектын шик астына куя. Шуңа да карамастан дөнья галимнәре кешелекнең яңа бишеген булдыру идеясе белән яна. Казанлылар исә табигый иярченнәргә игътибар бирергә тәкъдим итә.

– Безнең университетта Сатурн иярчене Титанга бәйле тикшеренүләр узды, – дип сөйли Юрий Нефедьев. – Марс түгел, нәкъ менә Титанны күпләр кешелекнең икенче бишеге урынына төп дәгъвачы дип саный. Менә без дә үз алдыбызга шундый сорау куябыз: Титанда сыеклык һәм тыгыз атмосфера булганда, безгә Марс нигә кирәк әле?

Титанда температура Марсныкы чамасындарак, әмма шул ук вакытта киләчәктә аның шартлары Җирнекенә якынрак булачак. Галимнәр иярчендә тереклек булу мөмкинлеген кире какмый, шул исәптән Титанның җир астында да, чөнки андагы климат өслектәгегә караганда күпкә «йомшаграк».

– Безне Венера кызыксындыра, чөнки Җирнең ул узган эволюция юлыннан баруы ихтимал, – ди Юрий Нефедьев.

Әлбәттә, башка планеталарны һәм аларның иярченнәрен колонизацияләү – бик ерак киләчәк эше. Әмма хәзерге вакытта башланмаса, ул ничек тормышка ашырыла алсын соң?

– Бүген без киләчәктәге колонизация турында сүз алып барабыз, чөнки Җирдә тормыш мөмкин булмаган вакытның килеп җитәчәген беләбез, – ди Юрий Анатольевич. – Кояш җылына, киңәя башлаячак һәм иртәме-соңмы планетабызны үзенә йотачак. Әлбәттә, моңа кадәр әле бик ерак, шуңа да карамастан, процессның башы инде бүген үк сизелә. Әмма шул ук вакытта бу күренешнең икенче ягы да бар – салкын планеталарда җылырак булачак, бозлар эреячәк. Шуңа күрә бүгенге бурычны кешелек Җирдән читтә тере материя эзләүдә күрә. Әгәр без аны тапсак, ул бөтен кешелек өчен искиткеч ачыш булачак.

Казан галимнәре фикеренчә, планетабызның эволюциясе белән бәйле күп кенә төп сорауларга җавапларны... Венерада табарга була. Россиянең космик кораблары Җирнең «бертуган сеңлесен» беренче булып тикшерә башлаган. Бүген инде шунысы ачыкланган: миллиардларча ел элек Венерада океан булган һәм, бәлки, тормыш та кайнап торгандыр.

– Хәзер анда тәмуг шартлары: температура – 400 градустан артык, ә басым 100 атмосферага тиң! Шуңа да карамастан безне Венера кызыксындыра, чөнки Җирнең ул узган эволюция юлын кабатлавы ихтимал, – ди Юрий Нефедьев. – Венерадагы үзгәрешләр парник эффекты аркасында килеп чыккан, дип санала. Без соңгы елларда Җирдә дә нәкъ шуны күрәбез бит. Хәзер безнең төркем Венера структурасын тикшерә. Планета өслеген параметрик анализлауның фракталь ысуллары ярдәмендә, Венерадагы кайсы да булса структураның тере организмнар катнашында барлыкка килмәгәнме икәнен ачыкларга тырышабыз. Әгәр гөманыбыз расланып, без анда тереклек билгеләрен тапсак, бу зур фәнни ачыш булачак һәм кешелеккә планетабыз эволюциясен аңлау өчен юнәлеш бирәчәк.



КИЛӘЧӘК ҖИТӘКЧЕСЕНЕҢ ГАЛӘМ КИҢЛЕКЛӘРЕ

«Ел җитәкчесе» республика конкурсы җиңүчеләрен игълан иткәндә, сәхнәгә нибары ике хатын-кыз чыкты. SIGN URBAN[1] («Фабрика качества» ҖЧҖ) компаниясенең генераль директоры һәм гамәлгә куючысы Ләйлә Сафина бәйгенең «Кече (урта) эшмәкәрлек предприятиесе белән уңышлы идарә иткән өчен» дип аталган менеджерлык номинациясендә иң яхшыларның берсе булды. «Хатын-кызмы син, ир-атмы – бизнеста бу мөһим түгел», – дип саный ул, үз уңышының серләрен ачып. Сүз уңаеннан, аның горурланырлыгы бар: пандемия һәм кризиска карамастан, SIGN URBAN компаниясенең эш нәтиҗәләре сокланып, тел шартлатып куярлык.

МАКСАТКА ҺИЧШИКСЕЗ ИРЕШӘМ!

Мин үзем турында, көчле менеджер, дип әйтә алам. Максат куям икән, ахыргача барам. Мөмкинлекләр һәм ресурслар һәрвакыт табылып тора ул, иң мөһиме – идея һәм аны тормышка ашыру.

Узган ел җиңелләрдән булмады, әмма без аны яхшы нәтиҗәләр белән тәмамладык. Ә бу инде – предприятие командасы эшенең һәм аның менеджментының нәтиҗәлелек күрсәткече. Бәлки, әлеге факт конкурста җиңүемдә хәлиткеч нигез булгандыр да. Хәер, безнең социаль юнәлештәге әһәмиятле иҗтимагый проектларда катнашуыбыз да уңышка йогынты ясагандыр дип өметләнәм.

«Безнең ишегалды» президент программасы нәкъ шундый проектларның берсе. Бу – ишегалларын төзекләндерүне күздә тоткан колачлы программа, һәм безнең SIGN URBAN компаниясе («Фабрика качества» ҖЧҖ) былтыр аның рәсми тәэминатчыларыннан берсе булды. Тиз генә бар көчне туплап, без кризисның асылда үсеш өчен бер этәргеч булуын тагын бер кат раслый алдык.

ИҢ МӨҺИМЕ – АХЫРГЫ НӘТИҖӘ

«Мин моны 38 ел көттем!» – ишегалды төзекләндерелгән Казан йортларының берсендә яшәүче ханымның әлеге сүзләре эшебезгә иң ихлас, үтемле бәяләмәдер, мөгаен. Синең хезмәтеңне күрә белүчеләр булганда, тагын да яхшырак эшлисе килә.

Менә инде биш ел безнең SIGN URBAN компаниясе урамнарда ял итү, вакытны файдалы үткәрү урыннары булдырырга ярдәм итә. Урамнарга, ишегалларына уңайлылык, матурлык, җанлылык бирү безгә бик ошый. Балаларыбызның шундый рухи хозурлыкны, уңайлылыкны күреп үсүендә үз өлешебез барлыгын тою да рәхәтлек өсти, чөнки бу аларның тәрбияләнешенә дә тәэсир итми калмаячак лабаса.

«Безнең ишегалды» президент программасын гамәлгә ашыру кысаларында гаять колачлы бурычлар үтәлде. Дүрт ай эчендә без 10 районның 237 ишегалдында 2500 ләп эшләнмә ясадык һәм монтажладык. Сүз уңаеннан, бу сан республика буенча әлеге программада каралган барлык кече архитектура формаларының дүрттән бер өлешен тәшкил итә. Иманым камил: без әле күбрәк тә эшли алабыз.

Фото Лайлә Сафина архивыннан

[1] Сайн урбан.

##ҺӘРКЕМГӘ ШӘХСИ ИГЪТИБАР – ӨСТЕНЛЕГЕБЕЗ

Ни өчен нәкъ менә безне сайлыйлар соң? Бәлки, эш сыйфатта гына түгел, хезмәт процессына гомуми мөнәсәбәттәдер дә. Иң мөһиме – ул комплекслы карашны күздә тота: материаллар сайлау һәм эшләнмәләрне ясаудан башлап, аны китереп бирү һәм монтажлауга кадәр. Дизайнер ясаган яктырту җиһазлары, навигация элементлары, ишек-капкадан керү урыннары, велопарковкалар, балалар уен комплекслары һәм спорт җиһазлары, чатырлар, таганнар, амфитеатрлар, шезлонглар... Безнең ассортиментта йөзләрчә продукция бар, алар иң югары куркынычсызлык һәм экология таләпләренә җавап бирә. Нинди материалдан ясалган булуына карамастан, алар температураның кинәт үзгәрүеннән дә, дымлылыктан да курыкмый. Шуңа күрә без компаниянең бөтен продукциясенә киңәйтелгән гарантия бирәбез. Әлбәттә, дизайн ягына да зур әһәмият бирелә, талантлы рәссамнар һәм архитекторлар белән бергә эксклюзив арт-объектлар эшләнә. Кыскасы, безнең өстенлегебез: концепцияне эшләүдән гарантияле хезмәт күрсәтүгә кадәр – бар нәрсәдә дә клиентның теләк-таләпләренә шәхси игътибар күрсәтүдә.

БАР ТЫРЫШЛЫКНЫ – ИҖАДИ ХЕЗМӘТКӘ

Җиңел булачак дип беркем дә вәгъдә итмәде. Мин бизнеста инде 20 ел, шуның 10 елында җитештерүне җитәклим.

Бу вакыт эчендә мин бик күп катлаулы, четерекле карарлар кабул иттем һәм моңа үкенмим. Ялгышлар һәм җиңүләр безне чыныктыра. Шуңа күрә мин уңаймы, тискәреме – һәр нәтиҗәне кабул итәм дә, хаталарны төзәтеп, алга барам.

Бервакыт без территорияне төзекләндерүгә бәйле бик зур проект белән яңа төбәктә эш башладык. Ул якта безне белмиләр дә, көтмиләр дә иде. Андагы эшмәкәрләр безнең компанияне базардан кысрыклап чыгарырга тырышты. Ул шартларда эш алып бару мөмкин түгел иде диярлек. Шактый катлаулы хәл. Судка мөрәҗәгать итеп, дәгъвалашып йөрергә була иде, тик мин башкача эшләргә уйладым. Без бу проектны энәсеннән җебенә кадәр үз өстебезгә алдык һәм җирле ширкәтләр өчен үрнәк булырлык итеп башкарып чыктык.

Ул чакта мин шундый нәтиҗә ясадым: бөтен көчне сугышка, бәхәскә сарыф итәргә яисә инде аны иҗат эшенә юнәлтергә була. Гамәлебез дөрес булып чыкты – без ул төбәк өчен горурлык объектына әйләнгән берничә кызыклы проект ясадык. Һәм анда гына түгел – SIGN URBAN илнең 16 төбәген колачлый, без киңәю процессын уңышлы дәвам итәбез. Биш ел эчендә 250дән артык проектны тормышка ашырдык. Алар арасында аеруча мөһимнәре, зурлары бар. Әйтик, мәйданы 77 га тәшкил иткән «Затюменский» экопаркы кебек.

Бу проект безнең теләсә нинди территорияләр белән эшли алуыбызны раслады. Хәтта алар аеруча саклана торган яки табигать һәйкәлләре статусына ия булганда да туктап калмыйбыз. Бүген ул парк – төмәнлеләрнең яраткан ял урыны, анда инфраструктура элементлары табигый ландшафтка бик яраштырып ясалган. Җирле скульптор, сөяк кырып ясау остасы, рәссам Сергей Шаповалов белән берлектә эшләнгән гадәти булмаган арт-объектларны эзләү төмәнлеләр өчен паркта үзенчәлекле квестка әйләнде. Чөнки безнең бурыч территорияне төрле арт-объектлар һәм кече архитектура формалары белән тутыру гына түгел, ә алар аша Себер фаунасының уникальлеген һәм үзенчәлеген күрсәтеп бирү дә булды. Ял итү һәм спорт белән шөгыльләнү өчен парк – шәһәр халкын җәлеп итәрлек урын булдырырга кирәк иде.

ЯҢА СЫНАУЛАРГА РИЗА!

Бизнесның энергиясе миңа көч-куәт бирә! Эшкуарлык максатчанлык кына түгел, ә һәрнәрсәдә яңа мөмкинлекләр табу теләге дә хас үзенчәлекле холык иясе булу дигән сүз ул. Төп сыйфатларның берсе – вакытында тәвәккәлләп, үз карарлары өчен җавап тота белү.

Нәкъ менә шундый кешеләр мине балачактан ук илһамландырды да инде. Мин шуны аңладым: бизнес үзгәрми торган константа түгел, һәм син бүген уңышлы эшләп торсаң да, иртәгесе көннең шулай тыныч һәм тотрыклы буласына бернинди гарантия дә юк. Эшмәкәрлек ерак дистанциягә йөгерүгә тиң, анда үсеп китә торган урыннар да, абынып егыла торган җирләр дә бар.

Иң мөһиме – эшмәкәрлек мохите сәламәт һәм гадел булсын, калганын бизнес үзе җайлаячак.

Энергия барлыкка килүдә мөһим баскычлар бар: яңа продукт булдыру, яңа проект туу вакыты, эш нәтиҗәсен күрү – болар да сиңа көч бирә. Хезмәтебезнең ахыр нәтиҗәсе рухландыра. Теге яки бу проект өчен нинди эш башкарылуын аңлау һәрвакыт күңелле.

Теге яки бу компаниянең ни дәрәҗәдә уңышлы булуы турында ул барлык формалашу этапларын узгач кына сөйләргә мөмкин. Безнең компания дә искәрмә түгел. Шәхсән үзем өчен ул ун ел элек, миңа юл билгеләре һәм навигация элементлары җитештерү һәм урнаштыру белән шөгыльләнә торган предприятие җитәкчесе вазифасын тәкъдим иткәч башланды... Чын сынау, яңага адым!

Чөнки миңа ширкәт җитәкчесе генә түгел, кризис-менеджер да булырга туры килде. Бихисап проблемаларны хәл итәргә, бизнес-процесслар барышын нәтиҗәле итеп көйләргә, яңа продуктларны эшләтеп җибәрергә...

Әлбәттә, бу команданың уртак эше иде. Аның нәтиҗәсе исә шуннан гыйбарәт: без үсешкә бәйле кризисларны, тышкы йогынтыларны җиңеп кенә калмадык, ә үз базарыбызны шактый киңәйттек, бизнесны диверсификацияләдек, яңа эш юнәлешләре ачтык.

РЕБРЕНДИНГ ҺӘМ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Бүген SIGN GROUP[2] компанияләр төркеме дүрт мөстәкыйль юнәлешне үз эченә ала һәм Татарстанда бу тармак ширкәтләренең беренче унлыгына керә. Иң яшь һәм актив үсештәге юнәлеш – SIGN URBAN.

Компания дизайнерлар эшләгән яктырту җайланмалары, навигация элементлары, керү урыннары, балалар уен комплекслары һәм спорт җиһазлары җитештерү һәм урнаштыру белән шөгыльләнә... Эшләнмәләрнең һәм хезмәтләрнең сыйфаты киңәйтелгән гарантия белән раслана. Клиент мәнфәгатен беренче планга кую, вакытка бәйле таләпләрне һәм өстебезгә алган бурычларны тиешенчә үтәү һәм үз стилебезнең булуы - безнең өстенлегебез.

Үзем өчен киләчәккә нинди максатлар куяммы? Әлбәттә, зур максатлар. Без алга таба да үсәчәкбез, матур проектлар белән халыкны сөендерәчәкбез, шул ук вакытта сыйфатны тагын да күтәрәчәкбез. Безнең өчен төп максат – төзекләндерү эшендәге һәр элементын күңел биреп башкару, кешеләргә уңайлылык һәм матурлык бүләк итү.

Мине аеруча рухландыра торган шигаребез – SIGN URBAN made in Tatarstan[3]. Ә якындагы өч елга максатыбыз – Россиянең бу тармактагы компанияләре арасында беренче унлыкка керү.

Һәрвакыттагыча, мин моңа комачаулардай бер каршылык та күрмим.

[2] Сайн групп, [3] Татарстанда эшләнгән.



ИГЕЛЕКЛЕ ЭЗ

Татарстанның транспорт һәм юл төзелеше тармагы уңышлы эш, традицияләргә тугрылык, яңа технологияләр куллану һәм, әлбәттә, туган төбәк һәм тулаем ил хакына намуслы хезмәт итү үрнәге булып тора. Үзенең заманча үскән инфраструктурасы ярдәмендә республикабыз туристлык һәм инвестиция потенциалы өчен үсеш ноктасы, татарстанлылар, россиялеләр һәм чит ил кунаклары өчен уңайлы территория булып танылган. Бу вазгыятьтә ТР Министрлар Кабинеты карары белән 1996 елда нигез салынган «Татарстан Республикасы күперләре» акционерлык җәмгыятенең өлеше зур. Быел предприятие үзенең юбилеен билгеләп үтә – менә инде 25 ел буе ул юл хуҗалыгы тармагы алдында торган иң әһәмиятле бурычларны хәл итә.

«Иман – күк белән җир арасындагы салават күпере ул».
Иоганн В. Гёте

Компания коллективы тарафыннан башкарылган эшләр арасында федераль һәм төбәк әһәмиятендәге зур объектлар, Татарстан Республикасының территориаль һәм федераль автомобиль юлларында сафка бастырылган йөзләрчә күпер бар. Легендар оешманың эш географиясе дә сокландыра – Кырымнан Татарстанга кадәр. Һичшиксез, төзелгән объектларның югары сыйфатлы булуын, барлык заманча таләпләргә, норматив проект документларына җавап бирүен дә әйтергә кирәк. Күперләр, юл чишелешләре, юллар, юлүткәргечләр, юл кичүләре – боларның барысын да компания хезмәткәрләре гасырларга җитәрлек итеп эшли. «Татарстан Республикасы күперләре» АҖ генераль директоры Ринат Мөхьянов, ТРның атказанган төзүчесе, табигый лидерлек сыйфатларына ия шәхес, искиткеч белгеч һәм зирәк җитәкче буларак, коллективны яңадан-яңа җиңүләргә алып бара. Предприятие коллективы, төзелгән килешүләр һәм контрактлар буенча куелган барлык бурычларның төгәл үтәлешен тәэмин итеп, күпер корылмаларын төзү, ремонтлау һәм карап тоту эшләрен оештыру буенча зур тәҗрибә һәм мөмкинлекләр туплаган.

Предприятие үзенең юбилеен ирешкән казанышлары өчен зур горурлык хисләре белән каршылый. Хезмәткәрләр командасының чын мәгънәсендә югары квалификацияле булуын әйтергә кирәк, алар уртак максат белән берләшеп эшләргә, иң җитди һәм күләмле таләпләргә җавап бирергә әзер тора. Компания коллективы, Зур Казан Боҗрасының генераль подрядчысы буларак, юл төзелеше өлкәсендәге әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү белән дә шөгыльләнә. «ТР күперләре» АҖ эшчеләренең сүзләренә караганда, Татарстанда предприятие күпер салмаган, шул рәвешле үзенең игелекле эзен калдырмаган район калмаган. Бу урында төзелгән корылмаларның социаль яктан әһәмиятле булуына да игътибар итәргә кирәк, чөнки алар коммерция йөкләрен ташуны һәм Россия Федерациясе субъектларын тоташтырган трассалар буенча хәрәкәтне тәэмин итеп кенә калмый, халыкның укырга, эшкә яки туганнарына йөрү шартларын да яхшырта. Компания социаль өлкә өчен мөһим булган бу объектларны төзү эшен инде күп еллар алып бара, районнар, юллар һәм, әлбәттә, кешеләрне берләштерә торган күперләр сала.

Мәҗит Салихов,
«Татарстан Республикасының төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе җитәкчесе

– Хөрмәтле Ринат Сәгыйтович, шәхсән үз исемемнән һәм безнең учреждение коллективы исеменнән Сезне һәм легендар предприятиегез хезмәткәрләрен бу зур юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм! Проектлау, төзелеш һәм эксплуатация стадияләрендә биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгын тәэмин итә торган дәүләт учреждениесе җитәкчесе буларак, Сез төзегән корылмаларның профессиональ яктан югары сыйфатлы, белгечләр тарафыннан ныклыгы расланган булуын билгеләп үтәм. Үз эшенең осталары булган командагызга киләчәктә дә зур казанышлар һәм автоюллар төзелешендә яңа уңышлар телим!

Фотолар «ТР ДЭБИ» ДАУ һәм «Главтатдортранс» ДКУ тарафыннан бирелде

КИРӘКЛЕ ХЕЗМӘТ

Транспорт инфраструктурасы үсеше территория, район, шәһәр, төбәкнең никадәр зур уңышка һәм югары дәрәҗәгә ирешүен күрсәтә. Уңайлы юл чишелешләре, юллар, җәяүлеләр өчен яңа юл кичүләре һәм күперләре, А ноктасыннан Б ноктасына тиз барып җитү мөмкинлегеннән тыш, биредә яшәүче халыкка горурланыр өчен сәбәп тә бирә. 1996 елда оештырылган «Татарстан Республикасы күперләре» АҖ – Татарстан Республикасының әһәмиятле инфраструктура проектларын гамәлгә ашыра торган предприятие. Быел ул үзенең 25 еллык юбилеен билгеләп үтә.

Баштарак җәмгыять Татарстан Республикасында күпер корылмаларын төзү һәм ремонтлау буенча дәүләт заказын башкара, ә инде 2001 елда «Татарстан Республикасы күперләре» АҖ республикабызда күпер кичүләре һәм күпер корылмалары төзү һәм ремонтлау буенча генераль подрядчы функцияләрен үти башлый. Унбиш ел дәвамында һәм бүгенге көнгә кадәр бу уңышлы компания республикада күперләрне карап тоту, төзү, капиталь ремонтлау, агымдагы, планлы-кисәтү ремонты эшләрен башкара.

Компания тарафыннан гамәлгә куелган күпсанлы проектлар арасында Казан–Әгерҗе тимер юлы аркылы Каменка станциясе янәшәсендә төзелгән юлүткәргеч, ТРның Әгерҗе районындагы Көчек авылы янында салынган күпер, «Волга» М-7 федераль автомобиль трассасында Идел һәм Зөя елгалары аша күперләрне тулысынча ремонтлау бар. Республикадан читтә дә эшләр алып бара башлагач, Татарстан күпер төзүчеләре эшчәнлеге федераль дәрәҗәгә күтәрелә. Мисал өчен, Хабаровскидан Владивостокка кадәр «Уссури» М-60 автомобиль юлының 540+099 чакрымындагы Кулешовка елгасы аша күперне проектлау, шулай ук Невердан Якутскига кадәр «Лена» М-56 автоюлының 335+101 километрындагы инеш аркылы күперне проектлау. «ТР күперләре» АҖ хезмәткәрләре федераль дәрәҗәдәге «Керчь–Феодосия–Белогорск–Симферепоть–Бакчасарай–Севастополь» (Бакчасарай районы чиге) автомобиль юлында күпер корылмалары төзи, хәзерге вакытта Зур Казан Боҗрасы проектының подрядчысы булып тора.

Юбилей датасы – предприятиенең тотрыклы үсеше, сайланган курска тугрылык, коллективның һәм аның җитәкчелегенең профессиональлеген раслый торган вакыйга. Компаниянең мөһим үзенчәлеге итеп, башкарылган эшләрнең югары сыйфатлы булуын гына түгел, ә төзелештә иң заманча технологияләр һәм материаллар кулланылуын да әйтергә кирәк. Предприятиене ТРның атказанган төзүчесе, тәҗрибәле җитәкче Ринат Мөхьянов җитәкли. Ул ТР Президенты Рәхмәте һәм РФ Транспорт министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

Эдуард Данилов,
«Главтатдортранс» ДКУ директоры

– Шәхсән үз исемемнән һәм компаниябез хезмәткәрләре коллективы исеменнән «ТР күперләре» акционерлык җәмгыятен ихлас күңелдән юбилее белән котлыйм. Профессиональ уңышларыгыз башкара торган эшегезнең югары сыйфаты турында сөйли һәм Татарстан юл төзүчеләренең данын Татарстаннан читтә дә тарата. Бүгенге көндә сезнең катлаулы, ләкин кирәкле хезмәтегез республиканың уңышлы үсеш символына, илебезнең алдынгы төбәге булган Татарстанның йөзек кашына әйләнде. Безнең учреждение коллективын сезнең компания белән күпьеллык уртак эш һәм тыгыз хезмәттәшлек бәйли. Хезмәттәшләребезгә яңа кыю проектлар, матур казанышлар, нык сәламәтлек, ә компаниягә киләчәктә дә Татарстаныбыз хакына яңа үрләр яулавын телим!

Фотолар «Главтатдортранс» ДКУ матбугат хезмәтеннән алынды

КЕШЕЛӘРНЕ БЕРЛӘШТЕРЕП

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1996 елгы карары нигезендә оешкан «Татарстан Республикасы күперләре» АҖ үзенең 25 еллык юбилеен билгеләп үтә. Бу үсеш дәвере Татарстан юлчыларының зур казанышлары, федераль һәм республика дәрәҗәсендә төзелгән йөзләрчә объект, бихисап күп юл чакрымнары һәм меңнәрчә кеше язмышы турында сөйләргә мөмкинлек бирә.

Тарихи карар тулы бер тармакның үсеше өчен хәлиткеч роль уйный. Күпер төзүчеләр җитди бурычлар, күләмле төзелеш эшләре, гамәлгә куелган зур проектлар һәм халык хуплаулары белән сугарылган катлаулы юл уза. Бу вакыт аралыгында «ТР күперләре» АҖ көче белән Татарстан Республикасының территориаль һәм федераль автомобиль юлларында 400дән артык күпер төзелгән һәм ремонтланган, шул исәптән «Волга» М-7 автоюлындагы Идел һәм Зөя аша күпер кичүен, «Казан–Оренбург» автоюлында Саескан Тавы янындагы Кама аша күпер кичүен төзү буенча проектлар уңышлы гамәлгә куелган. Соңгы еллардагы иң эре һәм әһәмиятле объектлар арасында ТРның Биектау районындагы «Казан–Әгерҗе» тимер юлы аша төзелгән юлүткәргеч һәм транспорт чишелешен; ТРның Ютазы районы территориясендәге Әпсәләм авылында 0+600 чакрымдагы күперне, М-7 автоюлындагы Идел елгасы аша булган күперне; Түбән Кама ГЭСы корылмалары аша Кама аркылы салынган күперне ремонтлауны, 1045+100, 1049+200, 1050+120 чакрымнарда җәяүлеләр өчен җир өсте юл кичүләрен төзүне атарга мөмкин.

Бүгенге көндә күперләр һәм юлүткәргечләр төзү «транспорт төзелеше» комплексының иң кирәкле һәм иң катлаулы элементлары булып санала. Әлеге комплекс һәрдаим динамик үсештә һәм күпер корылмаларын төзү, эксплуатацияләү этапларында гына түгел, проектлау чорында ук фәнни базаның нык булуын таләп итә. Приморье краенда Хабаровскидан Владивостокка кадәр «Уссури» М-60 автоюлының 540+099 чакрымындагы Кулешовка елгасы аша күперне реконструкцияләү; Невердан Якутскига кадәр «Лена» М-56 автомобиль юлының 335+101 чакрымындагы инеш аркылы күперне реконструкцияләү; Якутскидан Магаданга чаклы «Колыма» автоюлының 1171+150 чакрымындагы Светлый һәм Сюрприз чишмәләре аша күперне реконструкцияләү буенча документация эшләү уңышлы тәмамлана. Мәскәүдәге Вернадский проспектында җәяүлеләр өчен җир өстеннән 15 юл кичүе проекты әзерләнә. Компаниянең яңа объектлары киң колачлы һәм транспорт инфраструктурасы өчен әһәмиятле булулары белән сокландыра – Яшел Үзәндәге һәм Зәйдәге зур юлүткәргечләр, Кырымдагы күпер корылмалары. Әйтергә кирәк, оешма Зур Казан Боҗрасын төзү буенча да генераль подрядчы булып тора. Татарстан предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең югары сыйфаты һәм хезмәткәрләрнең оператив эшләве иң югары дәрәҗәдәге ышаныч яуларга, күләмле тендерларда җиңеп, аларны уңышлы гамәлгә куярга, күпсанлы профессиональ һәм дәүләт бүләкләренә лаек булырга мөмкинлек бирә. Чыннан да, әлеге оешманың күпьеллык хезмәте һәм көндәлек тырышлыгы ярдәмендә коммерция йөкләренең республика буенча уңайлы хәрәкәте оештырыла, территорияләр һәм районнар тоташа, аларда яшәүче кешеләр берләшә.

Руслан Зарипов,
«Русремстрой» ЖЧЖ директоры

– Хөрмәтле хезмәттәшләр, кадерле дуслар! Сезгә юбилей елында яңа зур контрактлар төзелүен һәм проектлар гамәлгә куелуын, шулай ук киләчәктә үсеш булуын телим. «ТР күперләре» АҖ коллективы, үзендә профессиональлек, осталык, максатчанлык сыйфатларын берләштереп, иң катлаулы бурычларны уңышлы үтәү үрнәген күрсәтә, шул рәвешле Татарстанның автоюллар хуҗалыгы данын бөтен илгә һәм аннан читтә дә тарата. Сезгә һәм сезнең якыннарыгызга ихластан бәхет, уңышлар һәм нык сәламәтлек телибез!

Фотолар «Русремстрой» ЖЧЖ һәм «Главтатдортранс» ДКУ тарафыннан бирелде

КҮПЕРЛӘР САЛЫП

Татарстанның автомобиль юллары тармагында күп еллар буе уңышлы эшләп килгән дәрәҗәле һәм профессиональ компанияләр арасында танылган төзүче Ринат Мөхьянов җитәкчелегендәге «Татарстан Республикасы күперләре» АҖ дә бар. Быел оешма үзенең 25 еллык юбилеен билгеләп үтә.

Хәзерге вакытта республиканың транспорт инфраструктурасы ил буенча алдынгылар рәтендә бара, моны төбәккә килүчеләр яхшы белә, ә татарстанлыларның үзләре өчен бу – зур горурлык. Уңайлылык һәм сыйфат өлкәсендәге логистика мәсьәләләрен шул рәвешле уңышлы хәл итүгә коллективның нәтиҗәле эшләве исәбенә ирешелә. Предприятие хезмәткәрләре компания тарихын 1996 елдан исәпли, нәкъ шул вакытта Республика Министрлар Кабинеты аны оештыру буенча карар кабул итә. Компаниянең тырышлыгы белән Татарстан Республикасының территориаль һәм федераль автомобиль юлларында 500 гә якын күпер төзелгән һәм ремонтланган, шул исәптән «Волга» М-7 автоюлында Идел һәм Зөя елгалары аша, «Казан–Оренбург» автоюлында Саескан Тавы авылы янында Кама аша күпер кичүләрен төзү буенча проектлар уңышлы гамәлгә ашырылган. «Татарстан Республикасы күперләре»ндә үз тармагында шактый югары казанышларга ирешкән профессионаллар эшли. Компания «ТР Төзүчеләр берлеге» төбәк коммерцияле булмаган партнёрлыгы, «Төзелеш төбәк берләшмәсе» коммерцияле булмаган партнёрлыгы, «Шәһәр төзелешен планлаштыру һәм проектлау берләшмәсе» коммерцияле булмаган партнёрлыгы һәм «Инженер-эзләнүчеләрнең милли оешмасы» коммерцияле булмаган партнёрлыгы әгъзасы булып тора.

«Татарстан Республикасы күперләре» проектлау өлкәсендә дә югары нәтиҗәләр күрсәтә – күперләргә һәм аларга илтә торган юлларга проектлар әзерли. Чирек гасыр дәвамында компания тарафыннан Татарстан Республикасындагы йөзләгән күперне проектлау, төзү һәм төзекләндерү эшләре башкарылган. Эшчәнлегенең яңа юнәлеше буларак юл-транспорт комплексы объектларына төзелеш ягыннан күзәтчелек итүне атарга була. Шул рәвешле, төзелеш контроле төркеме тарафыннан 4 объект буенча күзәтчелек алып барылган. Аерым алганда, «Лена» М-56 автомобиль юлының Невердан Якутскига кадәр өлешен, 151-155 чакрымнар һәм 58-63 чакрымнарны реконструкцияләү кебек зур проектлар турында сүз бара. Күргәнебезчә, компания эшчәнлеге республика территориясе белән генә чикләнми, ә бөтен Россияне колачлый – Мәскәүдән Уралга, Кырымнан Себергә кадәр.

Компания башкалардан үзенең тотрыклы булуы белән аерылып тора, чөнки бирелә квалификацияле хезмәткәрләрнең кадерен беләләр һәм клиентларның ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырышалар. Эшне комплекслы оештыру бәрабәренә автомобиль юллары тармагының күпер корылмаларын проектлау, төзү, эксплуатацияләү, ремонтлау һәм карап тоту этаплары югары сыйфатлы хезмәт күрсәтү циклын тәшкил итә.

Равил Гарипов,
«Каздорстрой» ААҖ Директорлар советы рәисе

– Бу юбилей елында сезнең оешмагызга алга таба да үсеш һәм яңа зур проектларны уңышлы тормышка ашыруын телим! Предприятие эшчеләренә дә хезмәткә рухландыра торган уңай кәеф телисем килә, тормышларын безнең тармак белән бәйләгән һәркем өчен бу бик кирәк. Күп эшләр башкарылган, ләкин алда яңадан-яңа бурычлар тора һәм зур казанышлар көтә! Компания өчен бу истәлекле юбилей елы яңа максатлар кую һәм аларга ирешү өчен башлангыч бирсен. Хезмәттәшләремә һәм аларның якыннарына бәхет, яхшы кәеф, уңышлар һәм, әлбәттә, нык сәламәтлек телим!

Фотолар «Каздорстрой» ААҖ һәм «Главтатдортранс» ДКУ тарафыннан бирелде

САКЧЫЛ КАРАШ – ТОРМЫШ НИГЕЗЕ

Татарстан төрле профильдәге предприятиеләр уңышлы эшләгән алдынгы төбәк булып тора. Андый предприятиеләр исәбенә «БЕТАР» фирмасы да керә – 1996 елда Чистайда төзелгән, куәтле базага һәм тиңсез тарихка ия көчле компания ул. Бүген «БЕТАР»– Россиядә энергия ресурсларын исәпләгеч приборлар җитештерә торган иң алдынгы предприятиеләрдән берсе. Быел компания үзенең 25 еллыгын билгеләп үтә.

«БЕТАР» җитештерү-коммерция фирмасы ЖЧҖ болгавыр туксанынчы елларда оеша һәм, кыенлыкларга бирешмәү генә түгел, кулланучылар арасында да, бу тармак компанияләре арасында да абруй казана һәм зур уңышларга ирешә. Кулланучыларның таләп-өметләрен акларлык, халыкара стандартларга туры килерлек һәм предприятиенең тотрыклы табышын тәэмин итәрлек алдынгы энергия саклау приборларын чыгару һәм аларны сатып алучыларга ирештерүне фирма тәүге адымнарыннан ук үзенең төп максаты итеп сайлый. Җитештерү-коммерция фирмасы 1996 елның 3 сентябрендә эшли башлый. Ә 1997 елның 1 апрелендә беренче продукция – СХВ-15 һәм СГВ-15 су исәпләгечләре чыгарыла. Конструкторлар тарафыннан әзерләүдән алып эшләп чыгаруга кадәр операцияләрнең тулы бер циклы гамәлгә куела. «БЕТАР» ҖКФ ЖЧҖ – коммуналь һәм индивидуаль су куллану системаларында эчәргә яраклы суны исәпкә алу приборларын җитештерүне үзләштергән һәм эшләтеп җибәргән республикада беренче предприятие. Предприятие искергән төр продукцияне эшләп чыгарудан баш тарта һәм кулланучыларга инновацияле җайланмалар, ягъни яңа конструкциядәге компактлы һәм ышанычлы су исәпләгечләре тәкъдим итә. ВНИИР (Казан), Татарстанның стандартлаштыру һәм метрология үзәге (Казан), «Эрготех» фәнни-җитештерү берләшмәсе (Минск), Җылылык приборлары фәнни-тикшеренү институты (Мәскәү) белән бергә «БЕТАР» салкын һәм кайнар су күләмен үлчәү өчен билгеләнгән су исәпләгечләрнең сыйфат һәм эксплуатация характеристикалары ягыннан принципиаль яңа төрен җитештерүне җайга сала. Уңышлы конструкция һәм яңа җиңел материаллар, исәпләгечләрнең төгәллеген, функциональлеген, ышанычлылыгын тәэмин итеп, чит ил продукциясе белән лаеклы көндәшлек итә.

Нәтиҗә үзен озак көттерми: беренче елда гына да 120 мең прибор эшләп чыгарыла һәм сатыла. 2000 елның июлендә миллионынчы су исәпләгече җитештерелә. Стратегик дөрес курс яшь компаниягә тиз арада әйләнешне арттырырга һәм базарда көндәшлеккә сәләтлелекне тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Коллектив су исәпләгечләрнең сыйфатын яхшырту юнәлешендә даими эш алып бара. Шунысын да билгеләп үтик: җитештерү процессы экологиягә йогынты ясамый, анда электр энергиясе, кысылган һава, су, экологик куркынычсыз чимал һәм материаллар кулланыла. Россиянең патент ведомствосында товар билгесе дә теркәлә, бу исә нәтиҗәле реклама ысулына әйләнә һәм су исәпләгечләрне ялганнан һәм фальсификациядән ышанычлы саклый. Компания шулай ук тематик күргәзмәләрдә дә актив катнаша. Актив реклама эшчәнлеге продукция сату базарын Россиянең күп кенә төбәкләренә һәм БДБ илләренә генә җәелдерү түгел, Омск, Казахстан, Белоруссия, Үзбәкстанда

Фотолар «БЕТАР» ЖКФ ЖЧҖннән алынды

уртак предприятиеләр булдырырга да мөмкинлек тудыра. Су исәпләгечләрне модернизацияләү, шулай ук газ исәпләгечләр ясау һәм җитештерә башлау компания өчен яңа адым була. Шул рәвешле СГ-1 газ исәпләгечләре, СХВ-20 һәм СГВ-20 тибындагы салкын һәм кайнар су исәпләгечләре җитештерү эше җайга салына. Җитештерүне техник яктан үстерү һәм аның нәтиҗәлелеге чыгымнарны киметергә, процессны гадиләштерергә һәм яңа технологияләр кертергә юл ача.

«БЕТАР» ҖКФ ҖЧҖ диспетчерлаштыру системасы белән комплекста мәгълүматларны читтән торып тапшырырга сәләтле исәплəгеч приборлар чыгара, андыйлар энергия ресурсларының барлык төрләре (салкын һәм кайнар су, газ, электр энергиясе) өчен эшләнә. Компания берничә ел инде «САКЛАУ» энергия ресурсларын куллануны комплекслы исәпкә алуның автоматлаштырылган системасын (АСКУПЭ) гамәлгә кертү буенча проектларны уңышлы тормышка ашыра. Әлеге система торак-коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм ышанычлылыгын арттырырга мөмкинлек бирә.

«БЕТАР» ҖКФ ҖЧҖ бүген 40 төрдән артык продукция чыгара. Төп продукция – көнкүреш газ исәпләгечләре, су исәпләгечләренең төрле модификацияләре, аларның фатирлар өчен чыгарыла торганнары, сәнәгать предприятиеләренә тәгаенләнгәннәре бар, ялгау урыны диаметры– 15 мм дан 50 мм га кадәр. Продукция фирманың дилерлар челтәре аша Россиянең 72 төбәгендә сатыла. Компания эшчәнлегенең яңа юнәлешләре–инструмент җитештерү (металл эретмәләр кою пресс-формалары, кискеч инструментлар проектлау һәм эшләү) һәм станоклар төзү (ташу-күтәрү җайланмалары, робот-манипуляторлар, автоматлаштырылган линияләрне проектлау һәм эшләү).

Фирманың үз метрология хезмәте – баш метролог департаменты эшли. 2003 елда предприятиенең су һәм газ исәпләгечләрен тикшерү хокукын аккредитацияләү турындагы актка кул куела, бу исә эталоннарга, персоналга һәм биналарга карата билгеләнгән таләпләрнең үтәлүен документ белән раслый. Бүген компания коллективы 474 кешене берләштерә.

Компаниядә хезмәткәрләр өчен уку-укыту курслары даими рәвештә үткәрелә һәм аларның квалификациясе күтәрелә. Бу эш планлы курслар, күрсәтмә мәгълүматлар нигезендә, җитештерү процессыннан аермыйча гына, хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын күтәрү рәвешендә алып барыла. Персоналның иҗади потенциалын ачу өчен, хезмәткәрләрне кызыксындыру һәм стимуллаштыруның уңайлы системасы эшли.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, «БЕТАР» фирмасының 25 еллык эш дәверендә хезмәт хакын түләү буенча бурычлар бер тапкыр да булмаган.

Клиентка төп игътибарны юнәлтү һәм ышанычлылык компания эшенең мөһим принциплары булып тора.

Компаниянең сыйфат өлкәсендә ике тапкыр РФ Хөкүмәте премияләре конкурсы лауреаты, сыйфат өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте премияләре бәйгесе лауреаты булуы, сыйфат белән идарә итү буенча Европа фондыннан иң югары бәя алуы, продукция һәм хезмәт күрсәтү сыйфаты өлкәсендәге казанышлары өчен БДБ илләре премияләре лауреаты булуы һич тә очраклы түгел. Продукциянең югары сыйфаты һәм нәтиҗәле идарә итү алымнары өчен фирма Бөтенроссия сыйфат оешмасының Дан залына кертелгән. «БЕТАР» ҖКФ ҖЧҖ хәйрия проектларына, мохтаҗларга булыша, шәһәр һәм республиканың социаль бурычларын хәл итүдә актив катнаша.

Компания су исәпләгечләр җитештерү һәм сату күләме буенча иң алдынгыларның берсе булып тора, продукциянең сыйфатын дәлилләгән Россия һәм халыкара дәрәҗәдәге 50 дән артык премия иясе ул. Продукциянең сыйфаты ISO9001 халыкара стандарты таләпләренә туры килү сертификаты белән расланган. Җитештерүдә өр-яңа җиһазлар кулланыла. Фирманың югары сыйфатлы продукциясе Техник тикшерү һәм метрология буенча Федераль агентлык тарафыннан сертификацияләнгән, су һәм газ исәпләгечләр Россия һәм башка илләрнең Үлчәү чаралары дәүләт реестрларына кертелгән.

– Компаниянең бөтен коллективын юбилей белән ихлас йөрәктән котлыйбыз! Сезнең һәрберегез – үз эшенең чын остасы, һәркайсыгызның хезмәте уртак уңышыбыз өчен, илебез һәм планетабызның табигый ресурсларын саклау өчен мөһим һәм кирәкле. Уртак нәтиҗәле хезмәтегез өчен рәхмәт белдерәбез, киләчәктә дә һөнәри уңышлар һәм нык сәламәтлек телибез! – дип котладылар предприятие хезмәткәрләрен «БЕТАР» ҖКФ ҖЧҖ президенты белән директоры Владимир Зайцев һәм Ринат Фәрдиев.

Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store

Google Play

Реклама 6+

АКЫЛЛЫ
ГАМӘЛЛӘР

игелекле эшләр

МӘҢГЕЛЕК
КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ
ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

Чувашиядә татарлар **НИЧЕК** яши

НИ ӨЧЕН 65 нче мәктәптә һәрвакыт «зәңгәр» ут яна

Татар киносын **НИНДИ** үзгәрешләр көтә

Олы мич **НИНДИ** кодрәткә ия

ЧИШМӘ СУЫНА – ЧУВАШСТАНГА

Автор: Алсу Троицкая

«Татарстан»ның татарлар күпләп яшәгән күрше республика һәм өлкәләр буйлап экспедициясе дәвам итә. Бу юлы журналистлар Чувашстанның Козловка районына юл тотты – халкының 98 проценты татар булган Янгилде авылына. Алар үзләре авылларын Кармыш дип тә атый.

Бер авылның нигә ике исемле булуын безгә Янгилде Мәдәният йорты мөдире Лилия Галиева аңлатты:

– Авылга нигез салучы Кармыш исемле булган, диләр. Риваятьтә сөйләнгәнчә, Явыз Иван хакимлек иткән чорда ул, чукындырудан качып, Тәтеш авылыннан бирегә, хәзер Янгилде авылы урнашкан җиргә килеп урнашкан. Әлеге легенданы Каюм Насыйриның этнографик хезмәтләре дә раслый, галим Янгилде авылы халкын борынгы Тәтеш нәселенә тоташа, дип санаган.

«Чишмә» вокаль коллективына йөрүчеләр милли татар киемендәге фотосессия өчен авыл Мәдәният йорты сәхнәсе артында бизәнгән-ясанган арада, Лилия Галиева безне авыл тарихы белән таныштыруын дәвам итә:

– Кармыш үз гаиләсе өчен уңайлы урынны шактый озак эзләгән, диләр. Ул төпләнергә ниятләгән урыннарында йоклап караган. Тик бөтен җирдә куркыныч төшләр күргән, бастырылган. Ә менә татарлар белән чувашлар яшәгән Әлмән һәм Семенчино авыллары янына килеп җиткәч, таныш түгел бер чишмә буенда бик тыныч йокыга талган. Төшендә умарта күче һәм бик күп көмеш тәңкә күргән. Әлеге төшен ул болай юраган: көмеш тәңкәләр – байлык-муллыкка, умарта күче – үрчемле нәселгә...

Һәм ул нәкъ шул чишмә янында төпләнергә карар кылган. Бу кизләүне шул вакыттан бирле «Тәңкә чишмәсе» дип йөртәләр. Кармышның ике улы булган. Янгилде исемлесе белән авылга нигез салган. Шуңа күрә аларның икесенең дә исеме – Кармыш та, Янгилде дә – авылга берегеп калган.

– Ә бит Кармышка мондый күрәзә төш тикмәгә генә кермәгән, ул чынга ашкан, – дип елмаеп сүзгә кушыла авыл китапханәчесе Резеда Төхфәтуллина. – Һәрхәлдә, байлык-муллыкка караган өлеше. Янгилде үз вакытында Чабаксар өязендәге иң зур татар авылы, сәүдә һәм мәгариф үзәге булган. Авыл бөтен әйләнә-тирәне көн дә кирәкле товарлар белән тәэмин иткән, бирелән Россиянең төрле төбәкләренә йомырка, тире җибәрелгән. Биредә күн заводлары һәм бояу мануфактурасы гөрләп эшләгән, ә өч мәчеттә өч указлы мулла балаларга һәм бөтен авыл халкына дин сабагы биргән...

Фото: Александр Ефремов

ЯНГИЛДЕ – ЧИШМӘЛӘР ҮЗӘНЕ

Безне мәдәният йортында ук бәлешләр белән чәй эчәргә утырткан сөйкемле ихлас ханымнар фикеренчә, нәкъ менә дин һәм гореф-гадәтләргә тугрылык биредә бүген дә туган телне һәм мәдәниятне саклау мөмкинлеген бирә. Һәм тагын... чишмәләр.

Мөгаен, йөзләрчә ел элек авыл урынын сайлаганда Кармыш аның географиясенә дә игътибар иткәндер. Авылларындагы чишмәләрнең санын ачыкларга маташканда, хатын-кызлар төгәл генә җавап бирә алмый – әллә җиде, әллә сигез шунда. Нәтиҗә мондый:

– Безнең Янгилде – чишмәләр өчен оҗмах ул.

Янгилде чишмәләренең матурлыгы һәм суының тәме белән рәхәтләнеп хозурланыр өчен, бирегә җәен килергә кирәк икән. Иң яхшысы – августта. Дания Сабирова әйтүенчә, «Бәйрәш» чишмәсе көне шул айда үткәрелә:

– Ел саен бу бәйрәмгә без генә түгел, Янгилдедән күптән чыгып китүчеләр һәм тирә-күрше авыл халкы да җыела. Безгә терәлеп диярлек чувашларның Семенчино авылы урнашкан – чишмәләр үзәне генә аерып тора. Менә шулай янәшә яшәп ятабыз инде – мөселманнар, православие динендәгеләр һәм мәҗүси-чувашлар. Мәчет, кәшәнә һәм «Юпа» йола баганасы биредә һәркемгә

Төзекләндерелгән чишмәләр, парклар, авыл бәйрәмнәре, Бөек Ватан сугышында катнашкан Янгилде каһарманнарына һәйкәлләр һәм истәлек такталары – боларның барысы да якташлар тырышлыгы белән булдырыла һәм саклана.

«Чишмә» вокаль коллективы.

Зәйтүнә Абдулбарый кызы Гыйсмәтуллина (уртада).

Бөек Ватан сугышына Янгилдедән 262 кеше киткән. Нибары 45е генә әйләнеп кайткан. Алар арасында Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Мидхәт Салихов та бар, мәктәп аның исемен йөртә. Авыл паркы Дан орденының тулы кавалеры Ярхәм Бикчәнтәев исеме белән аталган.

таныш. Барлык милли бәйрәмнәрне бергә билгеләп үтәбез. Безнең Сабан туена Семенчино күршеләребез килә. Көн авышкач, чувашларның кичке уеннары «Вайа»га без барабыз. Гасырлар буе янәшә яшәгәч, гореф-гадәтләребез дә охшаш, бер-берсеннән бик аз гына аерыла.

Тау битеннән бәреп чыккан салкын чишмәләр турында күптәннән мәгълүм. Моннан берничә ел элек Янгилде һәм Семенчино халкы бергәләп аларны төзекләндерергә ниятләгән. «Бәйрәш», «Тәңкә инеш», «Урта инеш», «Шанчас» кизләүләрен чистартканнар да инде. Татарлар һәм чувашлар бергәләп төзекләндергән ял зонасы пәйда булган. Чатыр, мангал төзегәннәр, янәшәсенә утын да өеп куйганнар – алай-болай кунакларга кирәксә, бар нәрсә әзер.

ТЫЛДАГЫ БАТЫРЛЫК

Янгилдедән җиденче сыйныф укучысы Зәйтүнә Гыйсмәтуллина әти-әнисе белән таштай каты җирне казый. Көрәк һәм кәйләдән башка кораллары юк. Ничек тә эшне җиңеләйтмәкче булып, башта җир өстен учак ягып җылыталар, аннары тагын чокыйлар. 1941 елда Сыры (Сүрә) саклану сызыгы шулай казыла.

Зәйтүнә Габделбарый кызына 4 майда 97 яшь тула, әмма әлеге авыр вакытларны ул әле хәзер дә бик яхшы хәтерли:

– Безнең авылдан бик күп кешене окоп казырга җибәрделәр. Мине исә мәктәптә дәрестә утырган җиремнән алып киттеләр. Кая, нигә икәнен аңламый да калдым. Барып җиткәч, нишләргә кирәклекне күрсәттеләр. Киңлеге 4–5 метрлы, тирәнлеге 3 метрлы окоплар казырга кирәк иде. Бертуктамый коеп яңгыр ява, пычрак, аннары кырык градуслы суыклар башланды. Эшкә иртәнге 6 да китеп, кичке 5 тә генә кайта идек. Бик авыр булды. Мине тагын берничә хатын-кыз белән Баланово авылында Анна Теренкова өенә урнаштырдылар. Хуҗабикә бик игелекле булып чыкты, кайткан җиребезгә борчаклы аш пешереп куя иде. Чабатам тишелгәч, мине кызганып, ул миңа яңа, бик калын оекбашлар бирде – шулай аягымны өшүдән саклап калды...

Чувашстаннан 100 меңнән артык кеше 45 көн эчендә мөмкин булмаганны эшли – 380 чакрым арада саклану конструкцияләрен төзи. 1942 елның 21 гыйнварында эчке эшләр халык комиссары Лаврентий Берия исеменә телеграмма җибәрелә: Казанга, Куйбышев һәм Ульяновскига бару юлларында гитлерчыларның гаскәрләрен тоткарлау өчен саклану сызыгының төзелеп бетүен хәбәр итәләр...

КАН АВАЗЫ

Фәнзия Хәйруллина Янгилдедә туып-үскән. Ул, татарлар Чувашстанда бик рәхәт яши, дип саный, аларның традицияләре һәм теле нигездә локаль яшәү урыны хисабына саклана:

– Гаиләләребездә без татарча сөйләшәбез, дини бәйрәмнәрне һәм гореф-гадәтләрне саклап калдык. Хәтта атеистик совет заманында да кача-поса намаз укыганнар. Бүген исә үзеңнең дини, мәдәни һәм рухи мәнфәгатьләреңне канәгатьләндерү өчен гомумән бернинди кыенлык та юк. Милли традицияләргә мәхәббәтне ниндидер проектлар белән генә уятып булмый, ул балага ана сөте белән күчә. Бу – кан авазы... Без үзебезнең ата-бабаларыбыз горефләрен онытмыйбыз. Менә «Чишмә» вокаль коллективын алыйк. Ул нәкъ менә шуның өчен оештырылды да.

ДАЧА УРЫНЫНА

– Элегрәк авылларда, язылмаган закон буенча, төпчек малай һәрвакыт әти-әнисе белән калган. Шунлыктан һәр йортта тор-

Кайчандыр Кармышта өч мәчет булган. Бүгенге мәчеттәге өч манара шул турыда искәртеп тора. Имам-хатыйбы – Әхмәт хәзрәт Мифтахетдинов. Каникулда шәһәрдән әби-бабалары янына кайткан балалар өчен ел саен җәен мәчеттә мөселман лагере оештырыла.

мыш кайнаган, ташландык өйләр булмаган, – дип дәвам итә дустының хикәятен Фәния Төхфәтуллина. – Ә хәзер карагыз инде, авылларда кем яши? Безнең кебек пенсионерлар гына. Күп йортлар дача урынына калды – хуҗалары ял вакытында гына кайта. Бездән Казан ерак түгел, һәм авылда үз йортың булу бик уңайлы. Яшьләр китә, чөнки эш юк. Мәктәптә балалар да аз калды, киләсе елга япмасыннар иде инде, дип борчылабыз. Менә бу авылның зур әрнүе...

ЯНГИЛДЕ ПОЛИГЛОТЛАРЫ

Калфак кигән кызлар, түбәтәйле малайлар, янәшәләрендәге укытучылары да милли киемнән. Барысы да, елмаеп, Габдулла Тукайның һәр татар өчен бик якын, бик кадерле булган җырын суза:

– И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Янгилде тугызъеллык мәктәбенең инглиз һәм немец телләре укытучысы Равилә Хәкимова, үзенең бер социаль челтәрдәге сәхифәсен күрсәтеп, сөенеп сөйли:

– Менә биредә без Туган тел көнен үткәрәбез. Балаларга да, безгә дә бик ошады. Безнең укучыларны чын полиглот дип әйтергә була. Күз алдына китерә аласызмы, күп дәрестә без дүрт телдә – рус, татар, чуваш, инглиз телләрендә аралашабыз. Хәзер әле немец теле дә өстәлде.

Янгилде мәктәбендә якын-тирә авыллардан 24 бала укый, шулардан унысы – татар. Мәктәпнең икенче катындагы фойеда татар йортындагы көнкүрешкә багышланган экспозиция урнашкан, икенче якта исә чуваш хуҗалыгын тасвирлаган шундый ук күргәзмә бар. Экспонатларны карап йөргәндә, укытучылар белән сөйләшәбез. Алар балаларның аз булуына хафалана һәм бер-ике елдан мәктәпнең ябылуыннан курка. Аннары укырга Түрлемәгә йөрергә туры киләчәк:

– Мәктәбебез зур, якты, чиста, ә иң мөһиме, укыту өчен бөтен кирәк-ярак бар. Экраннар, китапханә, ашханә, күптән түгел спорт залын ремонтладылар. Балалар гына юк...

Мәктәп китапханәсендәге күргәзмәдә татар һәм чуваш телендәге әдәбият янәшә киштәләрдә тора.

– Без һәрвакыт бергә яшәдек, укыдык, эшлибез. Бездә: «Син чуваш, ә син – татар», дип бүлү юк, – дип аңлата рус теле һәм әдәбияты, шулай ук татар теле укытучысы Халидә Мөхәммәтҗанова. – Биредә без барыбыз да өч телдә: ана телебездә, чуваш һәм рус телләрендә аралашабыз. Көнкүрештә кулланыла торган чуваш телен җирле татарлар гел белгән, чувашлар да алар белән татарча сөйләшкән. Көн саен аралашканда телне өйрәнү җиңел ул.

– Безнең балалар үзенә бертөрле мохиттә яши. Һәм аларга башка тел шартларына яраклашу җиңел булачак, – дип, коллегасының сүзен җөпли чуваш теле укытучысы Ирина Борисова. – Мин үзем күрше Семенчино авылыныкы, әмма бу мәктәптә укыдым, хәзер инде күп еллар буе биредә укытам. Бергәләшеп чувашча да, татарча да спектакльләр куябыз. Хәтта балалар өчен спорт уеннарын да милли колорит белән үткәрәбез.

Күрәсең, көнкүрештәге мондый симбиоз янгилделеләрнең теленә дә йогынты ясагандыр. Биредә хәтта үзләренең диалекты да формалашкан:

Киек – тычкан
Тустыган – чүмеч
Әнчек – эт
Ләүш – пирог
Апай – апа
Бармалы-кайтмалы – барырга кирәк-кайтырга кирәк

P.S. Янгилде татарларына башка милләт вәкилләре белән тату яшәр өчен сәяси корректлылыкка өйрәнергә кирәкми. Бу аларның канына сеңгән. Дин, гореф-гадәтләр, мәдәният төрле булырга мөмкин, әмма имин күршелек һәм дуслык теле һәркемгә дә сүзсез аңлашыла.

БЕЗ ЯШИ ТОРГАН ДӨНЬЯ

Азәрбайҗанча чын пылау ашап, долманы дөрес итеп пешерү өчен яфраклар кайдан һәм кайчан җыелырга тиеш – шуны белеп, өйдә әзерләнә торган ризыкларның тарихи технологияләрен өйрәнеп – бер сүз белән әйткәндә, Казан ипподромында узган Нәүруз бәйрәменә килгән кунаклар, борынгы азәрбайҗан мәдәнияте белән танышып, аны яратып китте. Менә күп еллар инде азәрбайҗаннарның Татарстандагы диаспорасы бәйрәм тантаналарын үткәрүгә үзенең саллы өлешен кертә.

– Нәүруз кунакларының безнең мәдәният белән ни дәрәҗәдә ихлас кызыксынуларын сөйләве дә күңелле. Элегрәк безнең янга милли ашларыбыздан авыз итәргә дип кенә киләләр иде. Быел шундый күп сораулар бирделәр, тирән мәгънәле булулары да сөендерде, – дип сөйли Азәрбайҗаннарның Татарстан Республикасындагы Төбәк иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Бахрам Мостафаев. – Якташларга мондый чаралар туган мәдәниятләрен күрергә, искә төшерергә, тамырларын барларга ярдәм итә. Башка милләт вәкилләре исә безнең турыда күбрәк белеп китә. Азәрбайҗанның нинди илләр белән чиктәш булуын күпләр әйтә алмый, шулай ук без – СССР таркалганнан соң, рус телле мәктәпләр ачылган бердәнбер республика. Нәүруз кебек бәйрәмнәрдә сүз, гадәттә, пылау төрләре турында сөйләшүдән башлана (сүз уңаеннан, алар бездә 100дән артык) һәм, Бакуга елның кайсы фасылында кунакка бару яхшырак, дип тәмамлана.

Бахрам Талиб улы диаспораның актив эшчәнлеге Татарстан җитәкчелегенең булышлык итүе нәтиҗәсендә мөмкин булды, дип билгеләде. Чараларның күп өлешен диаспора Халыклар дуслыгы йортында үткәрә, анда һәрбер халыкның милли оешмасына мондый мөмкинлекләр бирелә. Бахрам Талиб улы билгеләвенчә, башка төбәкләрдә дә шундый эшләр алып барыла, әмма оештыру җәһәтеннән Татарстан дәрәҗәсенә җиткәне юк әле.

Халыклар дуслыгы йортындагы иң мөһим проектларның берсе – якшәмбе мәктәбе.

– Мәктәпкә йөрүче балаларның күбесе бирегә туган һәм тарихи ватаннарында әле бер дә булганнары юк. Якшәмбе мәктәбендә алар туган телләрен өйрәнә ала. Безнең сыйныфта төрле яшьтәге балалар бар – 6 дан 16 яшькәчә. Теләүчеләр бар икән, икенчесен дә ачабыз, – ди Бахрам Талиб улы. – Халыклар дуслыгы йортында бик күп түгәрәкләр, секцияләр эшли, без башка диаспоралар белән чаралар үткәрәбез. Бу яшьләр өчен бик файдалы. Бары тик уртак эшләр генә башка халыкларның традицияләренә ихтирамлы мөнәсәбәтнең ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген, моның күпмилләтле республика тормышына уңай тәэсир итүен аңларга ярдәм итә.

Тел һәм мәдәниятне саклаудан тыш, диаспора мөһаҗирләрнең адаптация үтүенә бәйле мәсьәләрне хәл итү белән дә шөгыльләнә. Аның вәкилләре даими рәвештә чик һәм миграция хезмәтләре хезмәткәрләре һәм прокуратура, приставлар, юристлар белән очрашып тора.

– Без Азәрбайҗаннан килгән гражданнарга, ярдәм яки юридик киңәш сорап, безгә мөрәҗәгать итә аласыз, дип әйтәбез. Бу исә аларның сорауларын тизрәк хәл итәргә, судларның эшен киметергә мөмкинлек бирә, – ди диаспораның җитәкчесе. – Без шулай ук тәртип саклау органнарыннан килгән сигналларга да җавап бирәбез. Яшьләр белән профилактик әңгәмәләр үткәрәбез. Тыныч юл белән хәл итәргә тырышабыз. Диаспора шуның өчен кирәк тә.

Татарстанның районнарында һәм эре шәһәрләрендә дә азәрбайҗаннарның җирле төбәк иҗтимагый оешмалары ачыла. Аларның барысы да Халыклар дуслыгы йорты белгечләре ярдәме белән төрле очрашулар һәм чаралар оештыру эшенә кушылып китә.

– Пандемия безнең икътисадта гына тискәре чагылыш тапмады, ул кешеләрнең кәефенә дә үз йогынтысын ясады. Шуның өчен дә Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы – рухыбызны күтәрер өчен менә дигән форсат. Безнең планнар зурдан, – ди Бахрам Талиб улы. – Азәрбайҗанда 2021 ел азәрбайҗаннарның классик шагыйре, акыл иясе, XII гасыр галиме Низами Ганҗәви елы дип игълан ителде. Без аның хөрмәтенә Татарстанда зур концерт оештырырга телибез. Эпидемия вазгыяте йомшаруга оештыру эшләрен башлаячакбыз. Без Татарстанга бу эштә дә, башка күпсанлы проектларыбызны тормышка ашыруда да ярдәм итүе өчен бик рәхмәтлебез.

Фото «Азәрбайҗан» Милли-мәдәни мохтариятеннән алынды. Реклама

АЛАР НИБАРЫ БАШКА ТӨРЛЕ. БАРЫ ТИК БАШКАЧА ЯКЫН КИЛҮ КИРӘК

Календарьдагы бәйрәм көннәренә торган саен яңа төсләр өстәлә бара. Алар безнең төрле булуыбызны искәртә. 26 март шәмәхә көн – Халыкара эпилепсия көне. 2 апрельдә зәңгәр төсле көнне билгеләдек – аутизм турында мәгълүмат тарата торган көн. Шәһәрләрдә зәңгәр төстәге шарлар очып йөрде, тәрәзәләрдә зәңгәр утлар кабынды, социаль челтәрләрдәге хештеглар аутизм турындагы мәгълүмат белән бүлеште. #мыпростодругие – зәңгәр көннең төп хештегы. Анда аутист балаларның әти-әниләре андый балаларга ничек итеп ярдәм итеп булуы турында сөйли. Дөньядагы һәр 68 нче бала шушы диагноз белән туа бит.

Казанның 65 нче мәктәбендә аутист балаларга 2017 елдан алып булышa башлаганнар.

Биредә мондый балалар мәктәп мохитенә шактый җиңел иялэшә, сыйныфтан тыш төрле чараларда, уен программаларында, мастер-классларда, тәнәфесләрдә уеннарда актив катнаша ала, дип саныйлар. Бу аларның сәламәтлегенә, социумда үз-үзен тотышына һәм үсешенә уңай тәэсир итә.

ҮСЕШ ӨЧЕН ШАРТЛАР БУЛДЫРУ

«65 нче санлы мәктәп» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә 441 укучы укый. Алар арасында сәламәтлеге чикләнгән 17 бала бар, шуларның 11е аутист бала. Уку-укытуда ихтыяҗлары төрле булган, үсешкә, хезмәттәшлеккә, социумга җиңел иялэшеп китүгә сәләтле укучыларның шәхес потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру – мәктәпнең өстенлекле юнәлешләренең берсе. Шуңа да сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен биредә махсус ресурслар сыйныфы эшли.

УЙЛАП ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛГАН

Класс бүлмәсе һәр бала өчен индивидуаль эш урыннары һәм уен зонасы белән җиһазландырылган. Балалар фронталь дәресләр кабинетында да, белгечләр белән индивидуаль дәресләр кабинетында да шөгыльләнә ала. Алар белән дефектолог, логопед, психолог укытучылар, ресурс педагогы һәм балаларны озатып-карап торучы һәм уку материалын үзләштерергә ярдәм итүче ун кече тәрбияче эшли. Казан Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе ярдәме белән мәктәпнең штаты арттырылган, хәзер биредә кирәкле белгечләрнең барысы да бар.

Көн саен балалар расписание буенча дәресләргә йөри, аннан соң белгечләр белән аерым-аерым шөгыльләнә, аннан соң өстәмә белем ала.

ЯШЬТӘШЛӘРЕ БЕЛӘН БЕРГӘЛӘП

Коррекцион-үстерү эше индивидуаль һәм төркемләп, дәресләрдә алып барыла, алар баланың үз-үзен тотышын коррекцияләүгә, уку һәм язу, санау күнекмәләре белән бәйле артта калганнарны өлгертергә, игътибар һәм хәтерне үстерүгә юнәлтелгән. Инклюзив белем бирүнең мөһим бурычларының берсе – белемнәрне һәм социаль тәҗрибәне яшьтәшләре белән бергә алу. Монда волонтерлык ярдәмгә килә. Мәктәптә «Игелек юлыннан барабыз» проекты «Яшь волонтер» түгәрәгендә гамәлгә ашырыла. Аутизм спектрлы авырулары булган укучылар мәктәпнең волонтерлары белән бергәләп, актив рәвештә төрле сыйныфтан тыш чараларга һәм уеннарга кушылып китә. Сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен бу яшьтәшләре белән аралашу, үз-үзен күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлек. Ә сәламәт балалар өчен бу мөмкинлекләре теге яки бу җәһәттән чикләнгән кешеләр белән аралашырга өйрәтә торган практика.

БЕЗ ТӨРЛЕ, ӘММА КЫЙММӘТЛӘРЕБЕЗ – БЕР

Озак еллар инде мәктәптә Сәнгать мәктәбе эшли. Педагоглар ритмика буенча «Без төрле, әмма кыйммәтләребез – бер» дигән өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыра. Болар сәламәт һәм сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен төркем белән үткәрелә торган дәресләр. Алар музыкаль уеннар һәм импровизацияле биремнәр рәвешендә уза, музыкаль кабул итү сәләтен үстерә, музыканың тәэсире турындагы күзаллауларны киңәйтә. Балалар музыка һәм ритмны тою сәләтләрен үстерә.

УРТАК ПРОЕКТЛАР ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАР

Алда мәктәпнең матди һәм дидактик базасын камилләштерү, сенсорлы ял итү бүлмәсен җиһазландыру планнары тора. Педагоглар беренче сыйныфка киләчәк аутист балаларны мәктәпкә әзерләүне оештыру, ата-аналарны балаларның уңышлы социальләшүенә ярдәм итә торган уртак проектларга җәлеп итү турында хыяллана. Шулай ук мәктәптәге сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен өстәмә белем бирүне киңәйтү планлаштырыла. Балчыктан әйберләр ясау түгәрәге оештыру турында сүз бара, чөнки балчык еш кына тойгылар белән хисләр арасында күпер ролен уйнаучы билгеле бер сенсорлы тойгыларны уятырга сәләтле, шулай ук агрессияне контрольдә тотарга ярдәм итә.

УҢАЙ ҮЗГӘРЕШЛӘР

Теләсә кайсы баланың белем алырга хокукын гарантияли торган мәгариф турындагы яңа закон кабул ителгәннән соң, әлбәттә инде, сәламәтлекләре чикле балаларның мәктәптәге үсешендә күп кенә уңай үзгәрешләр барлыкка килде. Казанның 65 нче мәктәбендәге «зәңгәр» төс турындагы төп күзәтүне болайрак әйтергә була: аутист балаларның мәктәп социумындагы тормышы уңайлы булсын өчен, җәмгыятьчелеккә андый балалар турында күбрәк сөйләргә, аңлатырга кирәк. Алар бары башка төрле, аларга башкачарак якын килергә кирәк. Ә моның өчен махсус педагогларның әзерлеген яхшыртырга, практикага юнәлтелүенә басым ясарга кирәк.

Фото Казанның Мәскәү районы «65 нче мәктәп» МБМУнән алынды. Реклама

ТАТАР КИНОСЫ

Автор: Ксения Сёмина

Пандемияле 2020 ел азагында киң прокатка «Әпипә» дип исемләнгән беренче татарча фильм-мюзикл чыкты. Бу вакыйганы ничек шәрехләргә: әле онытылып өлгермәгән үткәнгә кайтумы, әллә инде билгесез яңалыкка бер адыммы? Мәсьәләне «Татарстан» өйрәнде.

Фото: Ната Смирнова; төшерү төркемнәреннән алынды

Картина татарстанлыларга яхшы таныш мәдәни кодларга корылган – романтик мәхәббәт тарихы комедия кысаларында бирелә һәм заманча татар эстрадасы башкаручыларының күпсанлы музыкаль композицияләре белән баетыла.

Әлеге мюзикл моннан 15 еллар элек республика телевидениесендә дөньяга чыккан «Ялгыз калган яшьлек» һәм «Мәхәббәт сынавы» фильмнарын хәтерләтте. Әмма шушы еллар эчендә Татарстан киносы бөтенләй үзгәргән.

ПРОКАТКА ЧЫГА БАШЛАДЫК

Шуны әйтергә кирәк: Татарстанда уен киносы, ягъни «игровое кино» жанрының үсеш юлы сикәлтәле булды. 2000 еллардан башлап федераль кино белгечләренең уңай бәясен алган ленталар Татарстан территориясендә биш елга бер тапкыр төшерелде (2004 ел – «Күктау», Илдар Ягъфәров; 2009 ел – «Бибинур», Юрий Фетинг; 2014 ел – «Корбан-роман», Салават Юзеев). 2016 елда Татарстан, берьюлы 12 фильм чыгарып, кино җитештерә торган төбәкләр сафына басты. Бүген бездә кино төшерү белән теге яки бу дәрәҗәдә шөгыльләнә торган берничә оешма эшләп килә – «Татаркино», Татарстан кинематографчылар берлеге, «Время кино» берләшмәсе, Казан мәдәният институты.

Соңгы елларда кино өлкәсендәге иң зур уңышлардан берсе – Татарстан киносының киң прокатка чыгуы. Инде лидерларны да атап китик: «Водяная» (ил буенча һәм чит илләргә дә прокатка чыга алган беренче Татарстан лентасы, гомуми җыем – якынча 3,5 млн сум), «Кире»/»Упёртый» (якынча 510 мең сум), «Айсылу» (407 мең сум тирәсе), «Мулла» (татар телендә русча субтитрлы фильм, 400 мең сум чамасы). «Водяная», «Кире» һәм «Пустота» картиналары стриминг платформаларга урнаштырылган беренче Татарстан фильмнары буларак тарихка кереп калыр. Якын арада стримингта шулай ук «Байгал» да тәкъдим ителәчәк. Татар телендә төшерелгән, русча субтитрлы «Әпипә» прокатка ноябрьдә чыкты. Лентаны Татарстан кинотеатрларында, татарлар күпләп яшәүче берничә төбәктә күрсәттеләр, шулай ук Мәскәүдә һәм Россиянең башка төбәкләрендә Татарстан киносы көннәре кысаларында тәкъдим иттеләр. Картина 390 мең сум чамасы касса җыйды. Хәзерге вакытта фильм төбәк кинотеатрларында күрсәтелә, стриминг платформаларына да урнаштыру күздә тотыла.

ЯШЬЛӘРГӘ МОНДА УРЫН ЮК?

Шулай итеп, процесс Татарстанга моңарчы хас булган темпларда дәвам итә – тарихи рәвештә республиканың беркайчан да кино башкалалы төбәк статусына дәгъва кылганы булмады. Альбина Нәфыйгова билгеләвенчә, бүген республикабыз кино җитештерү буенча Россия төбәкләре кинорейтингында ныклы икенче урында бара. Рейтинг фильмнар җитештерү һәм прокатка чыгару, фестивальләрдә актив катнашу, профильле югары уку йортлары, төрле проектлар, һөнәри берләшмәләр булу-булмау кебек күрсәткечләр буенча төзелә. Шуңа да карамастан, республика исемлектәге лидер – Якутиядән нык калыша. 2019 ел башына бишьеллык нәтиҗәләре буенча Татарстанда рәсми рәвештә 18 фильм теркәлгән булса, Саха Республикасында аларның исәбе 51 гә җитә. Әмма үзебезнең кинематографны кызганырга сәбәпләр моннан башка да җитәрлек.

– Бездә милли сюжетлы кино жанрына шартлы рәвештә кертергә мөмкин булган фильмнар бар, һәм яшьләрнең авторлык киносы бар. Ә алар арасында – бушлык. Шул ук якут

1

«Мулла» фильмын төшергәндә (реж. Әмир Галиәскаров, Рамил Фазлыев, 2018 ел).



«Байгал» фильмыннан (реж. Илдар Ягъфәров, 2018 ел).

«Кире»/»Упертый» фильмыннан (реж. Илсөяр Дамаскин, Рөстәм Рәшитов, 2019 ел).

кинематографында, мәсәлән, барлык жанрларда да төшерәләр, – ди форумның сайлап алу комиссиясе координаторы, кино белгече Әдилә Хәйбуллина. – Һәм бездәге сюжетларның үсеш мөмкинлекләре дә томанлы. «Время кино» химаясендә «7 көн эчендә кино», милли кино өлкәсендәге казанышлар һәм яшь авторлар өчен «Алтын тәлинкә»/«Золотая тарелка» төбәкара кинопремиясе, Халыкара яшьләр кинофестивале кебек проектлар дөньяга туды. Алар барысы да эш башлап җибәрүче командаларга үсәргә, үзләрен танытырга, төшерә башларга ярдәм итте. Әмма аннары бу егет-кызлар төрле якка таралыша. «Кире»нең режиссёры Рөстәм Рәшитов, шул ук Павел Москвин, Әлфия Шакирҗанова, Рим Шәфигуллин, «Киногрех» дип исемләнгән иситкеч чыгарылыш эшен төшереп кенә бетергән Никита Зубков, операторлар Юрий Данилов белән Руслан Косенко – алар барысы да һәм тагын бик күпләр бүген инде йә Мәскәүдә, йә Санкт-Петербургта.

Кадрларның китүе – айсбергның түбәсе генә әле ул. Республика киноиндустриясендә килеп туган хәл яшьләрне генә түгел, аягында нык басып торган кино әһелләрен дә пошаманга сала.

– Минем үзебезнекеләр өчен татар телендә, татар классикасына нигезләнгән кино төшерәсем килә. Әмма бу кино беркемгә дә кирәкми, аны прокатка алмаячаклар, – ди Татарстан кинематографчылар берлеге рәисе Илдар Ягъфәров. Аны шулай ук документаль кино өлкәсендә эш тукталып калу да борчый.

– Берничә ел элек миннән республиканың бер предприятиесе турында фильм төшерүемне үтенделәр. Архивта бу оешма директорларының 80 нче еллардагы чыгышларын, җитештерү барышын яздырган кадрлар таптым. Бу материалның барысын да Казан кинохроника студиясе төшергән. Бу студия инде күптән юк, һәм оешмалар, анда эшләүче кешеләр турында мондый «консерв»ларны сезнең һәм безнең турында инде беркем дә төшерми, – ди режиссёр. – Ә бу бит безнең тормышны документлаштыру дигән сүз, нинди бар – шундый итеп. Балаларыбызга

ни калдырырбыз соң? Төбәк үзенең кино сәнгатен үстерү юнәлешендә эшли икән, бу бит аның җитлеккәнлеге, үз мәдәниятенә карата, аны саклауга, дөнья һәм вакыт киңлекләрендә танытуга карата җаваплылыгы турында сөйли. Цифрлаштырылган мәгълүмат исә мәңге сакланачак.

«ТӨРЛЕ ЯШЬТӘГЕ ТӘҖРИБӘЛЕ КИНЕМАТОГРАФЧЫЛАР БАР, ҖИҺАЗЛАР, ПАВИЛЬОННАР, МЕНӘ ДИГӘН ИДЕЯЛӘР ДӘ ҖИТӘРЛЕК. ӘММА ДӘҮЛӘТ ДӘРӘҖӘСЕНДӘ КИНОГА ИГЪТИБАР ЮК, ХОСУСЫЙ ЗАТЛАР БУ ӨЛКӘГӘ АКЧА ТЫКМЫЙ, ЧӨНКИ ПРОКАТ ЮК, МӘСКӘҮ СТУДИЯЛӘРЕ КИЛЕР ИДЕ – БЕЗДӘ КИНОКОМИССИЯЛӘР ҺӘМ РИБЕЙТЛАР ЮК».

ТАМАШАЧЫНЫ КӨТКӘНДӘ

– Республика тирән, мәгънәле, көтелмәгән кино күрергә тели. Тамашачының мондый фильм өчен кинотеатрда түләргә әзер булуында шикләнәм, әмма барыбер көтә ул, – ди «Әпипә»нең режиссёры Илшат Рәхимбай.

Татарстан кинематографчылары шуңа басым ясый: киноиндустрия үсеше өчен республиканың техник мөмкинлекләре һәм кадрлары бар. Бары тик бер генә әйбер җитми.

– Күз алдына китерегез, нинди дә булса бер шәһәрдә футбол стадионы салып, бик яхшы йөз футболчыны җыйганнар, ди. Бу шәһәрдә футбол бар, дигән сүзме бу? Юк! Футбол булсын өчен, клублар оештырырга, алар командаларны танытырга, спортчыларга хезмәт хакы түләргә, ярышлар уздырырга, матчларга стадионны тутырырлык итеп билетлар сатарга, телетрансляцияләр, фанатлар хәрәкәте булырга тиеш. Боларны оештырмаганда, стадионны үлән басып китәчәк, ә футболчылар башка клубларга таралачак – үзләренең талантларын күрсәтә һәм бәясен алырдай командаларда уйнаячак, – ди режиссёр Алексей Барыкин. – Бездә нәкъ шундый хәл күзәтелә дә. Төрле яшьтәге тәҗрибәле кинематографчылар бар, җиһазлар, павильоннар, менә дигән идеяләр дә җитәрлек. Әмма дәүләт дәрәҗәсендә кинога игътибар юк, хосусый затлар бу өлкәгә акча тыкмый, чөнки прокат юк, Мәскәү студияләре килер иде – бездә кинокомиссияләр һәм рибейтлар юк.

Республикада төшерелгән әзер кинопродуктның да сыйфатында хилафлыклар бар.

– Без Татарстан Мәдәният министрлыгы субсидиясенә төшерелгән фильмнарның сыйфаты буенча берничә ел дәвамында федераль белгечләр катнашында конференцияләр үткәрә килдек. Алар билгеләгәнчә, әлегә безгә һөнәри осталык җитеп бетми, – ди «Татаркино» директоры Миләүшә Айтуганова.

Шуны искәртик: 2020 елда республика Мәдәният министрлыгыннан бирелгән субсидия күләме 7,7 млн сум тәшкил иткән. Бу акча 10 кинопроектка бүленгән. Чагыштыру өчен: Якутиянең «Пугало» дип исемләнгән авторлык киносының (2021 ел, касса җыемы – 11,4 млн сум чамасы) бюджеты 1,5 млн сум. Илдар Ягъфәровның «Байгал» картинасының бюджеты (киң экраннарда күрсәтү өчен) – 15 млн сум (кассада җыемы 32 мең сум тирәсе). Шул ук вакытта 2020 елда Россия Кино фондында хәбәр итүләренчә, 2015 елда Россия картинасының уртача бюджеты 116,2 млн сум тәшкил иткән, ә 2019 елда инде 175,9 млн сумга җиткән.

– Татарстанның кино продукциясе ярдәмгә мохтаҗ. Ашыгыч рәвештә әчке кинопрокатны үстерергә кирәк, үзебезнең картиналарны таныту һәм тарату инициативаларын финанслау зарур. Татарстан фильмының уртача бюджетын менә болай исәпләргә мөмкин: барлык тамашачы кәнәфиләрен сеанслар санына тапкырларга һәм урталай бүләргә, – ди Альбина Нәфыйгова. – Әйе, әлегә кинематограф тамашачы күрергә теләгән киноны төшерергә омтыла. Әмма тамашачы кино төшерүче каршында бурычлы түгел. Аның белән эшләргә кирәк, төрле кино карарга өйрәтергә кирәк.

– Хәзерге вакытта без Үзбәкстан белән берлектә татар язучысы Зифа Кадыйрова әсәре буенча төшерелгән «Сөмбел» картинасына прокат таныклыгы алу белән мәшгуль. Төбәкләрдә төшерелгән барлык фильмнар кебек үк, «Сөмбел» дә республикада күрсәтеләчәк (бездә хәзерге вакытта 100ләп күрсәтү ноктасы һәм 29 күчмә кинокомплекс бар). Билет бәясе 100 сум булачак. Бүген тамашачы, кинога барыргамы яисә фильм-сериалларны онлайн карагрыгамы дигәндә, икенчесенә өстенлек бирә. «Әпипә»не күрсәткәндә шуны аңладык: концерт өчен 500–1000 сум чыгарып салучы тамашачы шул ук йолдыз катнашындагы фильмны карар өчен 250 сум түләргә әзер түгел, – ди Миләүшә Айтуганова. – Федераль кинопрокат челтәренә әләгү өчен бик нык тырышырга кирәк. Мин монда бары бер генә чишелеш күрәм – Россия Мәдәният министрлыгы югарылыгында төбәк киноларын төбәкләрдә прокатка чыгару өчен квота булдыру турында карар кабул итәлергә тиеш. Милли фильмнар кинопрокатның һичьюгы 5 процентын булса да тәшкил итәргә тиеш. Безнең фильмнарның аудиториясен киңәйтүнең тагын бер ысулы – телевидение белән хезмәттәшлек. Берьюлы тулы метрга да, сериал форматына да заявка бирү, шул исәптән онлайн-платформаларга урнаштыру өчен дә файдалы булачак.

СЮЖЕТ БОРЫЛЫШЫ

Кино белгече Кирилл Разлогов әйтүенчә, тамашачы да, режиссёр да күрергә хыялланган яхшы фильм булдыру өчен еллар дәвамында иҗат материалы тупларга кирәк – якутлар үрнәгендә. Сүз уңаеннан, бу халык

2
«Пувырга» фильмын төшергәндә (реж. Влад Петров, быел экраннарга чыгар дип көтелә). Максим Толчинский фотосы.

3
«Әпипә» фильмыннан (реж. Илшат Рәхимбай, 2020 ел).

үз киносын яратып карый һәм шул рәвешле аны үстерергә ярдәм итә.

Татарстан киноиндустриясе вәкилләре бер фикердә: бүген һәм якын киләчәктә үз кинобызны җитештерү – хәйрия кылу белән бер. Шулай булса да, бу вазгыятьтә нәрсәне һәм кай якка үзгәртергә мөмкин булуын төгәл шәрехли алар.

– Республика кинематографында нәрсәне, ничек һәм ни өчен үстерергә кирәклеген билгеләгән дәүләт программасы булдыру зарур. Моннан тыш, объектив карарлар кабул итәр өчен, федераль белгечләр катнашында комиссия оештыру кирәк, – ди Илдар Ягъфәров. – Бу эшне талантлы кешеләр башкарырга тиеш. Бөтен дөньяда талантлар акча ясый, ә бездә үзеңне, талантыңны күрсәтү бик авыр.

– Татарлардан башка берәү дә татар киносын төшермәс. Тотылган чыгымнарны акласын өчен, сыйфатның югары булуы мөһим. Сыйфат – күләмле инвестицияләр дигән сүз, дәүләт инвестицияләре турында сүз бара, чөнки бүген картина төшерү өчен инвестор табу бөтенләй мөмкин түгел диярлек, – ди «Кинофест» ҖЧҖ җитәкчесе, продюсер (шул исәптән «Бибинур»ның да продюсеры) Светлана Бохараева. Өлкәне үстерү инструментларыннан берсе буларак, ул кино җитештерү буенча барлык хезмәтләрне дә башкара торган дәүләт кинокомпаниясе оештырырга тәкъдим итә. Дәүләт финанславы аерым командаларга да, кинокомпаниянең үзенә дә сыйфатлы продукт җитештерергә мөмкинлек бирәчәк, шул рәвешле чыгымнар үз-үзен аклаячак.

– Әйе, ярдәм кирәк, әмма ул монополияле булмасын, монополия теләсә нинди өлкәне тиз арада үтерә ала, – дип саный Алексей Барыкин. – Бу башка проектларга юлны ябачак, һәм кадрлар элеккечә Мәскәүгә агылачак.

Альбина Нәфыйгова фикеренчә, төбәктә проектларда мәшгульлекне булдыруны кинокомиссияләр һәм алар гамәлгә ашырган рибейтлар системасы ярдәмендә дә эшләргә мөмкин. Рибейт дип төбәк территориясендә кино җитештерүгә тотылган чыгымнарның бер өлешен шул төбәк бюджетыннан кайтару күренешен атыйлар (Россиядә 15тән 30%ка кадәр сумма). Мондый механизм Приморье краенда, Калининград, Ульяновск, Новгород, Вологда өлкәләрендә эшләп килә. Рибейт системасы эшли башлаганнан бирле федераль компанияләрдән кино җитештерүгә гаризалар кайбер төбәкләрдә бермәбер арткан.

Миләүшә Айтуганова бу мәсьәләдә кластерлы якын килүне максатка ярашлы дип саный – тулы цикллы киноҗитештерү булдыру, бәлки хосусый-дәүләт партнерлыгы инструментларын да куллану мәслихәттер. Төп басым белем бирүгә юнәлдерелергә тиеш – сыйфатлы белем алган техник белгечләр республикага кино төшерү чыгымнарын сизелерлек киметергә мөмкинлек бирәчәк. Бу максаттан, «Татаркино» директоры фикеренчә, республикада эшләп килгән училище базаларында урта махсус белем бирүне үстерергә кирәк – моны Казанда, Чаллыда, Алабугада, Лениногорскида эшләргә мөмкин.

«БҮГЕН ТАМАШАЧЫ, КИНОГА БАРЫРГАМЫ ЯИСӘ ФИЛЬМ-СЕРИАЛЛАРНЫ ОНЛАЙН КАРАРГАМЫ ДИГӘНДӘ, ИКЕНЧЕСЕНӘ ӨСТЕНЛЕК БИРӘ. «ӘПИПӘ»НЕ КҮРСӘТКӘНДӘ ШУНЫ АҢЛАДЫК: КОНЦЕРТ ӨЧЕН 500–1000 СУМ ЧЫГАРЫП САЛУЧЫ ТАМАШАЧЫ ШУЛ УК ЙОЛДЫЗ КАТНАШЫНДАГЫ ФИЛЬМНЫ КАРАР ӨЧЕН 250 СУМ ТҮЛӘРГӘ ӘЗЕР ТҮГЕЛ».

ТИТРЛАРДАН СОҢ

Татарстан кинематографындагы вазгыятьне республика җитәкчеләре дә күзәтә.

– Кино төшерүгә субсидияләр бирерлек бердәм механизмның булмавы безнең кино индустриясе үсешенә аяк чалган системалы проблемаларның бары бер өлеше генә. Күптән түгел Татарстан кинематографчылар берлеге әгъзалары белән очрашу вакытында без ике тема буенча фикер алыштык – кинопрокатка чыгаручылар белән элемтәләр булдыру һәм Россия Кино фонды белән очрашу оештыру. Ул безнең киноиндустрия вәкилләренә Фонд ярдәмендә инвестицияләр җәлеп итү механизмын аңлау өчен кирәк, – дип хәбәр итте «Татарстан»га Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова. – Моннан тыш, апрель башында ММЧ һәм ТВ арасында элемтәләр турында сөйләшү өчен кино җитештерүчеләр белән очрашырга җыенабыз, монда безнең телекомпанияләр, башлыча ТНВ компаниясе, кызыксыну белдерә. Документаль кино мәсьәләсе сөйләшүнең аерым бер өлкәсе булып тора. Коммерция, табыш ягыннан бу өлкә кызыктырмый, әмма бу безнең дәвернең елъязмасы бит. Бәлки, аерым проектларны гына сайлап алып үстерү җитеп бетмидер. Документаль киноның киләчәге мөһим – аны киштәдә яткыру дөрес түгел.

Ирада Әюпова әйтүенчә, Татарстан Хөкүмәтендә 2020–2025 елларга һәм 2030 елга кадәр Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясе проекты каралачак. Бәлки нәкъ шул проектта безнең киноның киләчәге нинди булыр – драма булырмы ул, героик эпосмы, кыска метрлы фильммы яки сериалмы, бер карарлык фильммы яки кинофондның алтын җәүһәреме, дигән сорауга җавап табылыр.

«Кире» фильмын төшергәндә
(реж. Илсөяр Дамаскин, Рөстәм Рәшитов, 2019 ел).

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ СОРАУЛАРЫ

ӘГӘР МӨМКИНЛЕК БИРЕЛСӘ, СЕЗ ТАТАРСТАНДА НӘРСӘ ТУРЫНДА КИНО ТӨШЕРЕР ИДЕГЕЗ?

АЛЕКСЕЙ БАРЫКИН:

– Милли мәдәният һәм милләтара мөнәсәбәтләр, мәхәббәт һәм батырлык, тарихи каһарманнар турында.

ИЛДАР ЯГЪФӘРОВ:

– «Ни өчен бездә кино юк?» – шундыйны төшерер идем мин.

НИНДИ ТАТАРСТАН КИНОСЫН КАРАРГА ТЕЛӘР ИДЕГЕЗ?

ИЛДАР ЯГЪФӘРОВ:

– Башкортостанда документаль кинематограф Малик Якшимбетовның «Врата свободы» («Ирек капкалары») фильмыннан башланды. Бүгенге Башкортостан нәрсә ул, дигән сорау куюдан. 31 ел суверен республика булу дәверендә безнең нинләргә ирешүебез турында документаль фильмны карарга кызык булыр иде ул. Телне югалту, авылларадагы вазгыять, татар теле укытучыларының хәле турында. Чүп яндыру заводы хакында. Иҗат гадел, туры сүзле булырга тиеш.

АЛЬБИНА НӘФЫЙГОВА:

– Әдәби чыганакларга нигезләнгән заманча адаптацияләр күбрәк эшләнсә, әйбәт булыр иде.

ӘДИЛӘ ХӘЙБУЛЛИНА:

– «Пувырга» картинасының чыгуын бик көтәм. Мине авторның теле, атмосфера мөкиббән итте. Бу тарихта шигърият бар. Авторлык киносы жанрына караган бик җитди эш. Нәтиҗәсен күрәсе килә, нинди булыр икән.

ИЛШАТ РӘХИМБАЙ:

– Һәр буынның үз мәсьәләләре. Миңа урта яшь кризисы, кешеләрнең төбәкләрдән читкә таралуы темалары кызыклы.

ИРАДА ӘЮПОВА:

– Шәхсән үзем бу киноның тамашачыларга кызыклы булуын теләр идем, әмма тамашачыга яраклашам дип, үз йөзен югалтмасын ул. Артхаус ошый, тирән мәгънәле. Заманча даирәдә артхаусны таныту – кинематограф алдында торган бурычларның берсе.

Язманың видеовариантлары да бар

Автор: Руфия Фазылова

ГАЛИҖӘНАП МИЧ КОДРӘТЕ

«Татарстан» журналы халкыбызның ата-бабадан килгән затлы һөнәрләрен, шөгыльләрен барлауны дәвам итә. Яшь буын да колагына киртләп куйсын. Оныткан булсак, яңартыйк!
Бу юлы олы мичне ягу серләренә төшендек. Шул ук вакытта ни өчен камыр ризыкларының нәкъ менә ялкында тәмлерәк булуын да ачыкладык.

ҺӨНӘРЛЕ ХУР БУЛМАС

КОРЫ УТЫН КИРӘК

Мич! Ничә гасырлар буена ул безнең халыкны ризыклы иткән, тәнен генә түгел, җанын да җылыткан. Биредә берьюлы ике ризык әзерләгәннәр – казанда аш кайнаса, мич эчендә ипи пешкән. Кичләрен исә мич башында әби кеше, оныкларын җыеп, экият сөйләгән. Мич башы бала-чаганың, әби-бабайның иң яраткан урыннарыннан берсе саналган.

Йортларга газ кергәч, мичләргә ихтыяҗ югалган. Бу аңлашыла да, җәй буе утын әзерлисе, иртән торып мичкә ягасы юк. Газыңны ачасың да, аш та пешә, өй дә җылына. Тик... газны ничек кенә мактасак та, ул мичне алыштыра алмый...

Кайбыч районының Кошман авылында яшәүче Мотыйгуллиннар мичләрен сүтмәгән. Алай гына да түгел, йортларында ике мич.

– Кыш буе ике мичкә дә утын яктык, – диде хуҗабикә Нурания апа.

Әлбәттә, Мотыйгуллиннар йортына газ кергән. Ә мичкә ягуның сәбәпләре бар икән. Хуҗабикә болай дип аңлатты:

– Беренчедән, быел кыш салкын булды, өй тизрәк җылынсын, дидек. Икенчедән, мичкә яккач, өйгә нур керә. Безнең караватлар мич буенда. Кичке якка мичне ягасың да, рәхәтләнеп, изрәп йоклыйсың. Мичтән төн буена җитәрлек җылы чыга.

Нурания апа шулай дип кечкенә мич турында аңлатты, анысы йокы бүлмәсендә тора. Ә икенче якта олы мич киерелеп утыра. Менә монысы инде җылылык бирү өчен генә түгел, ә камыр ризыклары пешерү өчен дә икән.

– Бу мичкә утыз елдан артык, – диде хуҗабикә. – Әйтмәгәнем булсын, бер дигән тарта. Ким дигәндә, атнасына бер ризык пешерәм инде: юка, кабартма, өчпочмак, пироглар. Балалар киләсе булса да, камыр куям, Сәлимулла да «заказ»ны биреп кенә тора.

Олы мичне карап әйләндек. Зур. Элек дүртпочмаклы өйләрнең яртысын алып торган инде бу, дибез. Мич башын да карадык. Рәхәтләнеп бер кеше йокларлык урын. Бер мәл күз алдына килеп басты: мич башында, зур ястык мендәрдә әби ята. Аяклары чыгып тормасын дип, ул аларны бөкләп куйган. Артык эсселәгәч, әби акрын гына урыныннан торып, мич башыннан төшеп китә...

КОШМАН КИРПЕЧЕ

Без килгәнче мичкә утын тутырылган иде. Баксаң, элек тә шулай иткәннәр. Беренчедән, утын кибеп, җылынып торган. Икенчедән, уңайлы булган – иртән торуга, мичкә ягып җибәргәннәр.

– Мичкә ягу өчен туйра (имән), юкә агачлары яхшы, – дип аңлатты хуҗабикә. – Туйра катырак, җылысы әйбәт чыга. Ә юкә ялкында камыр пешергәндә кирәк, ялкыны яхшы була.

Ул да түгел хуҗа кеше – Сәлимулла абый юкә чыраларын алып керде. Мичкә ягарга да, камыр пешергәндә дә кирәк булачак.

– Мондый эшләрдә хатын-кызларга булышырга кирәк, – дип елмайды ул.

Тик мичне Нурания апа элдерде. Әлбәттә, башта моржаларны ачты. Мичебез бик тиз янып китте, чөнки чыра да, утын да коры иде.

Фото: Лилиана Вәлитова

– Юкә чырасы мич элдерергә бик яхшы, – ди Нурания апа.

Мич янган арада хуҗабикә әче коймак камыры ясады.

– Сезгә пешереп күрсәтәсем килә, – диде ул.

Югыйсә, өстәл камыр ризыклары белән тулган иде – юка, кабартма, сумса, бәлеш, бәрәңге кабартмасы... Шул рәвешле хуҗабикә мичтә әллә ничә төрле ризык пешереп була икәнен раслады.

– Мич кабартмасы диләр бездә, – диде Нурания апа. – Аннан башка бер Коръән ашы да узмый. Әле дә ашларга шундый кабартма пешерәләр.

– Кошманда мичле йортлар шулай күпме? – дим.

– Күп түгел, санаулы гына. Мичле кешеләргә заказ да бирәләр. Бер дә булмаса, газ мичендә пешерәләр инде.

Мич алдына җыелдык. Утын дөрләп яна. Мич авызына күз салдым: кирпечләре тигез сакланган, ватылмаган. Югыйсә, өч дистә елдан артык вакыт узган бит.

– Монда Кошманда сугылган кирпечләр дә бар, – ди Сәлимулла Мотыйгуллин. – Безнең Кошманда ике йортның берсендә кирпеч сукканнар. Әле безгә дә эләкте ул. Олы абыем Фәһим белән кырдан кызыл балчык казып, аны кул арбасына төяп кайтып, ике ел кирпеч суктык. Мең кирпечкә бер кубометр утын кирәк. Аны кичтән яга башлыйлар, таң атканчы яндыралар. Шуннан соң кирпеч бер атна кибеп тора. Һәм ул эшкә яраклыга әйләнә. Кошман кирпече яхшы саналды, мич чыгаручылар аеруча ярата иде, чөнки аны теләсә кайсы җиреннән, теләсә кайсы зурлыкта ватып була. Заводта эшләнгән кирпеч исә ватылмый, ярыла гына.

БӘХЕТЛЕ КИЛЕН

Уңган килен ул таба, бәхетле хатын кыз таба, ди халык. Нурания Мотыйгуллина тормыш иптәше Сәлимулла абый белән өч кыз тәрбияләп үстергән. Кызлар инде кияүдә, үзләре дә ана булган. Әти-әниләренә сигез оныкбүләк иткәннәр. Мич янып, күмер төшкәнче, хуҗабикә белән гаилә, тормыш кыйммәтләре турында сөйләштек.

Нурания апа утыз җиде ел кайнана белән яшәгән килен.

– Әле кайнанамның апасы да бездә яшәде, – ди тәҗрибәле килен. – Мин аларга бик рәхмәтле. Кайнанамны искә алмаган бер көнебез дә юк. Кызлар әнкәй тәрбиясендә үскәнгә, шундый акыллы булгандыр, дип сөйләшәбез Сәлимулла белән. Балаларны үстерергә бик булышты. Кырыслык бар иде аңарда, тик һәр сүзе урынлы, мәгънәле иде. Эшкә дә, тормышка да өйрәтте. Урыны оҗмахта булсын...

Нурания апа – утыз җиде ел буе Кошман урта мәктәбендә татар теле, әдәбияты укыткан мөгаллимә. Шул дәвер эчендә күп кенә мактаулы исемнәргә лаек булган. Сөйләм теле матур. Шуңадыр да аның белән эшләргә бик җайлы булды. Мич турында да шактый кызык мәгълүматлар җиткерде:

– Әдәби әсәрләрдә мич турында бик күп сөйләнә. Бу аңлашыла да, ул бит яшәү чыганагы булган. Мәкаль, әйтемнәр дә күп. «Уңмаган хатынның мич алды чүп булыр», дигән безнең халык. Тагын бер ырым бар – мич башында яту ялкаулык билгесе саналган. Ә менә әби-бабайларга бу яраган, чөнки алар сөякләрен җылыткан. Бала-чагага да сүз әйтмәгәннәр. Ир-атлар, гомумән, мич башына бик менәргә тырышмаган.

Якынча ярты сәгать дигәндә утын янып бетте, күмер төште.

– Коймак кына пешерәсе булганга, утынны ярты кочак кына яктык, – дип аңлатты хуҗабикә.

– Ә өйне җылыту өчен күпме утын якканнар? – дим.

– Иртән бер кочак, кичен бер кочак. Кирпечләр тиз суынмый, аның җылысы көне буена җиткән.

Нурания апа күмерне кырыйгарак этте – табага урын әзерләде. Һәм табаны мичкә куйды. (Коймак майга салгач «чыж» итәргә тиеш.) Шуннан табаны майлап, кашык белән камырны салды. Һәм янә мичкә куйды. Өйгә хуш ис таралды, хәер, ул тышка да чыккан иде... Коймаклар күзгә күренеп кабарды. Әйләндерәсе дә юк, өч минут көтәсең дә, телеңне йотмалы ризык әзер.

...Миңа калса, мичнең күзгә күренми торган бер тылсымы бар. Кешелек дөньясы ни генә уйлап тапмады, ә мичне алмаштырырдай (сүз камыр пешерү турында бара) әйбер юк. Әйе, газ, электр мичләре бар. Тик ул бүтән. Чуенга куеп, мичтә пешерелгән аш белән кәстрүлдә, газ өстендә әзерләгән ашны чагыштыра алмыйбыз. Камыр ашларын да шулай. Мич тере организм кебек, аның кодрәте зур.

ЭШ БАРЫШЫ:

- мичкә утын тутырабыз;
- чыраны телəбез;
- морҗаны ачабыз;
- чырага ут төртәбез;
- утын янгач, кисәү (кисәү агачы) белән аны тигезләп җибәрәбез;
- барлыкка килгән күмерне кисәү (кисәү агачы) белән этәбез.

PRESSA

БӘХЕТ – ХЕЗМӘТТӘ

Без матди хәле һәм мөмкинлекләре төрле булган гаиләләрдә дөньяга киләбез, әмма барыбызның да хыялларыбыз бердәй – бәхетле булу. Тик бәхеткә илтә торган юлда сынаулар берәүне дә читләтеп үтми – тормышның кануны шундый. Шуңа күрә, теләсәк тә, теләмәсәк тә, көчле, нык булырга туры килә. Намус белән хезмәт куюы һәм замана яшьләренең төшенә кермәслек күп итеп эшли белүе белән Бөгелмәдә хөрмәт һәм абруй казанган мөлаем ханым – Асия Гомәр кызы ШАҺАБЕТДИНОВАга югарыда әйтелгән сүзләр бик яхшы билгеле.

Күп балалы гаиләдә, өстәвенә, балаларның иң олысы булып дөньяга аваз сала ул. Гаяз, Сания, Галим, Дания, Нияз, Рузалия, Ильяс исемле эне-сеңелләре өчен Асия төп остаз, төп тәрбияче була. Әти-әни көн буе эштә, хәер, совет чорында башкача булмый да иде, һәр кеше Ватанга мөмкин кадәр күбрәк файда китерергә тырышты. Балалар да ул вакытта мөстәкыйльрәк иде. Балаларның иң өлкәне буларак, Асиягә бик иртә өлгерергә, ныгырга туры килә. Барысына да күз-колак булу гына түгел, әле ашарга да пешерергә, эни кушып киткәннәрне дә эшләргә, дәресләр дә әзерләргә кирәк. Барысына да өлгереп, көтелмәгән хәлләрдә тиз арада карар кабул итә белү сәләте, еллар узгач, Асия ханыма чит җирләрдә өч ул тәрбияләп үстергән чакта бик ярап куя.

Асия Шаһабетдинованың әтисе – Бөек Ватан сугышы ветераны Гомәр Нәгыйм улы Ногманов чолганыштагы Ленинградны саклап сугыша һәм әлеге шәһәрнең блокадасын өзүдә катнаша, Кенигсбергны да штурмлый, шунда ул 1946 ел азагына кадәр хезмәт итә. Гомәр абый берничә тапкыр яралана һәм контузия ала, әмма «Ватан өчен!» дип алга барганда, үлем белән күзгә-күз очрашудан һичкайчан курыкмый.

Аның фидакяр кыюлыгын күрми калмыйлар – ул орден-медальләр белән бүләкләнә. Гомәр Ногманов сугыш турында сөйләргә бөтенләй яратмый – сугышчан дусларны яу кырларында югалтуыңны, теләсә кайсы мизгелдә үзеңнең дә һәлак була алуыңны искә төшерү бик авыр бит. Ә Асия апаның әнисе Нәкыя Ногманова – тыл хезмәтчәне, озак еллар совхозда умартачы булып эшли. Ир белән хатын бергә 66 ел тату гомер кичерә. Сүз уңаеннан, 1950 нче елларда күп балалы гаиләләр әллә ни сирәк күренеш түгел. Ни гаҗәп, күпләр туйганчы ашый да алмаган катлаулы вакытларда, бүгенге көннән аермалы буларак, күп бала табудан һичкем курыкмаган.

Фотолар Асия Шаһабетдинова архивыннан

Гаиләләр тату, нык була, өлкәнрәкләре кечеләргә булыша, бер-береңә хөрмәт һәм үзара ярдәмләшү һәрвакыт беренче планда тора. Моның никадәр мөһим икәнен искә төшерү урынсыз, чөнки без барыбыз да үз язмышыбызда ата-аналар калдырган генетик «йөк»не тартып барабыз. Ул кыйммәтле икән, димәк, кешене лаеклы киләчәк көтә. Шәһабетдиновлар гаиләсе дә – моның иң яхшы дәлиле.

Асия ханым кечкенәдән эне-сеңелләре турында кайгыртырга күнеккән, ул сигез баланы ашатып-эчертеп тәрбияләп үстерүнең һич тә җиңел түгеллеген аңлый. Шуңа күрә мөмкин кадәр тизрәк берәр һөнәр үзләштереп, эшли башлау турында хыяллана.

Өстәвенә, кая укырга барырга дигән сорау да тумый. Әтисе Плодопитомник бистәсендә агроном булып эшли башлагач, Асияне дә бу һөнәр үзенә тарта. Сүзнең нәрсә турында барганын аңлатып китик. 1930 нчы елларда Татарстанның Урман утырту идарәсе карамагында урман-бакча питомнигы оештырыла. 1940 елда ул агроурман питомнигы, соңрак агроурман-мелиорация питомнигы дип үзгәртелә. 1944 елда оешма мелиорация эшләре белән шөгыльләнүдән туктый һәм Бөгелмә урман питомнигына әверелә. Тиздән оешма чираттагы тапкыр үзгәртеп корыла – Татар бакчачылык һәм питомник хуҗалыклары идарәсенең Бөгелмә җиләк-җимеш питомнигы барлыкка килә. 1970 нче еллар башында аның базасында «Урал» җиләк-җимеш совхозы оеша. Шушы совхозда Асия ханымның ире Миңнефәрит башта механик, аннан соң баш инженер була. Асия ханымның әтисе – Уфа авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган белгеч тә – нәкъ менә шушында баш агроном булып эшли. Үз эшенең остасы булудан тыш, ул авырлыкларны җиңеп алга барудагы ныклыгы һәм кешелеклелеге белән аерылып тора. Бу сыйфатлар әтисеннән Асия ханымга да күчә. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк, чөнки һәр бала – ата-анасының чагылышы, дәвамы ул.

Ә тормыш юлында шундый авырлыклар очрый ки, дөресен әйткәндә, һәркем аларны җиңә дә алмас иде. Сугыштан соң совхоз рәисе итеп билгеләнгән Гомәр аганың гомерендәге бер фаҗигале мизгел игътибарга лаек. 1952–1953 елларның көзе мул уңыш алып килә. Игеннәр тулысынча диярлек җыеп алынып, ындыр табакларына китерелә. Ул вакытта авыл өчен «акча» һәм «хезмәт хакы» дигән сүзләр ят, һәр хисап «хезмәт көне» саны белән алып барыла, чынлыкта һичкемгә берни дә түләнми. Сугыштан соңгы чор кануннары кушканча, рәис кеше, ашлыкны дәүләткә тапшырганнан соң гына, калганын халыкка өләшә ала, шуңа күрә икмәкне совхоз складларыннан районга илтергә кирәк була. Ашлык ташырлык техника МТСта гына, Гомәр ага совхозының чираты тиз генә килеп җитәрлек түгел. Хәтта бер башак өчен дә төрмә янавына карамастан, авыр шартларда калган ач халык түзеп тора алмый – урлаша, канәгатьсезлеген дә яшерми. Асия ханымның әтисе, хәлләрнең мондый юнәлеш алуын күреп, уйлап та тормыйча, хезмәт көннәре өчен тир түгеп эшләп алган ашлыкны бүлеп бирә. Нәтиҗәдә, бер тәүлек тә үтми, НКВДның «козгын» машинасы аны районга алып китә, Гомәр агага анда, суд көтеп, билдән суда килеш подвалда утырырга туры килә. Аның язмышы инде хәл ителгән санала, чөнки ул автомат рәвештә халык дошманы исәпләнә башлый, бу исә лагерьда башың черетелә яки инде атып үтерү көтә дигән сүз. Әмма дөньяда игелекле кешеләр очрап тора бит. Гомәр Нәгыйм улы үзе дә еш кына: «Милләтнең начары юк, кешенең начары бар», – дип әйтә торган була. Ул вакытта мәгълүм «өчлек»ләр хөкем итә, ә Асиянең әтисен район комитетының беренче секретаре – чуваш кешесе коткарып кала, хөкем карары чыгарганда, ул ике тавышка ия була.

Еллар уза. Сигез баласы русча белем алсын өчен, 1963 елда Гомәр ага Карамыштан Бөгелмә районының Плодопитомник авылына күчәргә карар кыла. Гаилә башлыгы монда агроном булып урнаша. Ә 15 яшьлек Асия Бөгелмәнең 66 нчы урта мәктәбендәге сигезенче сыйныф укучысына әйләнә. Рус телен белмичә, өлкән сыйныфларга яңа кеше булып килү һай кыен була аңа. Үзенең үҗәтлеге һәм максатчанлыгы аркасында Асия инде бер елдан русча иркен сөйләшә башлый һәм яхшы укучылар рәтенә керә. Шул ук елларда кыз үсентеләр утыртырга, аларны ялгарга, тәрбияләп үстерергә өйрәнә. Шуңа күрә Кама Тамагы районының Тәмте авылындагы бакчачылык училищесына районнан юллама белән укырга җибәрелүе һич тә гаҗәпләндерми. Соңрак ул, Уфа авыл хуҗалыгы институтының читтән торып уку бүлеген тәмамлап, «агроном» белгечлеге ала.

Асия Шәһабетдинова питомникта бик яшьли эшли башлый, әмма ул баштан ук көн дими, төн дими, хезмәткә чума, чөнки җиләк-җимеш, җиләкләр үстерү процессы күңеленә бик хуш килә. Хәер, Асия ханымның яраткан питомнигына күпме хезмәт, күпме көч, күпме тырышлык, тәҗрибә керткәнен сүз белән генә әйтеп бетереп буламы?!

Хуҗалыкның территориясе бик зур була, һәм эш тоткарлыксыз, көйле барсын өчен, шәхси тормыш һәм планнар турында онытырга туры килә. Үсентеләрне сакларга, эшкәртергә, тукландырырга, ботакларын кисәргә кирәк. Ә җир көчен аңлап, тоеп алсаң, анда үзең өчен яңа мөмкинлекләр ача башлыйсың. Җир-ананың тырышлыкларыңны җавапсыз калдырмавын күрсәң, ул чакта җаваплылык та, үз-үзеңә карата таләпчәнлек тә берничә тапкыр арта.

Кияүгә чыгып, ерак Үзбәкстандагы искиткеч матур яшел кала – Шәһрисабзга китеп баргач та, Асия ханым яраткан питомнигын оныта алмый. Иң авыр мизгелләрдә ул һәрвакыт Бөгелмәсен, андагы йөрәккә якын урыннарның матурлыгын, кадерле әти-әнисен искә ала, үсентеләре өчен борчыла. Шәһрисабзда аның туганнары булмый диярлек, ә бер-бер артлы өч улы туган яшь хатынга ярдәмче, киңәшче бик кирәк. Акча җитми, балаларны нәни сабый килеш яслегә бирергә туры килә. Ул вакытта декрет ялы да бик кыска – бала тапканнан соң нибары ике ай гына. Ире Миңнефәрит Миңназетдин улы экскаваторчы булып эшли. Гаиләсен тәэмин итәргә бик тырыша да, тик ул вакытта икесе дә бик яшь һәм тәҗрибәсез бит. Асия инкубатор станциясендә дә, мамык заводында да эшли. Аңа күп яңа нәрсәгә өйрәнергә туры килә, әмма уңган ханым һәркайда булдыра. Сүз уңаеннан, башка хатын-кызлардан аермалы буларак, ул бар эшне дә ир-ат җилкәсенә йөкләргә ярамый дигән фикердә, чөнки ир затлары да ялга, күңел җылысына, кайгыртуга мохтаҗ. Ике арада кабынып килгән кытыршылыкларны шомарта, үз сүзләренең һәм гамәлләренең нәтиҗәләре турында уйлый белү ир белән хатын өчен бик мөһим бит.

Икенче улы Салаватның ахырда чукраклыкка китергән авыруы Асия ханым өчен зур сынау була. Баласын терелтергә теләп, яшь әни кая гына мөрәҗәгать итми – Ленинградка кадәр барып җитә. Иң яхшы докторлардан ярдәм өмет итә, тик, ни кызганыч, ул вакытта медицина әле хәзерге кебек алга китмәгән. Нәтиҗә нинди генә булмасын, ана мәхәббәте җиңә – Салаватның язмышы бик уңышлы дәвам итә: ул белем ала, сирәк белгечлек – агачтан

кыйммәтле җиһазлар ясау остасы һөнәрен үзләштерә, алтын куллы ир өйдә барысын да үзе ясый. Гаиләсе, балалары – күз генә тимәсен. Әнә шулай чиксез ана мәхәббәте, әлбәттә, аңа булыша, һәм бу таяныч һәрвакыт саклана…

1978 елда ирле-хатынлы Шаһабетдиновлар балалары белән туган якка – Бөгелмәгә кайткач, Асия ханым яңадан бик теләп питомнигындагы эшенә керешә. Башта баш агроном ярдәмчесе, аннары совхоз бүлекчәсе идарәчесе вазыйфасын башкара. Турысын әйткәндә, агроном сыйфатында җир белән эш итү дәверендә ул гектарның уңдырышлылык көчен мөмкин кадәр арттырырга тырыша, ул вакыттагы алдынгы технологияләрне кулланышка кертә. Алма, чия, кура җиләге дип, Бөгелмәгә бөтен Татарстаннан киләләр. Үсентеләр көчле, сәламәт була, чөнки аларны технологияне төгәл саклап үстерәләр. Питомникның мәйдан ягыннан шундый зурлыгы үзеннән-үзе сорау тудыра: бу нәфис ханым монда эшләргә дә, үз хуҗалыгын карарга да, өч бала тәрбияләргә дә ничек өлгерә алды икән? Шәхси хуҗалыкта да эш бихисап, монда төрле елларда ике-өч сыер, бозаулар, тавык-чебеш була – барысын да карарга, ашатырга кирәк. Әлбәттә, питомникта Асия ханымның ярдәмчеләре була, әмма ул башкалар белән бергә печәнен дә чаба, үсемлекләрне, җирне эшкәртә, үсентеләрне ялгый. Питомникта кайбер эшләрне, «соңыннан эшләрмен әле» дип, кичектереп булмый. Мондагы тормыш теге яки бу операцияләрнең әзлеклелегенә, үсемлекләргә һәм агачларга нәкъ менә шушы мизгелдә ни таләп ителгәнлегенә бәйләп алып барыла. Шуңа күрә Асия ханым ул вакытта үзенә булышкан һәркемгә, шул исәптән Бөгелмә медучилищесы, педучилищесы һәм 3 нче мәктәп укучыларына да чиксез рәхмәтле.

Питомниктагы көндәлек хезмәтеннән тыш, Асия Шаһабетдинова 1980 елдан җирле совет депутаты, аннары өч чакырылыш район депутаты (җир комитетында) була. 1980 нче елларның дәүләт өчен нинди мөһим чор икәнен, илнең киләчәге турында кайнар бәхәсләр кайнаганын хәтерлик. Депутат җыелышлары, шул исәптән район дәрәҗәсендәге утырышлар да берничә сәгатькә сузылган чаклар ул. Менә шунда без үз ватанының язмышы, киләчәге өчен Асия ханымның никадәр күңел биреп тырышканлыгына төшенербез. Эшләре баштан ашкан чакта, өч бала тәрбияләгән вакытта аңа шундый өстәмә җәмгать йөген тарту кирәк булганмы дип уйлыйсың. Әмма аның эшчән, ару-талу һәм тынгы белмәс холкы тирәюньдә барган хәлләргә битараф калырга юл куймый…

Илдә болгавыр чорлар башланып, колхоз-совхозлар бер-бер артлы бөлгенлеккә төшкәндә, авыл кешеләре дә, шәһәр халкы да иртәгесе көнгә ышанычны югалтканда, питомникны саклап калу өчен, Асия ханым кулдан килгәннең барысын да эшли. Ул хәтта «Мирас» дип исемләнгән крестьян-фермер хуҗалыгы да оештыра, анысы ун елдан артык эшли. Асылда ул катлаулы агротехнологияне үстерү белән шөгыльләнә, сөрүлек җирләренең бакчалар белән чагыштырганда бишкә бер коэффициенты белән исәпләнүе һич тә юкка түгел. Аңлашыла ки, дәүләт ярдәменнән башка питомник ябылуга дучар ителә. Асия ханым бай тарихлы предприятиене саклап кала алмавына бүген дә борчыла.

1990 нчы елларда ул шәхси тормышында фаҗига кичерә – ире Миңнефәрит 52 яшендә яман шеш авыруыннан вафат була. Асия ханымга бу вакытта нибары 45 яшь була. Дүрт елдан соң тагын бер фаҗига көтә – гаиләдәге иң кадерле кече энесе – 33 яшьлек Ильяс бандитлар кулыннан үлә. Ул вакытта Асия ханымга авырлыкларны җиңәргә, кайгыларга түзәргә нәрсә булышкан соң? Бу сорауга җавап бик гади – балалары. Сөекле уллары гел янәшәдә була, һәрвакыт ярдәм кулы суза. Олы улы Ринат – эшмәкәр, быел 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аның матур гаиләсендә ике ул һәм ике кыз үсә. Икенче улы Салават Бөгелмәдә яши, ике баласы бар. Өченче улы Руслан да ике бала атасы, механик булып эшли.

Асия ханым язмышына барысы өчен дә: сынаулары, шатлык-куанычлары, эш көннәре, бәйрәмнәре өчен рәхмәтле. Тырыш ханым ул-кызларына тормышның иң мөһим принципларын (бу тормышта нәрсәгә дә булса ирешү өчен, эшләргә кирәк, кемдер ярдәм сорый икән, кире кагарга ярамый) сеңдерә алган әби-бабалары, эти-әнисе белән горурлана. Авырлыктан курыкмаган, матди байлыкны беренче урынга куймаган кешеләрдән бүгенге буын үрнәк алырга тиеш. Гомер юлында күп нәрсә үзебездән тора, ата-бабалардан күчкән иң яхшы сыйфатларны үзебездә саклау, үстерү мөһим – Асия Шаһабетдинова бу хакыйкатьне үз язмышы белән раслый. Тирә-ягыбызда шундый игътибарлы, кече күңелле кешеләр күбрәк булган саен, җәмгыятебез дә шулкадәр уңышлырак, бәрәкәтлерәк һәм ныклырак булачак.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

Мәңгелек кыйммәтләр /

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

Бу санда тәкъдим итәбез:

«Камай реакциясе» **КАЙЧАН** ачылган

Иң нык тәнкыйтьләнгән мөфти **КЕМ** булган

Татар ТЮЗы директоры **НӘРСӘЛӘР** укый

Татар Тау Иле **НИЧЕК** яши

ОНЫТЫЛМАС ИСЕМНӘР

«МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТОРМЫШ!»

Фотолар Светлана Камаеваның гаилә архивыннан алынды

Автор: Ландыш Әбүдәрова

1963 елда Варшавада узган бөтендөнья химиклар симпозиумында Англиянең Корольлек җәмгыяте әгъзасы лорд Александр Тодд Казанны химиянең тарихи үзәге дип атый. XIX гасырның 40 нчы елларында Николай Зинин, Александр Бутлеров, Карл Клауслар нигез салган химия мәктәбенең эстафетасын XX гасырда Александр Арбузов һәм аның укучылары Борис Арбузов белән Гыйлем Камай дәвам иттерә. «Химиянең тарихи үзәге», дип Тодд нәкъ менә Камайга әйтә. 2021 елның февралендә беренче татар химия галиме Гыйлем Камайның тууына 120 ел тулды.

ФОРТУНА

«Минем өчен әтием – Гыйлем Камай – иң югары дәрәҗәдәге намуслылык, игелеклелек, шул ук вакытта кыюлык, ныклык һәм максатчанлык үрнәге. Аның бу сыйфатлары һәр адымында сизелеп тора иде. Җиденче дистәмне тутырып килгәндә, шул биеклектән торып, мин аның балачагы турында уйлыйм да, ничек итеп шул чагында ук максатын дөрес билгеләп, үзендә шушы сыйфатларны үстерә алган икән ул, дип таң калам», – дип сөйли Светлана Гыйлем кызы.

Камайларның Тәтеш шәһәрендә Иделнең биек ярында ук урнашкан, тәрәзәсенә кадәр җиргә сеңгән иске өйләренең ишеген кайгы җиле какканда, Гыйлем 8 яшьлек кенә малай була. Ә бит зур баржада йөк төяргә дип, Рыбинскига киткән әтисен зур өметләр баглап көтәләр. Бигрәк тә Гыйльметдин көтә: әтисе Хәйретдин акча эшләп кайтса, малайның укырга акчасы булачак. Әтисе кыш буе шулай дип өметләндерә аны: «Яз җитүгә акча эшлим дә сине укырга бирәм, писарь булырсың», – ди. Ә үзе язгы Идел суына төшеп, бик каты салкын тидереп кайта, һәм шул ук төнне аның гомере өзелә. Мирас итеп, улына йөкче ыргагы белән иске бушлатын калдыра. Васыять итеп әйткән соңгы сүзләре: «Улым, укы. Грамотага өйрән», – була.

«Әтинең үлеме мине аяктан екты. Тирәякта бушлык, суларга һава җитми кебек. Һич кенә дә аңыма барып җитми: нигә үлде ул? Без бит аны шундый ярата идек...» – дип яза Камай балачагы турында. Шулвакыт күрше хатыннарының берсе, малайны кызганып, «Менә, этиең калдырды...» – дип, аңа ак күмәч тоттыра. «Мин шунда ук елаудан туктадым. Без шундый ач идек. Ак күмәчне күрүгә, кайгы да онытылды», – дип сөйли торган була бу хатирәсен Гыйлем балаларына.

– Улым, сиңа 8 яшь инде, – ди аңа беркөнне әнисе Бибиәсма. – Эшкә чыгарга вакыт.

Мәктәп турындагы хыялларын онытырга туры килә, ул көч-хәл белән йөк ташучы извозчик Тупеевка ат карарга яллана. Атларга карата тирән ихтирамы, яратуы әнә шул вакытлардан кала аның. Ике ел узгач, пристаньга йөк ташучы булып төшә. Үзе кебек малайлар белән көнгә ике-өч тиен эшли. Яртысын әнисенә алып кайтып бирсә (бер тиенгә бер савыт он сатып алып булган), калганына Сытин басмаларын ала.

«Камайны хәреф танырга йөкчеләр өйрәткән, диләр, – дип сөйли Светлана ханым. – Алай түгел. Алар бит үзләре дә укый белми. Ул хәрефләрне үтеп баручы кешеләрдән сорый торган була. Әнә шулай үҗәтләнә, кызыксына торгач, ул хәрефләрдән сүз җыярга өйрәнгән. Иң беренче укыган сүзе Идел буйлап барган пароходның исеме була. «Фортуна!» – дип кычкырып җибәрә ул».

Язмышындагы фортунаның исеме Антонина Малыгина була. Сытин басмаларыннан укып ятлаган Пушкин, Лермонтов, Некрасов шигырьләрен йөкчеләргә кычкырып сөйләп торганда, яланаяклы, сәләмә киемле бу малайга игътибар итеп: «Энем, син кайда укыйсың?» – дип сорый. Гыйлемнән алда йөкчеләр җавап бирә: «Аның үз гомерендә әлифба тотып караганы юк». Шуннан инде олы йөрәкле мөгаллимә аны үзенә укырга чакыра. Казанга Татар укытучылар семинариясенә киткәндә, аңа фатихасын һәм Кольцов томлыгын биреп озата. Шулай итеп, яшь Камай, соңгы бер елда күпер төзелешендә эшләп алган 9 сум акчасын тотып, Казанга – гыйлем алырга юлга чыга...

PRESSA

ГЫЙЛЕМ ЭСТӘП, ЕВРОПАГА КАДӘР

Гадәттә, гыйлемгә омтылуның классик үрнәге итеп, Михаил Ломоносовның Архангельск губернасыннан, җәяүләп, Мәскәүгә чыгып китүен искә алалар. Хәзер инде бу мифның нигезендә башкарак фактлар яту, аерым алганда, булачак философ-галимнең, үги әнисе белән низаглардан туеп, өйләндерүләреннән качып китүе билгеле. Үзе ул хәлле крестьян гаиләсеннән була.

Ә менә Гыйлемнең үзе белән алган запаслары Яңа елга кадәр генә җитә. Семинариядә укыганда, башта төшке ашлардан баш тартырга туры килә, аннан соң көнгә бер генә тапкыр ашый башлый. Җылы вакытта Печән базары мәчете янындагы янкормада кунып йөри, аннан соң бер иптәше үзе янына дәшә. Әмма иптәше үлеп китә, һәм фатир хуҗасы Гыйлемне куып чыгара. Ачлыктан хәлсезләнгән 15 яшьлек үсмер математика дәресендә тәмле-тәмле ризыклар турындагы мәсьәләне чишеп утырганда аңын җуеп егыла. Өстәвенә, соңгы вакытта тавык күзе авыруы көчәеп китә... Нәтиҗәдә Камай, укуын ташлап, янә Тәтешкә йөкче камытын кияргә кайтып китәргә мәҗбүр була. Йөкчеләр аны үз уллары кебек якты йөз белән каршы ала. «Алар мине саклыйлар иде. Көчеңне сакла, кирәге чыгар дип, артык авыр күтәрттермәделәр дә», – дип искә ала ул чакларны Камай. Патшаның бәреп төшерелүен дә Тәтеш пристанендә ишетә ул. Һәм бәхетен сынап карарга дип, тагын Казанга килә. Умарта оясын хәтерләткән шәһәрдә бары тик белем алу максатын гына маяк иткән Гыйлем Мулланур Вахитов белән танышып китә, шулай итеп, «милләтчеләр» белән «революционерлар» арасындагы каршылыкларны аера башлый, Февраль революциясе белән Октябрь инкыйлабы арасында бер митингтан икенчесенә, Казанның байлар бистәсе белән хеерче мәхәлләләрендә чаба, төрле кыйблага йөз тоткан вакытлы матбугат белән таныша торгач, чын большевик булып өлгереп җитә. Яшь Совет иленә яңа интеллигенция кирәк дип, аны Томск университетына укырга җибәрәләр.

Әлбәттә, гыйлем гранитын кимерү җиңелдән булмый. 15 сумлык стипендия ашарга да җитми, шуңа күрә Идел ярларында кияргә туры килгән йөкче камыты Томь ярларында ярдәмгә килә: вакыт булган саен Камай пароходларга йөк төяргә-бушатырга йөгерә торган була. Өстәвенә, өлкән буын интеллигент профессорлар, «теләсә каян җыелган» студентларга лекцияләр укыганда, махсус катлаулы терминнар куллана, шул рәвешле йокылы-уяулы, ярымач яшьләрнең укуын тагын да катлауландыра. Әмма Камайның укуга дигән иманы нык була, ул бирешми. Өлкән курсларда укыганда инде аны Балалар йорты мөдире итеп куялар, аннан соң Себер төрки-татар педагогика техникумына укытучы итеп билгелиләр. Химия белән фәнни дәрәҗәдәге дуслыгы нәкъ менә Томск университетында башлана. Гыйлем Камайның химиягә һәвәслеген профессор Тронов күреп

ала һәм синтезлар белән мавыккан егетне аспирантурага чакыра. «Йөкче малаенмы? Җитмәсә, татар! Җитмәсә, коммунист!» – дип каршы төшә икенче бер профессор. Әмма 1926 елда аны партиянең Татар өлкә комитеты Казан университетына чакыртып ала.

Дворян нәселле Арбузов аны теләмичә, егетнең үҗәтлеген күреп кенә үзенә аспирант итеп ала. «Кырыс булачакмын, үпкәләштән түгел», дип кисәтә. «Александр Ерминингельдович таләпчән, хәтта кырыс укытучы булды. Әмма иң беренче чиратта ул үзенең улы Бориска карата артык таләпчәнлек күрсәтә иде. Борис лабораториядә, завод цехларында 16–18әр сәгать эшли. Без еш кына лабораториядә өстәлләр арасына түшәк җәеп куна калабыз», – дип яза Камай үзе истәлекләрендә.

Аспирантурада укыганда, Гыйлем Камай Татар коммунистик университетында укыта, химия дәресләкләрен татар теленә тәрҗемә итә, татарча химик терминнар сүзлеген төзи. 1929 елда аспирантураны тәмамлагач, аны Германиягә Тюбинген университетына стажировка үтәргә җибәрәләр.

1930 елда Германиядән Казанга ул чын европалы булып кайта. Мотыйгулла хәзрәтнең оныгы, Галия Кайбицкаяның туганнан туган сеңлесе, Камайның булачак хатыны Рәйсә ханым беренче тапкыр очрашуларын болай дип тасвирлый: «Мин аны беренче тапкыр Г. Камал исемендәге Татар академия театрында күрдем. Ул Германиядән генә кайткан, КХТИда уку-укыту бүлеген җитәкли, мин медицина техникумын тәмамлыйм. Аның үз-үзен тотышы, тәмле итеп көлүе кешеләрнең игътибарын җәлеп итә иде. Ул бөтен нәрсә белән кызыксына, сораулар яудыра, үзе дә сорауларга рәхәтләнеп җавап бирә. Гыйлем бөтен булмышы белән шатлык сибә иде. Шунда мин аннан, туган көнегез түгелме, дип сорадым. Ул: «Туган ягыма исән-сау әйләнеп кайтуыма сөенәм», – дип җавап бирде. Беренче очрашудан җиде ай үтүгә без өйләнештек».

1930–1937 елларда Камай КХТИда арадаш продуктлар һәм буягычлар кафедрасы мөдире була, бер үк вакытта КДУда органик химия кафедрасын җитәкли, 1932 елда ТАССРның Социалистик Төзелеш Герое исеменә лаек була, 1935 елда Казан университеты ректоры итеп билгеләнә. Ике ел эчендә ул бер тулай торак төзетә, икенчесенең төзелеше башлана, университетның кайбер биналарына ремонт ясата, химия корпусына нигез салдыра. Болары хуҗалык эшләре генә әле.

КАМАЙ РЕАКЦИЯСЕ

1937 ел җитә. Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты архивындагы «Камай эше»нең план тутырыр өчен генә барлыкка килүе бүген сер түгел инде. Шул ук елның августында

1 Гыйлем Камай Германиядә дә спорт белән шөгыльләнүен туктатмый.

2 Гыйлем Камай гаиләсе белән.



3 Рәйсә Камай.

4 Иптәшләрчә шаярту. «Гыйлемле» Камай.

аны вазыйфасыннан азат итәләр, сентябрьдә кулга алалар. Йөкче улы Камайның Германиядә укуы «шик» уята, димәк, «фашистлар җәмгыятендә» торган. Имештер, троцкийчылар, милләтчеләр белән элемтәдә булган, Мирсәет Солтангалиевнең сеңлесенә КХТИга укырга керергә ярдәм иткән. Имештер, Германиягә киткәндә Арбузов, Мейзенгеймерга тапшыру өчен, Камайга бер ампула биреп җибәргән.

Камай Черек күл төрмәсендә 1939 елга кадәр утыра. Кирәкле кәгазьләргә кул куйдыртыр өчен, аны 120 сәгать тоташ йоклатмыйлар. Чыкканда бөтен тешләре коелган, сәламәтлеге какшаган була.

– Арбузовтан: «Чыннан да ампула биреп җибәрдеңме?» – дип сорыйлар. Ул «әйе» дип җавап бирә. Ампулада бернинди сер булмый, фәнни әйләнешкә кереп киткән үрнәкләрен Германиядәге коллегасына биреп җибәрә ул. Арбузов ничек бар, шулай, ягъни этинең ул ампуланы үз белдеге белән алып бармавын әйтә, шулай итеп, җаваплылыкны үз өстенә ала. Әтине КГБда Ежовны Берия алыштыру гына коткарып кала. Инде өмет өзелгәндә, аның белән кешечә сөйләшә башлыйлар, шикәрле кайнар чәй эчерәләр... – дип сөйли Светлана Гыйлем кызы, этисе язмышындагы ул авыр елларны искә төшереп. – Әнигә ул вакытта: «Син яшь бит әле, аерыл», – дип әйтә торган булганнар. Черек күлнең КГБ бинасына каршы ягында аның Хәлимә апасы яшәгән. Әни көннәр буе тәрәзәдән шул бинага карап утыра торган булган. Ничектер җаен табып, тугрылык саклавы, аны көтүе турында язып, үзенең фотосын этигә бирә алган.

«БУ ТУРЫДА ОНЫТМАСАК ИДЕ...»

Тешләре сынса да, рухы сынмый Гыйлем Камайның. Үзен тулаем фәнгә багышлар өчен, ул КХТИда кала һәм 1941 елда докторлык диссертациясе яклый, фәнгә «Камай реакциясе» булып кереп калачак синтез, реакция ысулларын ача.

– Бөек Ватан сугышының буеннан буена ул оборона заказларын үти. Казанның химия мәктәбендә Александр Арбузов җитәкчелегендә берничә төркем галимнәр нейропаралитик газ синтезлау белән шөгыльләнә. Камай төркеме эшләгән газ уңышлы дип табыла. Әти аны түш кесәсенә салып, теплушкада А.И. Разумов белән бергә Мәскәүгә илтә. Басып баралар, ул-бу була калса, ампула ватылса, анда берәү дә исән калмас иде. Гитлер Германиясендә дә шундый химик корал эшләнгән була. СССРда шундый ук газның аналогы барлыкка килү ул коралны куллануны туктатып кала. Казан химиклары барысы да бу турыда белә. 1952 елда әти Сталин премиясе белән бүләкләнә, – дип сөйли Светлана ханым.

30 нчы елларда Арбузовны еш кына теория белән мавыгуда гаеплиләр. Әмма Казан химия мәктәбенең СССРның халык хуҗалыгына керткән өлеше дә бихисап. Мәсәлән, Гыйлем Камай уйлап тапкан буяу икътисадта миллионнарны экономияләргә мөмкинлек бирә. Әйтик, юлда йөк корабының төбенә экәмтөкәмнәр ябыша торган була. Бу исә корабны

авырайта, юл чыгымнарын арттыра, шулай ук ремонт эшләрен дә ешрак үткәрүне таләп итә. Камай уйлап тапкан бояуга исә берни дә ябышмый. Файдасын үзегез санагыз.

Камайга хас оптимизмны кызы Светлана Камай шул чор белән бәйләп аңлата: «Максим Горькийны укырга ярата иде ул. Үзен Чеховның Ванька Жуковына охшата иде. Табигатьне бик ярата иде, ул да көч биргәнләр. Җәй саен без Югары Осланның Кызыл Яр авылына кайта идек. Елга ярына ук урнашкан бердәнбер татар авылы иде ул чакта. Ул кешеләрне бик яратты. Беркайчан да үзен өстен куймады. Үзен кеше иткән йөкчеләргә ихтирамлы булды. Ятимнәрне, «улым, кызым» дип, һәрвакыт үз канаты астына алды. Ул 7 фән докторы, 40 фән кандидаты әзерләде. Аларның һәркайсы Гыйлем Камайга рәхмәтле булды.

Көнкүрештә дә гади иде: кара ипи яратты. Мәскәүдән кызыл кәгазь тасмалы «Бородинский» ипиен алып кайта иде. Ипинең бер валчыгын да коймаска өйрәтте. Балык яратты, Идел егете бит. Гомер буе спорт белән шөгыльләнде. Мәскәүгә баргач, спектакльләр карамыйча кайтмый иде. Гомумән, сәнгатьне бик ярата иде. Бигрәк тә Глинка, Мусоргский операларын яратып тыңлый иде. Иң яраткан җыры – «Я люблю тебя, жизнь!»

Без элекке Комлев, хәзерге Мөштәри урамында, Совет чорында коммуналка итеп үзгәртелгән особнякта яшәдек. Әни гомерен әтигә, безгә багышлады. Мин әтигә 50 яшь булганда туганмын. Тагын ике елдан энем Руслан туды. Әти безне бик ярата иде. Безнең өйдә һәрвакыт кунаклар күп була иде. Әни бик тәмле итеп пешерә, әти, вакыты булганда, ишегалдына самавыр куеп, грузин, Краснодар, һинд чәйләрен бергә кушып, чәй кайната...»

Гыйлем Камай 1970 елда йөрәк авыруыннан вафат була. Үзе ихлас күңеленнән инанган коммунизм, Октябрь революциясе идеалларының кризисын күрми ул. Шул ук вакытта ихластан фән өчен эшләгән галимнәрнең хезмәтенә бәһа төшүен дә күрми кала. Шунысы белән бәхетле...

Редакциядән. Мәкаләне басмага әзерләгәндә материаллар белән ярдәм иткән өчен Гыйлем Камайның кызы Светлана ханымга, КХТИ тарихы музее кураторы Денис Сахарныхка, Тәтеш төбәге тарихы музее хезмәткәрләренә рәхмәтебезне белдерәбез.

5 Гыйлем Камай Борис Арбузов белән.

А.С. Лозовой, Г. Камайның беренче биографы, КХТИ тарихы музееен төзүче:
– Гыйлем Хәйри улы шәкертләреннән уңды. Аларның барысына да «Камай прививкасы» ясалган: барысына да фән җене кагылган. Нәкъ шуның нәтиҗәсендә алар барысы да зур уңышларга иреште. Гыйлем Хәйри улы хәрәмләшә белми, аңа бөтенләй ят ул. Фикердә дә, эштә дә, тормышта да ихлас. Шуңа күрә дә аның тирәсендә фикердәшләрдән торган уникаль атмосфера барлыкка килде. Аның белән аралашкан кешеләр Камайны ихлас, принципиаль, туры сүзле булуы өчен ярата иде.

В.Я. Гудкова, «Совет Татарстаны» газетасы журналисты:
– Беркөнне Гыйлем Камай редакциягә килде. «Бүген имтихан алдым, борчылдым әле», – дип, бусагадан ук сүз башлады ул. Бик дулкынланган иде, шунда ук әйтеп тә бирде. Студенттан, кем күбрәк ошый: Эдуард Манемы, Клод Монемы дип сораган идем, мин химиядән имтихан бирәм, сәнгать тарихыннан түгел дип җавап бирде, дип, борчулары белән бүлеште. Ул елларда физиклар белән лириклар арасында модага кергән дискуссияне күпертелгән дип саный һәм кешеләрне «технарьлар» белән «гуманитарийлар»га бүлгәнне өнәми иде.

БЕЛЕШМӘ

Гыйлем Камай

1901 елның 23 феврале – Казан губернасы Тәтеш шәһәрендә туган.
1910–1915 еллар – Тәтештә ат караучы, йөк ташучы булып, Сембердә Идел-Бөгелмә тимер юлы күпере төзелешендә эшли.
1916–1920 еллар – Казанда Татар укытучылар семинариясен тәмамлый, ВКП (б) сафларына баса.
1920–1926 еллар – СибТатКирбюрода эшли, Томск университетында укый.
1927–1929 еллар – Казан университетында аспирантурада укый, Татар коммунистик университетында укыта.
1929 ел – Германиянең Тюбинген шәһәрендә.
1930–1934 еллар – КХТИ һәм КДУ укытучысы, профессор.
1935 ел, февраль–1937 ел, август – КДУ ректоры.
1937–1939 еллар – «Камай эше» буенча Черек күл төрмәсендә утыра.
1939–1970 нче елларга кадәр – КХТИ профессоры, кафедра мөдире.
1970 ел, 17 март – Гыйлем Камай вафат була. Казанда Татар зиратына җирләнә.
Фән докторы (1941 ел). 450 дән артык фәнни публикация авторы, 35 ачышка авторлык таныклыгы бар.
ТАССРның Социалистик Төзелеш Герое (1932). СССР Дәүләт премиясе лауреаты (1952). Хезмәт Кызыл Байрагы (1945, 1950, 1951), Ленин (1961, 1967), «Почет Билгесе» орденнары иясе.
Казан урамнарының берсе Г. Камай исемен йөртә. Быел КХТИның Төп органик һәм нефть химиясе синтезы кафедрасына Г. Камай исеме бирелде. Тәтеш мәктәпләренең берсендә аның исемендәге класс бар, анда ел саен «Камай укулары» үтә. КФУ, КХТИ музейларында Камайга багышланган почмаклар булдырылган.

КҮЛӘГӘДӘГЕ СӘЯСӘТЧЕ: МӨФТИ МӨХӘММӘДЬЯР СОЛТАНОВ

Автор: Илдус Заһидуллин

Мәхкамәи шәргыя архивын ныклап өйрәнгән Риза Фәхретдин, мөфтиләрне чагыштырганда, «Мөфтиятне чын мәгънәсендә Мәхкамәи шәргыя итәргә тырышкан», «Халык тарафыннан иң нык тәнкыйтьләнгән» һәм «Дөньяви белемнәрен файдаланган», «Канунны саклап, канун нигезендә идарә иткән» дигән номинацияләрдә Мөхәммәдьяр Солтановны беренче урынга куйган. «Дини белемнәренең дәрәҗәсе» дигән номинациядә Солтанов ахырдан икенче урынны «алган».

ТАТАР ДВОРЯННАРЫ ТӘКЪДИМ ИТКӘН МӨФТИ

1885 елның 2 гыйнварында мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев вафат була. Аның урынына дворян Мөхәммәдьяр Солтанов тәкъдим ителә. Әлеге кандидатурага тукталуда хәлиткеч рольне Казан миссионеры Н.И.Ильминский уйный. Аның фикеренчә, Солтанов – байлыгы белән дә, аристократлыгы һәм чиннары белән дә күзгә ташланмый торган һәм мөселманнарга йогынтысы булмаган уртакул җир биләүче алпавыт. Иң мөһиме, милли идеялләрдән ерак торучы, фанатизмы булмаган, мөселман динен һәм гарәп чыганакларын өйрәнмәгән зат.

Елына 2000 сум хезмәт хакы алып эшләгән Мөхәммәдьяр, зур гаилә башлыгы буларак, мөфтинең 1572 сум 8 тиенлек еллык хезмәт хакына кызыкмый. Эчке эшләр министры граф Д.А.Толстой Солтановны яңа вазифага елына 5 мең сум хезмәт хакы вәгъдә итеп кенә күндерә. 1886 елның 2 гыйнварында Александр III Солтановны мөфти итеп билгели.

Мөхәммәдьяр Солтановның ерак бабалары Минзәлә өязенең Күҗәкә авылыннан чыккан, әтисе татар морзасы Габделҗәлил башкорт кантоны җитәкчесе булып хезмәт итә. Казан гимназиясен тәмамлагач, Мөхәммәдьяр 1856 елда университетка укырга керә, ләкин авыру сәбәпле, 1 курстан укуын калдыра. Бераздан 18 нче башкорт кантонында урядник вазифасына керешә. 1866 елда поручик дәрәҗәсендә отставкага чыгып, Минзәлә өязендә крестьяннар белән идарә итүче булып эшли башлый. 1870–1878 елларда Бәләбәй өязендә шул ук вазифаны башкара, 1879 ел башында Бәләбәй өязендә мировой судья итеп билгеләнә. Өч елдан соң шундый ук вазифаны Минзәлә өязендә башкара башлый. Мөдәммәдьяр Әзмәй авылы янында 774 дисәтинә җир били.

МӨФТИ КЕРТКӘН ЯҢАЛЫКЛАР

Мөхәммәдьяр Солтанов, Мәхкамәи шәргыягә гыйлемле муллаларны җәлеп итү максаты белән, 1890 елда Казан губернасы руханиларының казыйларны сайлау хокукларын алып, аларны үзәк хакимияткә үзе тәкъдим итә башлый. Бирегә тирән дини гыйлемле, мәгърифәтчелек идеологиясен алга куючы, милләткә хезмәт итәргә омтылган муллалар казыйлыкка чакырыла. Шушы юл белән Уфага Риза Фәхретдин, Габдерәшит Ибраһимов, Хәсәнгата Габәши, Җиһангир Тангатаров һ.б. килә. Шул рәвешле, мөфти тирәсендә җәдитче казыйлар туплана. Тәрҗемә эшләрен җиңеләйтергә теләп, ун ел эчендә Мәхкамәи шәргыя канцеляриясендәге рус хезмәткәрләрен татар зыялылары белән алыштырып бетерә.

Чиновник буларак муллаларның хезмәтен җиңеләйтү, яхшырту өчен, мөфти күпләп инструкцияләр, төрле-төрле справка формалары эшләтеп тараттыра. Бигрәк тә төрле «кагыйдәләр» язуга һәм тәрҗемә итүгә зур игътибар

Фотолар автордан алынды

бирә. Метрикә кенәгәләрен дөрес тотыру, мирас бүлү, холерадан үлгәннәрне күмү, вакыфлар белән идарә итү кагыйдәләре дөнья күрә. Гыйлемле казыйларның муллалардан килгән сорауларга җаваплар бирүен җайга сала. Казый Риза Фәхретдин тырышлыгы белән шушы текстларны һәм империянең исламга бәйле карарларын туплап, мөфти 1903 һәм 1905 елларда муллалар өчен җыентыклар бастыруны оештыра.

Бу елларда Мәхкамәи шәргыя бинасында күпсанлы техник яңалыклар кертелә. Ул 1887 елда агач мунча төзетә. Мәхкамәи шәргыяның эш мәйданнарын киңәйтү максатында 1900 елда бинага ике катлы янкорма төзергә рөхсәт ала, 1904 елда архив бинасына янкорма салдыра. Бинаны телефонлы итә, 1899 елда электр уты керттерә, 1907 елда су торбалары уздыра.

Мөхәммәдьяр Солтанов, гимназия тәмамлаган кеше буларак, мөселман руханиларына дәүләт телен белү кирәкле гамәл дип, бу хакта хөкүмәткә тәкъдим белән чыга. Мөфтинең проекты казыйларга һәм азсанлы шәһәр имамнарына гына кагылган булса, император 1888 ел 16 июль канунында русча белүне барлык булачак авыл имамнарына да мәҗбүри итеп куя. 1891 елдан барлык ахун һәм шәһәрдә имам булырга теләүчеләр – бер сыйныфлык халык училищеларында, авыл имамнары – өяз училищелары советларында русча сөйләшә һәм укый алулары турында имтихан тота башлый.

Мөхәммәдьяр мөфти тырышлыгы белән 1908 елда «Мәгълүмате Мәхкамәи шәргыя Орынбургыя» дип аталган журнал чыга башлый, аның тиражы 3500–4500 данә данә була, айга бер тапкыр басыла.

МӨФТИ ФӘРМАННАРЫ ҺӘМ НӘСЫЙХӘТНАМӘЛӘРЕ

XIX гасыр ахырында татар җәмгыятендә җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында көрәш көчәя. Шундый катлаулы шартларда Солтанов руханиларга махсус нәсыйхәт белән мөрәҗәгать итә. Мөфти мөрәҗәгатендә мәчетне, җәмигъ намазын – халыкны яхшы эшләргә, хезмәт сөюгә, яңа һөнәрләр үзләштерүгә, әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен беренче планга куеп яшәргә өндәү урынына әйләндерергә, бар яктан да мәхәллә халкына үрнәк булырга өнди. Шул рәвешле, мөфти беренче тапкыр мәхәлләләрдә социаль тормышны оештыруда – һәрбер мөселманның, балаларны укытуда һәм тәрбияләүдә һәрбер ата кешенең үз алдында торган бурычын үтәүнең мөһимлеген ассызыклый, һәр авылда заманча бина урнашкан башлангыч мәктәп булдыру кирәклеген әйтә. Муллаларга, Коръән һәм хәдисләргә нигезләп вәгазьләгез, гарәп һәм фарсы сүзләрен катыштырмыйча, гади халык аңлый торган телдә ачык сөйләгез, дип өндәшә.

Бер ел үткәч, 1898 елның 25 августында, мөфти шәһәр имамнарына махсус нәсыйхәтнамә белән мөрәҗәгать итә. Ул, тагын да кыюланып, имамнар мөселманнар арасында алдынгы фикер таратырга тырышырга тиеш дигән сүзләрне ачыктан-ачык сөйли. Халыкны тугры юлга өндәү сезнең эшегездер ди, заманга һәм халык күңеленә туры килә торган сүзләр сөйләргә кирәклеген искәртә.

БЕРЕНЧЕ ИНКЫЙЛАБ ЕЛЛАРЫНДА ЭШЧӘНЛЕГЕ

Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов һәртөрле сәяси чаралардан читтә торырга тырыша. Әйтик, ул Бөтенроссия мөселман съездларында катнашмый, ләкин 1905 елның мартында Министрлар кабинеты рәисе С.Ю. Витте белән очрашканда, аңа мөселманнарны дини билге буенча кимсеткән канunnar исемлеген тапшыра һәм аны газеталарда бастырта.

1905–1907 еллардагы инкыйлаб вакытында Солтанов башкарып чыккан икенче мөһим эш Мәхкамәи шәргыяның яңа устав проектын эшләтү була. Ислам институтлары белән идарә итүне камилләштерү өчен яңача фикерләү кирәген аңлап, мөфти эшкә килгән һәр казыйдан Мәхкамәи шәргыянең устав проектын эшләтеп ала. Беренче рус инкыйлабы башлангач, хакимияттән рөхсәт алып, күренекле ахун-голәмәләрне Уфага чакырып, 1905 елның 10–15 апрель көннәрендә Корылтай уздыра һәм яңа устав проектын эшләтә. Бу документны әзерләүдә үз теләкләре белән Уфага килгән сәүдәгәр һәм дворян зыялылар да катнаша. Яңа устав проекты мөселманнарның һәм ислам институтларының Россиядә тигез хокуклылыгы, дин, сүз иреге принципларына нигезләнеп төзелә. Бу документны, кабул ителгән очракта, дини-мәдәни автономия уставы дип карарга да мөмкин булыр иде.

1905 елда Идел-Урал төбәге мөселманнары үз хокукларын киңәйтүне сорап хөкүмәт исеменә күпсанлы петицияләр юллый. Бу мөрәҗәгатьләрнең күбесендә гаскәриләрнең дини хокукларын үтәүне гарантияләү мәсьәләсе куела. Гаскәриләрнең дини хокукларны яклап, мөфти 1906 елның 15 февралендә Мәхкамәи шәргыядә рус-япон сугышында хәрби мулла вазифасын үтәгән солдатлар, мөселман офицерлары катнашында киңәшмә уздырып, аның карарын китапчык итеп бастырып, хәрби министрга җибәрә. Документта сүз армиядә уртача 3–4 мең мөселман солдатына бер хәрби мулла штаты билгеләү турында бара. Бу чара муллаларның ант кабул итү, җирләү йоласын үтәү, бигрәк тә җомга һәм бәйрәм көннәрендә җәмагать намазларын башкару, солдатларны, лазаретта дәваланучыларны вәгазьләү кебек күпсанлы вазифалар башкарулары белән аңлатыла. Шулай ук мөселманнардан махсус гаскәрләр төзү тәкъдиме яңгырый. Һәм 1908 елда илнең биш хәрби округында, христиан руханилары кебек югары хезмәт хакы белән, берәр хәрби мулла штаты кертелә.

Мөфти, мөселман авылларында эчкечелек таралуга юл куймас өчен, 1907 елның гыйнварында

эчке эшләр министрына ун мөселман авылында хәмер сата торган кибетләрнең һәм сыраханәләрнең ябылуын сорап мөрәҗәгать итә.

Мәхкамәи шәргыядә җәдит мәктәпләрендә укытачак яшьләргә мөгаллимлек шәһадәтнамәсен бирдерүне беренче инкыйлаб елларында Мөхәммәдьяр Солтанов тарафыннан башкарылган тагын бер зур эш дип атарга кирәк. Кулларына тиешле документ алгач, кадимче муллалар һәм хакимият аларны җәдит мәктәпләрдә эшләүдән читләштерә алмаган.

ИМПЕРИЯ БАШКАЛАСЫНДА МӘЧЕТ САЛУ

Мөфти инициативасы һәм император рөхсәте белән 1906 елны «Санкт-Петербург җәмигъ мәчетен төзү Комитеты» уставы теркәлә һәм аңа 10 ел дәвамында Россия күләмендә иганә җыю хокукы бирелә. Башкалада җәмигъ мәчете нигезенә беренче ташны салу тантанасы 1910 елның 3 февралендә мөфти Солтанов, Бохара әмире, Дәүләт думасы мөселман депутатлары, Исмәгыйль Гаспринский, Төркия һәм Иран консуллары һәм шәһәр халкы катнашында үткәрелә. Империя башкаласында мәчеткә нигез ташы салу вакыйгасына илкүләм яңгыраш бирү максатында, Мәхкамәи шәргыя 1910 елның 29 декабрендә руханиларга махсус мөрәҗәгать белән чыга. Хатыйблар 1911 елның 29 гыйнвар көнне җомга намазы вакытында падишаһ Николай II иминлегенә, Россиянең гөрләп алга баруы өчен һәм башкала мәчетен төзүдә төп иганәче булган Бохара әмире исәнлегенә дога кылырга тиеш була. Җәмәгать намазыннан соң мәчеттәге халык Санкт-Петербург мәчете төзелеше өчен иганә җыю чарасында катнаша. Әле XIX гасыр азагында Санкт-Петербургка бер килүендә мөфти башкалада мәчет төзелеше өчен 25 мең сум җыеп бирергә вәгъдә иткән була. Мәхкамәи шәргыя округының 5,5 мең мәчетендә шушындый иганә акциясе уздырып, Мөхәммәдьяр үзенең вәгъдәсен үтәгән дип уйларга кирәк.

Солтанов мөселман руханиларын хәрби хезмәттән азат иттерү өчен зур тырышлык куя. 1894 елдан башлап хөкүмәткә даими рәвештә гаризалар язып, муллаларга, православие руханиларыныкы кебек, өстенлек бирү турында сүз алып бара. Аның теләге 1912 елны тормышка аша.

Татар вакытлы матбугатында мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның хөкүмәткә хезмәтенә илле, мөфтилек хезмәтенә егерме биш ел тулу уңаеннан юбилеен дини һәм милли тантана буларак бәйрәм итеп уздыру хакында сүзләр күп яңгырый. Махсус Юбилей комитеты төзелә. 1911 елның декабрендә Санкт-Петербургка үзенең юбилеен оештыру комитеты әгъзалары белән килгән мөфти хөкүмәткә Уфада яки Оренбургта ир-ат һәм хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йортлары ачу хакында гариза кертә. Уйланылган эшләр барып чыкмаса да, Уфадагы юбилей мәҗлесе милләтне туплау һәм берләштерү ягыннан бик зур әһәмияткә ия була.

Идел буе төбәгендә татар-мөселман йогынтысына каршы чаралар уздыруга багышланган Махсус киңәшмә (1910 елның 12–25 гыйнвары) карарларында дөньяви белем бирүгә күчеп барган мәктәп-мәдрәсәләрне икегә аерырга тәкъдим ителә. Империя хакимияте дини уку йортларын дини укыту предметларын гына калдырып оештырырга ниятли. 1913 елның 12 сентябрендә эчке эшләр министры мөфтигә шәригатьчә дин сабагын укыту мәктәпләре, аларның максатлары, укыту предметлары, дин сабагын укытырга алынган укытучылар нинди таләпләргә җавап бирергә тиешләр дигән сораулар белән мөрәҗәгать итә. Солтанов мәсьәләне бик оста хәл итә: төрле төбәкләрдән мөдәррис һәм казыйлар чакырып киңәшмә уздыра. Әлеге сорауларга, Коръән аятьләреннән һәм хәдисләрдән табып, мөселман дини уку йортында тәҗвидтән башлап, рус тарихы, физика, химия кебек предметлар укытылырга тиеш дип җавап яза. Шул рәвешле мәктәп-мәдрәсәләрдә дини һәм дөньяви фәннәр укытылуның хак икәнлеген Коръәнгә һәм дини китапларга таянып раслый.

Беренче бөтендөнья сугышы башланганчы, дини уку йортлары программасы эшләнми кала. Сугыш башлангач, мөфти үзен сәяси яктан алдан күрүчән җәмәгать эшлеклесе итеп күрсәтә, руханиларга нәсыйхәт белән мөрәҗәгать итеп, мәчетләрдә атна саен Россия җиңсен дип дога укырга өнди. Солтанов руханиларга Кызыл Хач җәмгыяте файдасына мөселманнар арасында иганә җыю кампаниясен башларга куша. Дәүләт думасының мөселман фракциясе депутатлары сугышчыларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү вакытлы мөселман комитетын төзиләр. Мөфтинең 1915 елның 5 апрелендә имзалаган руханиларга соңгы рәсми мөрәҗәгатьләренең берсе мәчетләрдә бер җомга көнне шушы иҗтимагый оешма файдасына иганә акчасын җыюны оештыру хакында була.

Мөхәммәдьяр Солтанов 1915 елның 12 июнендә вафат була. Васыяте һәм хөкүмәт рөхсәте белән аның җәсәде таш мәчетнең көнбатыш ягында, Сәлимгәрәй Тәфкилев кабереннән төньяктарак җирләнә.

Мөхәммәдьяр Солтановның мөфтилек хезмәте елларында Идел-Урал төбәгендә җәдит мәктәпләре ачыла, кадимчеләр белән идеологик көрәштә яңалык яклылар җиңеп чыга, татар милләте вакытлы матбугатка ия булып, сәяси көрәшкә кушыла. Бу яңалыкларны мөфти читтән генә күзәтми, кайбер очракларда аларда хәлиткеч рольне дә уйнап куя. Аның эшчәнлегенең шаһиты булган Риза Фәхретдин, киләчәктә мөфти дөньяви белемле кеше булырга тиеш, дигән фикергә килә. Төрле катлам һәм төрле иҗтимагый карашлы мөселманнар тарафыннан макталуга караганда күбрәк һәм ешрак тәнкыйтьләнгән Мөхәммәдьяр Солтанов шәхесенә Риза Фәхретдиннең бу фикере тарихи бәя булып яңгырый.

КИТАП КИШТӘСЕ

ЛУИЗА ШАРОВАНЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры директоры, танылган шагыйрә һәм сценарист Луиза Шарова (Янсуар) – әдәбиятны бик яратучы һәм нечкә тоемлаучы шәхес. Аның китап киштәсенә күз салу – димәк, маҗаралы сәяхәткә чыгу ул.

ШОМЛЫ ДА, СЕРЛЕ ДӘ КИТАПЛАР

Безнең өйдә китапларга һәм әдәби сүзгә искиткеч ихтирамлы мөнәсәбәт хөкем сөрә иде. Барысы да нәрсә дә булса укый, шәрехли, үзара фикер алыша, кемнедер яклый, аклый, ул гамәлләрнең нәрсәдән шулай булуын анализлый... – кыскасы, әйтерсең, теге яки бу әсәрнең каһарманнары белән авторлары безнең якын туганнарыбыз, йә булмаса танышларыбыз. Әсәрләр белән генә түгел, фильмнар, телевизордан караган спектакльләр, тапшырулар белән дә – шул ук хәл.

Бик бәләкәй чагымда, әбием һәм бабам белән яшәгәндә, мин киштәдә тезелешеп торган китапларга карап ятарга ярата идем. Иртән уянасың, кояш нурлары аерым бер почмак буйлап ургылып китапларга төшә, алар көяз итеп, рәт-рәт тезелешеп торалар. Еш кына урыннан күчешле уйныйлар. Мин хәзерге моментта әбием өчен кайсы «фаворит» икәнен төгәл беләм һәм, башкаларына сиздермичә генә, шунысына күз кысам! Янәсе: һәй, мин беләм сезнең әби белән сердәш икәнегезне! Үзем әле укый башлаганчы ук, аларны таный, тышлыкларындагы сурәт, язулар буенча классификацияли идем. Ә инде 5 яшемдә укырга өйрәнгәч, үз системам буенча билгеләп, тәртипләп чыктым.

Иң кадерле китапларның берсе – коточкыч калын «Җырларым» дип аталган китап иде. Без ул китапны һәр кич, чаршауны төшереп, йокларга яткач, әби белән бергә ачабыз һәм – кәефебезгә карап – җыру сайлыйбыз. Мин, бөкләнгән битләр буенча, кайсы җырның кайсы биттә яшәгәнен беләм. Кайчак, бик йончымаган һәм күңеле көррәк чагы булса, әби җыруларны минем «запрос» буенча җырлый. Алар арасында «әти белән әнине сагынганда җырлый торган җырлар», «бернәрсә дә күңелне күтәрмәгәндә җырлый торган җырлар», «очы-кырые юк эшне эшләгәндә җиңеллек китерә торган җырлар», «берәр этлек эшлисе килгәндә җырлый торган җырлар» кебек махсус категориягә карый торганнары да бар иде.

Берара әби «Язгы җилләр» һәм «Язгы аҗаган» дигән китапларны бик тетрәнеп укыды. Мин аларны кем язганын да белми идем әле ул вакытта, әмма икесе дә, исемнәрендә «яз» булса да, шом белән күңелгә кереп калган. Ә аннары без телевизордан «Язгы аҗаган»ның спектаклен дә карадык. Шунда бәләкәй Газиның: «Аҗаган күрдем, аҗаган!» – дип йөгереп кергән мизгеле йөрәгемне урталайга ярдымыни! Әбинең китаплары арасында бик үк билгеле булмаган бер авторның – Хәернисa Сафинаның – «Гөлчирә» романы бар иде. Ул Себердә яшәгән язучы апа дип хәтергә уелып калган. Тагын бер яратып укыган авторы – Кояш Тимбикова. Аның Кипарис исемле кыз турындагы романы турында без әби белән көннәр буе сөйләшә идек. Тагын берсе – «Кырагай», аны мин эзлим-эзлим, таба алмыйм...

Бервакыт өйдә «Гөлбадран» повесте хакында сөйләшә башладылар. Аңарчы шигырьләре бик еш яңгырый иде Сажидә Сөләймановaның. Ә бу китап турында сөйләгәндә, әрнеп сөйләшәләр. Соңрак аңладым – ул әсәр Сажидә апаның хушлашу китабы булган икән.

...Теге киштә дә, китаплар да... юк инде. Әмма иртән уянып, күземне ачканчы, кайчакта, мин аларны йокылы-уяулы бер параллель галәмдә һаман да күрәм. Шулай ук көязләнеп тезелешеп торалар. Ә мин аларга күз кысам: һә-ә-әй!..

БАЛАЧАКТА ҺӘМ ҮСМЕР ЕЛЛАРДА ИҢ НЫК ТӘЭСИР ИТКӘН КИТАПЛАР

Каюм Насыйриның «Әбүгалисина»сын ничә укыганмындыр, хәтерләмим. Әле, шундагы Хәлвәфрүштән күрмәле, зәгъфран дигән серле буяуга охшатмакчы булып, кулны кызыл балчыккаманып, авыл капкаларының келәләрен буяп йөргән дә хәтердә. Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар»ы бик ошый иде, миндә ул икенче бер әсәр – Анна Сьюэллның «Приключения Черного Красавчика» китабы белән тәңгәллəшә. Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы», Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары», Һади Такташның «Караборынның дусты», Дәрҗия Аппакованың «Кечкенә Бануның күргәннәре», Шәвәли турындагы Шәүкәт абый шигырьләре... Барысын да искә төшереп санап бетереп булмас. Кайберләренә генә тукталам. Мәсәлән, безнең өйдә зур бер китап бар иде, кызыл тышлы, тышына алтынсу хәрефләр белән «Муса Җәлил» дип язылган. Ул китапның уртасына килеп җиткәч, анда аерым битләрдә кешеләрнең исемнәре язылган да, аларның фотолары куелган һәм үлем сәгатьләре теркәлгән. Әнә шул битләр мине бик тетрәндерә иде. Шулай итеп мин Муса Җәлил белән бергә эшафотта һәлак булган җәлилчеләр турында белдем. Хәзер ул китап-альбом үземнең китапханәдә бик кадерле урында тора. Тагын бер сорау уяткан китапларның берсе – Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре. Биредә Тукай искиткеч психолог та, күпмедер күләмдә манипулятор да. Гомумән, бу шәхесне еллар яссылыгында өйрәнә-өйрәнә, аның психологиясе торган саен ныграк кызыксындыра. Бүгенге көндә тригерлар турында сөйләшергә яратабыз бит, абьюз, балачак травмалары темасын куертырга... Бу җәһәттән Тукай – искиткеч фигура. Без аның өслеген генә күрәбез, гәрчә тормышын елларга, айларга, атна, көннәргә бүлеп өйрәнеп чыксак та. Ә айсбергның бар чынлыгы – дәрья төбендә. Сүз уңаеннан, Тукайның «Исемдә калганнар»ы – әле XX гасыр башында ук иҗат ителгән менә дигән нон-фикшн ул!

Рус һәм чит ил әдәбиятына килсәк, Елена Ильинаның Гуля Королева турындагы «Четвертая высота» китабын атыйсым килә. Владимир Короленконың «Дети подземелья», Жорж Сандның «Консуэло» һәм «Графиня Рудольштадт», Шарлотта Бронтеның «Джен Эйр», Эмили Бронтеның «Грозовой перевал», Виктор Гюгоның «Собор Парижской богоматери», Александр Дюманың «Три мушкетера», «Граф Монте-Кристо», Мэри Шеллиның «Франкенштейн», Этель Лилиан Войничның «Овод», Вальтер Скоттның «Айвенго» романнары... Алар мине шулкадәр әсәрендерә иде ки, үзләрен чынбарлыкта өзлексез уйнап йөрим. Җәйләрен мәктәп бакчасында – анда безнең урманга тиң агачлык иде, шул «урман» эчендә минем рыцарь турнирлары уза. Кышларын ишегалдында борма-борма баскычлары, яшерен коридорлары, тәхет заллары, әсирләр өчен җир асты зинданнары булган замок төзим. Төнгә кадәр шул замокта әлләниләр булып бетә, – мин кичке ашка шыкраеп каткан бияләй, шарфлар белән кайтып керәм... Әле анда да өйгә куып диярдәй кертәләр! Әти белән әни дә, чит кешеләр дә ул замокка аяк басарга тиеш түгел иде, аның чит-чите боз диварлар белән уратып алынган һәм анда «Луиза замогы» дигән язу куелган. Һәм бу чикләрне чын-чынлап хөрмәт итәләр, кермиләр иде.

Ә аннары мин баштанаяк Герберт Уэллска гашыйк булдым. «Война миров»тан башларга киңәш иткәннәр иде, әмма мин «Человек-невидимка»дан башладым һәм чумдым. Иң-иң яраткан романым – «Остров доктора Моро». Герберт Уэллсның бөтенләй диярлек күз уңыннан төшеп кала торган искиткеч әсәре бар – «Чудесное посещение».

МИНЕМ ӨЧЕН КИТАП УЛ НӘРСӘ?

Минемчә, алар – плацебо да, психотерапевтлар да, коучлар да, рухи практика белән техникалар да... һәм, әлбәттә, порталлар!

ХӘЗЕР УКЫЙМ...

Балалар һәм яшүсмерләр өчен басылган рус һәм чит ил әдәбиятын, драматургияне. Үзебезгә нинди темалар, колач җитмәвен торган саен ныграк аңлыйм. Ә театрның репертуары классика һәм тәрҗемә әсәрләре нигезендә генә яши алмый, аңа бүгенгенең нервы кирәк, проблемалары... Шулкадәр шәп китаплар бар, сокланып туя алмыйм. Безнең әдәбиятка әнә шул заман сулышын кертәсе килә. Үстерәсе, тәрбиялисе иде яңа заман әдипләрен. Киләчәктә проза һәм драматургия юнәлешенә, шулай ук яшь авторларга зур өметләр баглыйм.

АЛАР БУЛМАСА, МИН БУЛМАС ИДЕМ, ДИГӘН КИТАПЛАР

9 яшемдә мин үзем өчен Блокны ачтым. Әйтерсең, Дөньяга ул югалтыбрак торган җете төсләр кайтты... Аннары – Цветаева, Лена Шагыйрьҗан, икесен бертәңгәл укыдым һәм аркылыга-буйга өйрәнеп чыктым. Әтидән (ул, мәктәп директоры булгач, районга да, Казанга да еш йөри иде, командировкаларга да), исемлек язып, китаплар кайтартам. Бу чорда мин нигездә ЖЗЛ сериясен укый башладым, фәнни-популяр әдәбият.

Ахматовага Цветаева багышлаулары аша гашыйк булдым, аның китаплары ул чакта юк иде. Авыл китапханәсендә, районда гына да түгел, ә гомумән...

БӨТЕНЛӘЙГӘ «МИНЕКЕ» ДИГӘН АВТОРЛАР ҺӘМ КИТАПЛАР

Джон Ирвингның «Молитва об Оуэне Мини» һәм «Правила Дома сидра» романнары – бөтенләйгә минеке. Ничек яза ул аларны – минем бу сергә кайчан да булса бер төшенәсем килә! «Оуэн Мини» романы миндә әллә нинди яшерен катламнарны кузгатты, шулай ук серенә төшенә алганым юк әле. Мариам Петросянның «Дом, в котором...» роман-трилогиясе белән дә – шулай.

КӘГАЗЬ КИТАПМЫ, ЭЛЕКТРОН КИТАПМЫ?

Әлбәттә, кәгазь китап, аны берни алыштырмый, әмма мин күптән инде электрон вариантка күчтем. Бу бик җайлы – телефонда китапны теләсә кайсы вакытта ачарга һәм укырга мөмкин. Мәсәлән, машинада (рульдә үзең булмау зарур, әлбәттә!) яки таксида, бер локациядән икенчесенә күчкән арада, эчпошыргыч җыелышларда, бер колагың белән анда сөйләгәннәрне тыңлыйтыңлый... Миңа смартфон өчен эшләнгән әйбәт мобиль кушымталар ошый, соңгы арада ешрак MyBook һәм Bookmate тан укыйм. Соңгысы әле миңа, даими һәм күп укый торган клиент буларак, 3 айга бушлай премиум-язылу бүләк итте – күңелгә бал да май якты тәмам!

Аерым бер авторларны яратам. Аларның дөньяларын бөртекләп өйрәнеп чыкмасам, тынычлана алмыйм. Китапларын гына түгел, ә биографиясен, һәр интервьюсын, әсәрләрендәге образ-нарративлар структурасын... Шундыйларның берсе – Харуки Мураками. «Мой любимый Sputnik» китабы белән романнан башланды барысы да. Ул барлык этапларны да узды: соклану, сихерләнү, кире кагу, бәхәсләшү, килешү, кабул итү... Шуңа һич шикләнмичә әйтә алам: Мураками – минеке, бөтенләйгә. Кинода Дэвид Линч ничек минеке – бу да шулай. Аларның баш миен шартлата торган сәер-аңлаешсыз дөньяларында мин үземне өемдә кебек хис итәм, тынычланам, таралып-иркенәеп китәм. Бу дөньялар аша нидер сулыш ала, ә ул сулыш аша Дөнья Тәртибе сиземләнә.

Орхан Памук – минеке. Аның бик моңсу, сагыш саркып торган романнары мине дәвалый. «Черная книга»дан башланган иде бу мәхәббәт, һаман дәвам итә. Һәр китабын зарыгып көтеп алам.

НИ БЕЛӘНДЕР ТАРТЫП КАЙТАРА ТОРГАН КИТАПЛАР

Владислав Крапивин китаплары! «Журавлёнок и молния», мәсәлән. Мин аны беренче мәртәбә татар теленә тәрҗемәдә укыдым – «Яшен чаткысы» дип атала иде. Китап үзендә яшәгән сабыйны югалтмаска ярдәм итә, дөньяны тотып торган дөреслекне җуюдан саклый. Һәм затлылык турында уйландыра! Югалган... без үзебез югалткан затлылык турында...

ӘРНЕТКӘН ҺӘМ ЙӨРӘКНЕ АВЫРТТЫРГАН КИТАПЛАР

Питер Хёг дигән язучының «Фрекен Смилла и её чувство снега» китабы. Мин шушы китап аша үземә Хёгны беренче мәртәбә ачтым. Глобализм шартларында безнең милли дөньяларның ничек юкка чыга баруы, кече халыкларның телләре, гореф-гадәтләре, менталитеты җуелуы турында сөйли бу китап. Юк, дөресрәге, аның турында түгел, киресенчә... Тиешлечә ыспай һәм җитеш шәһәр тормышына кертеп утыртылган ярымданияле, ярымэскимос Смилла Ясперсенның ничек итеп тамырлары һәм җан хәтере кубарылуы турында. Менә ул күршесендә яшәгән бәләкәй дустының мәете өстенә кайтып керә, һәм бу тетрәнү аша үзенең кем булуы турында уйлана башлый.

Ирена Доускованың «Будь Жегорт», Натан Ингландерның «Министерство по особым делам», Эми Липтропның «Выгон», Андраш Форгачның «Незакрытых дел – нет», Вигдис Йортның «Песня учителя», Алексей Рощинның «Страна утраченной эмпатии» китаплары. Болары – соңгы укыганнардан.

«МИНЕКЕ» БУЛМАГАН КИТАПЛАР

Нишләптер, күпме мактасалар да, язучы һәм философ Айн Рэндның «Источник» романын мин үз итә алмадым. Югыйсә, күп нәрсәләргә ачкыч һәм кодлар салынган анда... әмма, юк, кабул итә алмыйм. Бар шундый авторлар һәм китаплар, алар белән берничек тә бәйләнеш булдыра алмыйсың. Вирджиния Вулф белән дуслашып китә алмадык без, мәсәлән. Теодор Драйзер, Амос Оз белән...

УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘР ИДЕМ...

«Библиотека всемирной литературы» сериясендә чыккан 200 томлык – мине балачактан хәзергә кадәр озатып килгән гаҗәеп бер чыганак. Ул «Художественная литература» нәшрияты тарафыннан 1967–1977 елларда 300 меңнән артык тираж белән нәшер ителә. Өч сериядә: 1) Борынгы Көнчыгыш, антик чор, Урта гасыр һәм Яңарыш чоры әдәбияты, XVII–XVIII гасырларга караган әдәби мирас; 2) XIX гасыр әдәбияты; 3) XX гасыр әдәбияты. Кайчандыр Максим Горький тәкъдим иткән була бу идеяне. БВЛ томнарын бастырыр өчен бер елга 4 мең тоннадан артык кәгазь таләп ителгән.

Үзебезнең милли мирасны укырга киңәш итәр идем. Нинди генә бәхәсле ситуацияләр килеп туганда да, телеңне, әдәбиятыңны, тарихыңны белми торып, син үзеңне яклый да, тиешле югарылыкта, затлылыкта күрсәтә дә алмыйсың. Чөнки синең таяныр җирлегең юк! Менә моңа никадәр иртәрәк төшенсәң, үзеңне шулкадәр зыялырак итеп күрсәтә аласың, дип уйлыйм.

Мөмкин булганча, эзлекле итеп, үзебезнең әдәбиятны укып чыгарга кирәк – борынгы рун истәлекләреннән, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, «Идегәй» дастаннарыннан башлап, бүгенге көнгәчә. Әйе, баштарак алар кызыксыз тоелырга мөмкин, «скучно» дияргә яратабыз без борынгы әдәбият белән таныша башлаганда. Әмма акрынлап, аның нинди контекстта барлыкка килгәнен аңлап, детальләргә таяна-таяна, үзең өчен моңарчы күз алдыңа да китермәгән Ачышларга чыгарга мөмкинсең...

Бүгенге әдәбиятка килсәк, мин безнең хәзерге поэзияне бик көчле энергетикага ия дияр идем. Ул чын-чынлап югары кимәлдә: һәм фикер, һәм форма-экспериментлар ягыннан, һәм авазлар полифониясе буенча. Поэзия – ул искиткеч затлы деликатес, аның тәмен бер татыган кеше соңыннан теләсә нинди тәгамгә риза булмый инде.



ТАТАР ТАУ ИЛЕ

Автор: Руфия Фазылова

Яшьнәп торган авыллар бар, авырлык белән яшәүчеләре дә очрый. Һәм монда шәһәргә якын, ерак булу да әллә ни роль уйламый. Питрәч районының Татар Тау Иле гөрләп торган авыллар исәбенә керә. Мәктәп яшенә кадәрге балалар саны – илле дүрт. Һөнәр үзләштергәч тә, биредә яшьләр туган якларына кайтырга тырыша. Моңа дәлил – авылдагы сиксәннән артык яшь гаилә...

Фото: Александр Ефремов

ТАТАР ТАУ ИЛЕ

«ЮЛ ӨСТЕНДӘ БЕЗ...»

Тукаебыз: «Тау астына салынгандыр безнең авыл...», – дип язса, Татар Тау Иле нәкъ тау өстендә утыра. 206 хуҗалык бар биредә, 574 кеше гомер итә. Кышын бикле торган 4–5 өйне санамаганда, ябык йортлар юк монда. Мәктәп яшенә кадәрге балалар саны илле дүрт, дидем. Ә мәктәптә укучы малай-кызлар саны – утыз алты. Татар Тау Илендә урта мәктәп эшли, барлыгы 55 укучы белем ала. Бирегә күрше авыллардан да киләләр.

– Яшь гаиләләрне авылда калырга ничек күндерәсез? – дип сорадым Татар Тау Иле авыл җирлеге секретаре Рушания Боһараевадан.

– Авылда эш бар, төп сәбәп шунда. Үзебезнең җирлектә «Ак Барс» агрофирмасы эшли, механизаторлар, терлекчеләргә никадәр эш урыны дигән сүз. Күрше Ленино-Кокушкино авылында тавык фабрикасы бар, шунда эшлиләр. Икенче якта Пановка төрмәсе, анда эшләүчеләр дә шактый. Тагын үзебездә карьер бар. Район үзәге Питрәчкә, Казанга йөреп эшләүчеләр дә байтак. Кыскасы, читтә хезмәт куючылар йөздән артык кеше исәпләнә.

Авылың рус телендәге исеме – Татарское Ходяшево. Күпләр аның шул атамасын беләдер. Тәрҗемә итеп карадым да, аңлашылмады – тау ничек Ходяшевога әйләнгән соң? Бу хакта Рушания Боһараева болай диде:

– Үзебезнең дә уйланганыбыз бар – тәрҗемәсе туры килми. Аңа төгәл генә җавап юк. Күршедә Рус Ходяшевосы булганга, биредә татарлар яшәгәнгә, шулай куштылармы икән... Электән шулай килгән ул, документларда да шулай язылган.

Җирлеккә өч авыл керә – Татар Тау Иле, Княжа, Рус Ходяшевосы. Соңгысын югала барган авыллар рәтенә кертергә мөмкин – җәен яшәүчеләр генә бар икән. Күмәк хуҗалыклар оешкан мәлдә Татар Тау Иле өч колхозга бүленгән. Ләкин ул хәл дистә елга якын гына барган, аннан соң «Нариман» колхозы булып калган.

Колхозлар таралгач та, биредә фермалар ятим калмаган. Авыл җирләрен «Ак Барс» агрофирмасы үз кулына алган. Агымдагы ел башына 3 мең 990 баш мөгезле эре терлек саналган. Шуның өчтән бере савым сыерлары икән.

– Авыл кешесенә дә, күрше авылларга да эш бар, – диде Рушания Боһараева. – Агрофирманың эшчеләрне йөртер өчен өч автобусы бар. Төшке ашка ул халыкны өенә кайтарып куя,

1 Рушания апа эшкә киткәнче, дүрттә торып, бәлеш ясап, мичкә тыккан.

2 Дүрт буын бергә яшәүче Гыйззәтуллиннар.

3 – Минем өстә шушы үгезләр, – дип, ихаталары белән таныштырды яшь фермер Ришат Булатов.

алып китә. Хезмәт хаклары әйбәт, айныкын айга түлиләр.

ДҮРТ БУЫН БЕРГӘ

Берьюлы килен дә, кайнана да булу ничек икән? Гыйззәтуллиннар йортына юл алгач, шулай дип уйлап куйдым: дүрт буын бергә тату гомер итә икән! «Өлкән» килен Рушания апа гомер буе кайнанасы Кәримә апа белән яшәгән. Сигез ел элек йортта тагын бер киленгә арткан – Әнәс абый белән Рушания апаның уллары Ранис әнисе кебек елмаеп кына торучы кыз – Зиләгә өйләнгән.

– Ике килен белән яшим, – дип елмаеп каршы алды Кәримә апа.

– Ә яшь киленегез ике кайнана белән яши икән, – дидем.

– Әйе, шулай булып чыга. И, мин инде Зиләне кызым кебек кабул иттем. Рушаниясе исә әллә кайчан кызым...

Өйгә бәлеш исе таралган иде. (Рәхмәт яугыры, Рушания апа эшкә киткәнче, дүрттә торып бәлеш ясап, мичкә тыккан). Тәрәзәдән яз кояшы балкый. Ике килен табын әзерләп йөри... Кәримә апа түр башына утырган да куышлы уйнаучы ике малайны күзәтә. Бер мәл әбекәй:

– Сабыр гына торыгыз, җитте! – дип куйды. Малайлар эреп юк булды, диярсең...

Гаиләнең иң өлкән кешесе буларак, сүзне Кәримә ападан башладык.

– Безнең балачак бик авыр заманнарга – сугыш чорына туры килде, – ди ул. – Сугыш башланганда миңа тугыз яшь иде. Гел хезмәттә булдык. Әти сугыштан кайтмады, бик авыр тормышта үстек. Ундүрт яшьтән урман да кистек, үгез дә җиктек. Аякта – чабата, итек булмады.

Кәримә апа мәрхүм тормыш иптәше белән алты бала үстергән. Ни кызганыч, икесе инде бакыйлыкка күчкән. Өч улы, күршедә генә яшәүче бер кызы белән тату гына гомер итәләр. Әнәс абый төпчеге икән. «Әнәскә: «Төп йортны ташлап китмә», – дидем. Ташламады, рәхмәт», – ди әбекәй.

Кәримә апа белән килене Рушания утыз өч ел бер түбә астында яшиләр. Ул хәтта аны үзенең һөнәренә – яңа туган бозаулар карарга да өйрәткән.

– Фермада әнинең эшен дәвам итәм, – дип сөйли Рушания апа. – Яңа туган бозауларны өч айга кадәр үстерәбез дә башка терлекчеләргә тапшырабыз. Бик җаваплы эш, аларны яшь баланы караган кебек тәрбияләргә кирәк.

– Өч хатын-кыз бер аш бүлмәсенә ничек сыясыз? – дим.

– Урын барыбызга да җитә. Хәзер әни дилбегәне безгә тапшырды. Шулай да эштән кайтуыбызга чәен куеп каршы ала. Ашны плитәгә куеп китсәк, пешереп бетерә. Яшәсен генә, өйдә ул булгач, бик рәхәт.

Ике кайнанасын тыныч кына тыңлап утырган Зиләгә сүз каттым:

– Яшьләр бүген аерым яшәргә омтыла. Сезнең дә андый теләк юкмы?

– Без инде аерым яшәп карадык. Өйләнешкәч тә, Питрәчтән фатир алган идек. Шунда күченеп киттек. Тик кире авылга, төп нигезгә әйләнеп кайттык. Бергә яшәү күпкә җиңелрәк. Һәрвакыт ачык ишеккә кайтып керәсең, балаларны мәктәптән, бакчадан алырга кирәк дип ашыгасы юк. Дәү әни белән дәү әти янәшәдә булганда, бала үстерәсе күпкә җиңелрәк икән.

Зилә авыл кибетендә сатучы булып эшли, ике көн эшләп, ике көн ял итә. Гаиләдәге ир-атлар – Әнәс абый механизатор булып хезмәт куя. Ранис та әтисенең һөнәрен сайлаган. Агрофирмада эшлиләр икән.

Гыйззәтуллиннар элеккеге кебек күпләп мал асрамый. Ит өчен бер-ике баш үгез тоталар. Җәен исә каз, үрдәк, тавык-чебиләр алалар. Ә менә сыерларын бетергәннәр. Сәбәбе – авылда сөт җыймый башлаганнар.

– Питрәчнең сөт заводын ябып торганнар иде, – ди Әнәс абый. – Халыктан сөт җыелмады. Аннары бит сөтнең хакы да бик арзан. Кешеләр шуңа да асрамый башлады. Мисал өчен, без көне буе эштә. Бер рәхәткә чыккач, яңадан сыер асрыйсы килми икән ул. Хезмәт хакын ай саен биреп торалар. Эштән кайтасың да ял итәсең. Элек безнең як кешеләре базарга каймак, сөт күп ташыды. Ул чакта хезмәт хакы бирмиләр иде. Әйтәм бит, хәзер шәһәрчә яшибез.

«КЕШЕГӘ ЭШЛӘГӘНЧЕ...»

Авылның тагын бер гаиләсе белән таныштык – Булатовлар. Гаилә башлыгы Рөстәм абый өч баласын да авылда эшләргә күндерә алган, аларга мөмкинлекләр тудырган. (Кызганыч, үзе белән танышып булмады, авылда түгел иде.) Ә менә аның эшен дәвам итүчеләр – улы Ришат һәм кызы Зөлфирә белән аралаштык. Булатовлар КФХ хуҗалары. Үгезләр үстерү, аны эшкәртеп сату эшен җайга салганнар. Биредә һәркайсына да эш җитә.

– Минем өстә шушы үгезләр, – дип, ихаталары белән таныштырып йөрде яшь фермер Ришат. – Әлегә 80 баш үгез бар, итле дип, махсус Герефорд токымлыларны алып кайттык.

Булатовларның карамагында 1000 гектар җир бар, шуның 800 гектарында – бөртекле культуралар, калганында печән үсә. Бөтен төр техникалары да үзләрендә.

– Әти фермерлык эше белән 2005 елдан бирле шөгыльләнә, – дип сүзен дәвам итте Ришат. – Шул дәвер эчендә җыелган техникалар бу. Бер тапкыр грант алган идек, ул акчага трактор сатып алдык.

Әйткәнемчә, Булатовлар итне үстереп, эшкәртеп тә саталар. Узган ел кафе да ачканнар. Тик пандемия башлану сәбәпле, ябарга туры килгән. Менә хәзер шуны яңадан ачарга җыеналар. Шулай ук үзләренең кибетләре дә бар. Анда көндәлек кирәк ризыклардан

4

Әнә бүгенге балалар ничек үсә. Тәрбиячеләре кулда күтәреп йоклата, якты, иркен бүлмәләр.

5

– Хәзер бер яшь ярымлык балаларны да алабыз, – диде балалар бакчасы мөдире Фирая Гобәйдуллина.

6

Унөч ел Казанда, бер оешмада юрист булып эшләгәннән соң, барысын да ташлап, Зөлфирә туган авылына эшкә кайткан.

тыш, ыслап ясалган ит тә (ат, сыер, дуңгыз, тавык), балык та сатыла. Шулай ук үзләре әзерләгән пилмәннәр, кәтлитләр да бар. Боларның барысы белән дә Булатовларның кызлары – Зөлфирә идарә итә. Унөч ел Казанда, бер оешмада юрист булып эшләгәннән соң, барысын да ташлап, туган авылына эшкә кайткан ул.

– Кияүгә чыккач та, Питрәчтән көн саен Казанга йөреп эшләдем, – диде Зөлфирә. – Тик юл бик ардыра, бала үскәнен дә күрмисең. Эти: «Ит ыслый торган җиһазлар алабыз, кибет, кафе ачабыз», – дигәч, кайтырга булдым. Нәкъ шул елны олы улыбыз мәктәпкә укырга керәсе иде. Дөресен әйтим, кибетче булып эшли башлаган мәлдә бик авыр булды, бәргәләндем. Ә аннан үзем өчен шуны аңладым: бер эшнең дә ояты юк. Иң мөһиме – мин үземә эшлим. Нигездә, кибеттә гел үзем сату итәм, кайбер көннәрдә генә әни килеп алыштыра.

Пилмәннәр ясарга, итне ысларга махсус кешеләре бар икән. Әлбәттә, ит үзләре җитештергән генә түгел, читтән дә сатып алалар.

– Ысланган ит белән сәүдә итү куркыныч түгелме, алмасалар, бозылырга мөмкин бит, – дим.

– Юк, бозылмый. Һәрчак сатылып бетә. Итләрне өч көнгә бер ыслыйбыз. Безнең инде даими сатып алучыларыбыз бар. Аннары шул ягы әйбәт: кибет юл өстендә. Узган-барган кешеләр дә туктап ала. Махсус килүчеләр дә күп. Тәмле безнең ит.

Зөлфирәнең үз-үзен тотышы, сатып алучылар белән аралашуы ошады. Итагатьле, зыялы ханым.

КӨЛЕП ТОРГАН БАКЧА

Авылда балалар күп. Хәтта балалар бакчасына чират булган. Ни өчен үткән заманда язам, хәзер бу проблема хәл ителгән. Республика программасы кысаларында, бакчага капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Нәтиҗәдә, нәниләр һәм урта яшьтәге балаларны ике төркемгә бүлү мөмкинлеге барлыкка килгән. Ә авылда яшәүче хатын-кызларга исә тагын дүрт эш урыны барлыкка килгән.

– Хәзер бер яшь ярымлык балаларны да алабыз, – диде бакчаның мөдире Фирая Гобәйдуллина. – Быел алты балабыз мәктәпкә бара. Димәк, җәйгә алты урын булачак. Әлегә ике төркемдә дә балалар саны тулы. Әлбәттә, хәзер эшләргә күпкә җайлырак. Бүлмәләр матур, балкып тора. Ризык әзерли, кер юа торган бүлмәләр дә уңайлы.

Баксаң, капиталь төзекләндерүгә кадәр бакча белән авыл җирлеге идарәсе, китапханә бер бинада булган. Хәзер инде ул фәкать

4

5

6

балалар бакчасы булып кына тора. Авыл җирлеге идарәсен – мәдәният йортына, ә китапханәне мәктәпкә күчергәннәр. (Авыл җирлеге идарәсенә яңа бина салынырга тиеш, диделәр.)

Фирая Гобәйдуллина белән аның кайнатасы, кайнанасы янына да барып килдек. Әминә белән Әюп Гобәйдуллиннар алтмыш ел бергә гомер итәләр икән. Өч ул үстергәннәр.

– И, җәй көне ковид белән авырдым, үләм дип торам, – ди әбекәй. – Бабай үзе генә калыр дип уйлаган идем инде. Алланың рәхмәте, ничектер аякка бастым. Әюп белән алтмыш беренче елыбызны башладык.

Әминә апа нык чирләгән – хастаханәдә дә яткан. Ә менә Әюп абыйга зәһәр чир иярмәгән. Бабай белән әби сиксән сигез яшьләрен тутырган. Икәү генә яшиләр. Әлегә кадәр кәҗә, кош-корт асраганнар.

– Ничек таныштыгыз? – дигән сорауга иң беренче әби җавап бирде.

– Минем монда туганнар яши иде, кунакка кайтып йөрдем. Күрше тавыгы күркә була бит, бабайның күзе төште, – дип көлде әби.

Икесенең дә балачаклары сугыш елларына туры килә. Сугыш тәмамлангач та, җиңел булмый аларга. Шуңа да карт белән карчык бүгенге тормышларыннан бик канәгать. Күкләрдән алар бары исәнлек, тигезлек сорый.

– Әти гомер буе колхозда бухгалтер-кассир булып эшләгән, – ди Фирая апа. – Бик башлы ул. Лаеклы ялга чыккач та, тагын ун ел хезмәт куйды әле.

– Илле биш ел хезмәт стажым бар, – диде Әюп абый. – Тау Илендә җиде класс тәмамлаган килеш мин. Мәктәптә бишлегә генә укыдым. Аннары да дәвам итәргә теләгән идем, мөмкинлек булмады. Әти юк, әнигә дүрт ир баланы ашатырга да кирәк бит.

Әминә апа да әтисез үсә. Алты баласын калдырып, әтиләре сугышка китә. Һәм шуннан кайтмый.

– Бик авыр заманнар туры килде безгә, – диде әби. – Сезгә, яшьләргә, аларны күрергә язмасын. Тормышлар матур инде бүген. Бер улыбыз авылда калды. Хатыны Фирая белән әнә гел шулай килеп торалар. Без бик канәгать...

...Алтмыш ел бергә гомер итүче әби белән бабай яныннан чыккач, уйга калдым: әнә бүгенге балалар ничек үсә. Тәрбиячеләре кулда күтәреп йоклата, якты, иркен бүлмәләр. Ашауны әйткән дә юк. Ә әле генә аралашкан Кәримә апа, Әюп абый, Әминә апаларның да балачаклары булган бит. Алар буыны өчен суда пешкән бәрәңге затлы ризык саналган. Ә бүген балаларны ашатып булмый... Кызык инде бу адәм балалары! Т

7
Әминә белән Әюп Гобәйдуллиннар алтмыш ел бергә гомер итәләр.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Рушания Бoһараева,
Татар Тау Иле авыл җирлеге секретаре:
– Татар Тау Иленең оешу вакыты XVI гасыр башларына карый. Кукмара ягыннан Тавигил исемле кеше гаиләсе белән килеп утырган дигән тарих йөри. Милләте буенча татар булганга, аны Татар Тавигиле дип йөргәннәр. Тиз арада якын-тирә авылларда яшәүче бүтән татар гаиләләре дә бирегә күченеп килгәннәр. Һәм авылга, аны оештыручы хөрмәтенә Татар Тау Иле дигән атама кушыла.
Бу урыннарда кеше яшәмәгән. Ләкин авыл урыны юл өсте саналган, юлаучылар шактый йөргән. Хәтта безнең зиратта алтынчы, җиденче гасырга караган өч каберлек, таш та бар. Бабайлар сүзләре буенча, ул юлаучыларның каберләре.

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КИЛӘСЕ САНЫНДА:

Хәерче малайлар өчен йорт... Ятим кызлар өчен приют... Фәкыйрь кәләшләр өчен пособие... Сукбайлар өчен кунып чыгу йорты... Ачлар өчен икмәк склады... Шәһәр өчен суүткәргеч...

ЧИСТАЙ ИГАНӘЧЕЛӘРЕНЕҢ БҮЛӘКЛӘРЕ

Чистайның «икмәк корольләре»: Челышевлар, Шашиннар, Чукашёвлар, Подуруевлар – шәһәрдәге ярлыларга ничек ярдәм иткән.



Василий Львович Челышев портреты. 1884 ел. И.Крамской.
Пермь дәүләт сәнгать галереясы тупланмасыннан

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Татарстаннан
кайнар сәлам!

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

* Татарстаннан кайнар сәлам!
(азәрбайҗан теленнән тәрҗемә).

Татарстанда 9527 азәрбайҗан кешесе яши
(2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).